Безнең МИРАС

ISSN:2500-011X

11

ноябрь 2016

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

БОЛГАР ИСЛАМ АКАДЕМИЯСЕ: кичә, бүген, иртәгә

Казан Кремлендә ТР Дәүләт киңәшчесе, «Яңарыш» республика фондының иганәчеләр советы рәисе Минтимер Шәймиев катнашында Болгар ислам академиясен төзүгә багышланган киңәшмә булып узды. Анда эш тизлеген кышын да киметмәүгә басым ясалды.

Киңәшмә барышында Болгардагы «Кол Гали» кунакханә комплексын коруга кагылышлы мәсьәләләр дә каралды.

Болгар ислам академиясенә килгәндә исә, ул илнең мөселман өммәте интеллектуаль элитасын – ислам тәгълиматы магистрларын һәм докторларын әзерләү белән шөгыльләнәчәк. Шулай ук өстәмә һөнәри белем алу өчен дә мөмкинлекләр тудырылачак.



Фотолар shaimiev.tatarstan.ru сайтыннан алынды

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
11 (275)
ноябрь 2016

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

90

101 АЛАР ГУЛАГТА ДУСЛАШКАН. *Лилия Гаделшина*

112 АГАЧ ЭШЛӘНМӘЛӘР. *Р.Мөхетдинова*

ЭЧТӘЛЕК

БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

3 **Без — рәхмәтле халык**

«БЕЗНЕҢ МИРАС»КА — 25!

4 **«Без — мираслы халык».** *Рәхмәт хатлары, тәбрикләүләр*

ТАРИХИ МИРАС

12 **Болгар. Икмәк музее**
14 **Зөләйха.** *Ә.Мөхәммәдиев*
18 **Каргалы казаклары.** *Р.Әминов*
24 **«Илдә финанс тәртибе бетте...»** *Р.Вәлиев*
32 **Якуб Акчурин йорты.** *Н.Таиров, И.Таиров*
36 **Хөсрәү би язмышы.** *Р.Галләм*
40 **Рауза Бикколова: «Бабаларым затлы кешеләр иде...»**
45 **Уңышлы башламнар.** *Л.Хәмидуллин*

ТАТАР ГАМЕ

48 **Мансур Ярмиев: «Без татар булуыбыз белән горурланып яшәргә тиеш!..»** *Р.Сәгъди*
52 **Алардан шәп мирас калды.** *Р.Юныс*

ТАТАР МӨҺАҖИРЛӘРЕ

56 **Сания Гыйффәт.** *Ф.Гаффарова*

ӘДӘБИ МИРАС

60 **Кутадгу билик. (Котайткыч белем).** *Й.Баласагуни*
64 **Чыңгызханның ак болыты.** *Ч.Айтматов*
74 **Кияү сайлаганда.** *С.Кальметов*
76 **Галиябануның сәхнәгә менгән көннәре.** *М.Фәйзуллин*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

80 **Галимҗан Ибраһимов.** *Р.Мөхәммәтша*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

84 **Ялтаның җылы хатирәсе.** *Р.Мирхәйдәров*

СӘНГАТИ МИРАС

90 **Татар моңын дөньяга таратучы.** *Ф.Мөслимова*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

96 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
98 **Пибик.** *Х.Исмәгыйлев*
99 **Тел — тормыш көзгесе.** *Г.Бәширов*

ХӘТЕР САГЫНДА

101 **Алар ГУЛАГта дуслашкан.** *Л.Гаделшина*
104 **Зур Чынлының олуг улы.** *Ф.Дәминова*
106 **Еллар кайтавазы яки бер сәфәр.** *Ф. Кутлу*
112 **Агач эшләнмәләр.** *Р.Мөхетдинова*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның ноябрь ае.** *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **Вак-вак ләтыйфәләр.** *Р.Шәрәфиева*

118 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Ноябрь*

119 **Мирасворд**

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Марат Закиров
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №М-2818. Тираж – 1600 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 26.10.2016
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе иректе.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән
туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми
һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта
гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән
башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61
телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән,
авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан,
«Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык
«Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Ана портреты». 1955 ел. Киндер, майлы буяу.
Х.Якупов рәсеме

Без – рәхмәтле халык

Без – мираслы халык. Без – хәтерле халык.

25 еллык тарихы булган «Безнең мирас» та – безнең мирасыбыз, хәтеребез: халкыбыз мирасы, халкыбыз хәтере!

Без – эшчән һәм хисчән халык. Без – булдыра торган халык. Без – рәхмәтле халык.

Журналыбызның юбилее мөнәсәбәте илә басма исеменә җитәкчелектән һәм җәмәгатьчелектән бик күп котлаулар, Рәхмәт хатлары килде. Без аларны эшләгән эшебезгә бирелгән ихлас бәяләр дип кабул иттек. Үз чиратыбызда тәбрикләүчеләребезгә, аерым алганда, Татарстан Республикасы Президенты **Р.Н.Миңнехановка**, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе **Ф.Х.Мөхәммәтшинга**, Беренче Президентыбыз **М.Ш.Шәймиевкә**, мәдәният министры **А.М.Сибагатуллинга**, «ТАТМЕДИА» матбугат һәм гәммави коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе **А.Р.Зариповка**, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комететы рәисе **Р.З.Закировка**, «Халыклар Дуслыгы йорты» директоры, Дәүләт Советы депутаты **И.И.Шәриповка**, Россия Федерациясе мөселманнары диния нәзарәте рәисе, Россия Мөфтиләр шурасы рәисе, мөфти шәех **Равил Гайнетдингә**, ИЯЛИ директоры, профессор, ТВФнең мөхбир әгъзасы **К.М.Миңнуллинга**, Мамадыш муниципаль район хакимияте башлыгы **А.П.Ивановка**, «Ойл-сервис» ҖЧҖ генераль директоры, Башкортстан Республикасының Дәүләт Корылтае депутаты **Ә.В.Ишмөхәммәтовка**, шулай ук «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры **А.В.Кузьминга**, «Татнефть» ААҖ генераль директоры **Н.Ө.Мәгановка**, ТР Милли музее генераль директоры, тарих фәннәре докторы **Г.Р.Нәҗиповага**, «Кукмара киез эшләнмәләр комбинаты» ААҖ генераль директоры **Ш.М.Әхмәтшинга**, археолог-галим **А.Борһановка**, әдәбият галиме, рәссам-хаттат **Н.Нәккашка**, Алманиядә яшәүче милләттәшебез, журналист, кинорежиссёр **Н.Юрушбаевка** һәм безгә котлауларын ирештергән барча милләттәшләребезгә олуг рәхмәтләребезне юллыйбыз.

Үткәне барның – мирасы бар. Мирасы барның – киләчәге бар.

Без – максатлы халык. Безнең максат – халыкка, милләткә хезмәт итү. Шагыйребез сүзләрен куәтләп, әйдәгез, бергә-бергә алга – халыкка хезмәткә!

Ләбиб ЛЕРОН

10 октябрьдә

«БЕЗНЕҢ МИРАС»

ЖУРНАЛЫНЫҢ ЧЫГА БАШЛАВЫНА 25 ЕЛ ТУЛУГА БАГЫШЛАНГАН

25

«БЕЗ – МИРАСЛЫ ХАЛЫК»

дигән әдәби-музыкаль кичә булып узды

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең

РӘХМӘТ ХАТЫ
«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫ КОЛЛЕКТИВЫНА

Татар халкының данлы мирасын халкыбызга кайтару өлкәсендә башкарган хезмәтләрегез өчен зур рәхмәтемне белдерәм.

Моннан чирек гасыр элек нәшер ителә башлаган «Безнең мирас» («Мирас») журналы үз тирәсенә милләтпәрвәр каләм әһелләрен, галимнәрне һәм халкыбызның үткәненә, киләчәгенә битараф булмаган укучыларны туплады. Шушы дәвердә журнал сәхифәләрендә милләт язмышын чагылдырган, инде тарих катламнары арасында күмелеп кала башлаган бәяннар нәшер ителде, милли каһарманнарыбызның исеме халыкка кайтты.

Киләчәктә дә сезгә зур уңышлар, журналның, изге миссияне дәвам итеп, заман белән бергә атлавын телим!

Ф.Х.МӨХӘММӘТШИН
2016 елның 10 октябре

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы

РӘХМӘТ ХАТЫ
ХӨРМӘТЛЕ «БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫ КОЛЛЕКТИВЫ!

«Безнең мирас» журналын ихлас күңелдән 25 еллык юбилее белән котлыйм. Туксанынчы еллар башында милләтебез өчен зур казаныш булып дөньяга аваз салган журнал халкыбызның кыйммәтле хәзинәгә тиң бай мирасын бөртекләп җыеп халыкка кайтару белән шөгыльләнә. Биредә тарихи, әдәби, мәдәни, дини, сәнгати һәм педагогик мираска кагылышлы язмалар басылып, кадерле ядкярләребез яктыртылып килә. Журнал битләрендә татар дөньясында тирән эз калдырган шәхесләребез, атаклы милләттәшләребез һәм аларның хезмәтләре хакындагы язмалар киң урын ала.

Халкыбызның бай мирасын киләчәк буыннарга саклау юнәлешендә без уртак эш башкарабыз, халкыбызның милли җәүһәре булган Сабан туе кебек бәйрәмнәрне дә без сезнең журнал белән бергәләп үткәрәбез.

Киләчәктә дә шулай бердәм булып, киңәшләшеп эшләргә язсын! Киңәшле эш таркалмас, дигән аксакалларыбыз.

Сезгә алга таба эшегездә иҗади уңышлар телим! Тиражыгыз зур, укучыларыгыз күп булсын!

А.М.СИБАГАТУЛЛИН,
Татарстан Республикасы мәдәният министры
Казан шәһәре, 2016 ел

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫН УКУЧЫЛАР ҺӘМ ЧЫГАРУЧЫЛАР! ХӨРМӘТЛЕ ГАЛИМНӘРЕБЕЗ, ӘДИПЛӘРЕБЕЗ ҺӘМ ЖУРНАЛИСТЛАРЫБЫЗ!ХӨРМӘТЛЕ ЛӘБИБ ЛЕРОН УЛЫ!

Сезне күренекле журналыбыз «Безнең мирас»ның 25 еллыгы белән чын күңелдән котлыйм!

Журнал илдә олы үзгәрешләр барган чорда, татарның үзаңы көчәйгән заманда чыга башлады. Максаты – тарихыбызның тирән катламнарын ачып, тиңсез рухи мирасыбызны дөньяга чыгару һәм милләтебезне үзгәртеп коруның аяусыз давылларыннан саклап калу иде. Шул вакыттан башлап хәзерге көнгә кадәр журнал үз бурычын лаеклы үтәп килә. Чирек гасыр вакыт дәвамында кайбер эчке үзгәрешләр кичерсә дә, мирас дигән кыйбласына тугрылыклы калды. «Безнең мирас» талантлы һәм фидакяр зыялыларыбызны үз тирәсенә туплап, милләтебезнең бөтен фәнни-мәдәни көчен, иҗади мөмкинлеген журнал сәхифәләрендә гамәлгә ашырып, телебезне, тарихыбызны, фәнебезне, мәдәниятебезне саклауга һәм баетуга хезмәт итә. Әйе, без – мираслы халык, димәк, узганыбызга – ихтирамлы, бүгенге көндә – зирәк, киләчәгебез өчен җаваплы халык.

«Безнең мирас» журналын чыгаручы булдыклы, талантлы журналистларга, язучыларга, барлык хезмәткәрләргә зур рәхмәтебезне җиткерәбез.

Барчабызга да сәламәтлек, бәрәкәтле тормыш һәм яңа иҗади уңышлар телим. Киләчәктә дә халкыбызга бергә-бергә хезмәт итәргә насыйп булсын, газиз милләттәшләр!

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ,
Татарстан Республикасының Беренче Президенты

БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО
КОЛЛЕКТИВУ ЖУРНАЛА «БЕЗНЕҢ МИРАС»

За многолетнюю плодотворную работу и большой вклад в развитие средств массовой информации Республики Татарстан и в связи с 25-летием журнала.

А.ЗАРИПОВ,
Руководитель Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям «ТАТМЕДИА»
Казань, 2016

РӘХМӘТ ХАТЫ

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫНЫҢХӨРМӘТЛЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ, БАШ МӨХӘРРИР ЛӘБИБ ӘФӘНДЕ ЛЕРОН!

Сезне күркәм бәйрәмегез белән чын күңелдән тәбрик итәм! Безнең дә бәйрәм ул! Чөнки халкыбызның күп гасырлык тарихын, мирасын барлау – һәммәбезнең дә уртак эше.

Журналның быелгы сентябрь-октябрь саннарында бабабызга багышланган «Ишмөхәммәт хаҗи кыйссасы» дөнья күргәч, «Безнең мирас» аеруча кадерле, газиз

булып китте. Буыннан-буынга өзелмичә килгән иманлы нәсел-нәсәпне әнә шулай күркәм итеп күрсәтүегез өчен сезгә бик зур рәхмәт! Асыл бәйрәмегез котлы булсын, халкыбызның яшәү көчен, иманын бергәләп тергезик һәм саклыйк!

Ә. В. ИШМӨХӘММӘТОВ,
Башкортостан Республикасының Дәүләт Корылтае депутаты, «Ойл-сервис» ҖЧҖнең генераль директоры

ХӨРМӘТЛЕ «БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ!

Егерменче гасырның 90 нчы елларында милли күтәрелеш чорында «Мирас» журналының беренче саны дөнья күрде. Бу милләтебез өчен бик мөһим вакыйга иде. Заман белән бергә атлап барган басма бүген үзенең 25 еллыгын «Безнең мирас» дигән исем астында бәйрәм итә. Сезнең журналның кабатланмас үз язу рәвеше, үзенең кыйбласы бар. Язмаларыгыз халкыбызның тарихын барлау белән генә чикләнми, аның мәдәниятен, сәнгатен пропагандалау буенча да игелекле эшләр алып бара. Бүгенге көндә «Безнең мирас» журналы динамик үсештәге басма.

Редакция коллективына һәм авторларга иҗади рух, гомумкешелек кыйммәтләренә тугрылык, киләчәккә омтылыш хас. Сез бүгенге көндә үрнәк булырлык эшләр башкарасыз. Халкыбызның тарихын барлау, эшкә чын күңелдән бирелгәнлек, энтузиазм, иң мөһиме - хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгы, «Безнең мирас»ны файдалы һәм милләт өчен бик тә кирәкле журналга әверелдерде. Киләчәктә дә тоткан кыйблагыздан тайпылмассыз дип ышанам.

Барыгызны да «Безнең мирас»ның юбилее белән ихлас күңелдән котлыйм, милләтебезнең киләчәген кайгыртып яшәвегезне телим. Сезгә иҗади уңышлар, ныклы сәламәтлек, гаилә бәхете юлдаш булсын. Татар халкының үткәнен, бүгенгесен, киләчәген дөрес яктыртучы булып калыгыз!

Р.З.ЗАКИРОВ,
Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе

МӨХТӘРӘМ ЛӘБИБ ӘФӘНДЕ ЛЕРОН ҺӘМ «БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ!

Милләттәшләрем, дин кардәшләрем!

Сезне ихлас күңелемнән «Безнең мирас» журналының 25 еллыгы уңаеннан котлыйм һәм әлеге саллы матбаганың киләчәктә дә укучылары даирәсен арттырып, уңышлы эшләвен телим. Тормышларын татар тарихы, әдәбияты, сәнгате мирасын барлау һәм шуларны халыкка кайтаруга багышлаган мөхәррирләргә һәм редакция хезмәткәрләренә сәламәтлек, тынычлык, гаилә бәхете, иҗади уңышлар телим! Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә һәр изге эшегездә сезгә Үзе ярдәмче булып, теләк-морадларыгызга ирешергә насыйп итсә иде! Амин.

РАВИЛ ГАЙНЕТДИН,
Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Россия мөфтиләр Шурасы рәисе, мөфти шәех

КӨТЕП АЛГАН БАСМА

Хөрмәтле дуслар!

Милләтебез өчен истәлекле вакыйга – «Безнең мирас» журналының 25 еллыгы уңаеннан сезгә ихлас котлавымны җиткерәм!

Чирек гасыр эчендә журнал татар халкының көтеп алган басмасына әйләнеп, дистә меңләп мирас ядкярен дөньяга чыгарды.

Шушы дәвер эчендә журнал, үз мәсләгенә тугры калып, халкыбызның бер мең дүрт йөз елга якын тарихын күтәреп, аның үзенчәлекле рухи дөньясын, хыялларын, уй-фикерләрен чагылдырып, милләтебезгә игелекле хезмәт күрсәтеп килә. Бу юнәлештә башкарыласы эшләрнең бихисап булуын искә алсаң, әле юл башында гына торуыбыз күзаллана.

Хөрмәтле дуслар!

Киләчәктә дә озак еллар буе үзара хезмәттәшлек итәргә, республикабыз һәм халкыбыз өчен зур эшләр башкарырга насыйп булсын. Сезгә сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калам.

И.И.ШӘРИПОВ,
«Татарстан Халыклар дуслыгы йорты» директоры,
ТР Дәүләт Советы депутаты

ХӨРМӘТЛЕ «БЕЗНЕҢ МИРАС» РЕДАКЦИЯСЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ!

Татарстан фәннәр академиясенең тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре һәм шәхсән үз исемемнән татар халкының кадерле, мәртәбәле, милли журналы оешуга 25 ел тулу уңае белән ихластан тәбрик итәм!

Тарихи, әдәби, сәнгати, рухи, әхлакый, дини мирасыбызны халыкка кайтаруны төп максаты итеп билгеләгән «Безнең мирас», галимнәребез белән берлектә, чын мәгънәсендә тирәнтен эзләнүләр алып бара, яңа ачыш-табышларны киң катлам укучыга җиткереп, ана телебезне, мәдәниятебезне саклауга һәм үстерүгә күп көч куя. Соңгы 25 елда Татарстан Республикасы яңа алым һәм заманча фикергә корылган гамәлләре белән дөньякүләм танылу алса, «Безнең мирас» бу елларда, киресенчә, ерак тарихта калган гасырларны иңләп, бүгенге уңышларыбызның нигезе йөз, мең еллар элек үк салынганын исбатлауда зур эшчәнлек башкарды.

Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк, ди халык. Без — мираслы халык! «Безнең мирас» журналына алга таба да үткән белән киләчәкне тоташтыра торган күпер вазифасын башкаруын телим!

К.М.МИҢНУЛЛИН,
Институт директоры, профессор, ТФАнең мөхбир әгъзасы

ХӨРМӘТЛЕ «БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ, МАТБУГАТ ВЕТЕРАННАРЫ, ХӘБӘРЧЕЛӘРЕ!

Мамадыш муниципаль районы һәм шәхсән үз исемемнән барыгызны да журналның 25 еллыгы белән ихлас күңелдән тәбрик итәм.

Татарстанның яңа тарихы белән бер яшьтә булган, халкыбызның бай мирасын таныткан журналны безнең райондашлар да бик яратып укый. Тарихи, әдәби, сәнгати, рухи, әхлакый, дини мирасыбызны халыкка кайтаруда Сез биниһая зур хезмәт куясыз, бөтен укучыга да аңлаешлы фәнни-популяр телдә язарга, киң халык катламына үтеп керергә омтыласыз. Журнал битләрендә дөнья күргән уникаль, уйландырырлык, гыйбрәтле язмаларны башка җирдән эзләп табып булмый. Актуаль темаларны күтәрүегез, аларны оста ачуыгыз, матбугатның тәэсирле сүзе аша кешеләргә ярдәм итәргә омтылуыгыз өчен олы хөрмәт хисләремне җиткерәм. Сыйфатлы кәгазьдә, төсле фотолар белән чыгарган иҗат җимешен кулга алулары күңелле. Югары һөнәри осталыкка ия иҗади коллективыгызның тырышлыгы нәтиҗәсендә татар халкын матбугат мәйданында танытучы заманча басмага әверелдегез.

Сезгә чын йөрәктән исәнлек-саулык, иминлек, иҗади уңышлар, журналның алга таба да укучыларның тирән мәхәббәтен яулавын, тагын да камилләшә баруын телим.

А.П.ИВАНОВ,
Мамадыш муниципаль районы хакимияте башлыгы, район Советы рәисе

«БЕЗНЕҢ МИРАС»НЫ ЯРАТЫЙК!

«Безнең мирас»ка – 25 яшь. Чирек гасыр үтеп тә киткән. Бу дәвер эчендә күп әйберләр үзгәрде, журналның хәтта исеме дә алышында, әмма аның асылы сакланып калды. «Безнең мирас» журналы татар халкына, Татарстан Республикасына хезмәт итә. 1990 елларда оешкан журнал бүген дә актуальлеген югалтмый. Бу, басмада Төрки каһанлыгы, ислам дине, Болгарстан, Алтын Урда, Казан ханлыгы һәм татар халкының урыс дәүләтендәге, Советлар чорындагы язмышы, хәзерге тормыш яктыртыла, авыллар тарихына игътибар ителә. Татарны авыл милләте, дип тә әйтергә була, чөнки XVI гасырдан соң безнең яшәешебез, гореф-гадәтләребез нигездә авылларда

– Казан арты, Тау ягы, Каманың аръягында сакланган. Башкортстан, Урал буе һәм Евразиянең башка төбәкләрендә дә бай мирасыбыз бар. Журнал татарның Идел-Урал буена, читтә яшәгән урыннарына һәрдаим игътибар итеп, мәкаләләр чыгарып тора. Татарстан галимнәре, Бөтендөнья татар конгрессы белән берләшеп, авыллар тарихын өйрәнә башлады. Бу эштә дә «Безнең мирас» журналының өлеше гаять зур, аның сәхифәләрендә шул уңайдан оештырылган конференцияләр, «түгәрәк өстәл»ләрдә яңгыраган чыгышлар, мәкаләләр даими басыла.

Журнал хезмәткәрләрен, укучыларын 25 еллык бәйрәм белән ихлас күңелдән котлыйм. Алга таба да бергә булыйк, мирасыбызны өйрәник, журналга язылыйк, «Безнең мирас»ны яратыйк!

АЛЬБЕРТ БОРҺАНОВ,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты галиме

ТЫЛСЫМЛЫ БАЙЛЫК САНДЫГЫ

«Мирас» журналы – татар-төрки галәменең якты йолдызы! Аны күпме укысаң да, укыйсы килә. Мин «Мирас» журналын мендәр астына салып йоклыйм һәм миңа хәзер бик тә матур төшләр керә. Баштарак атлар кешнәве, паровоз, каз-тавык тавышлыры... аннары – муллалар авазы... Хәзер күңел урынына утырды. Рәхәт.

Бөтен коллегаларыма мин, күңелемнең иң тирән түреннән, шундый гүзәл, халык өчен бик кирәк, тылсымлы байлык сандыгын тудыруда нык тазалык, саф күңел, якты чырай, тугрылык теләп калам һәм Ходайдан Сезгә бәхет сорап торырмын!

Бәйрәмегез котлы булсын!

НӘСҮР ЮРУШБАЕВ,
журналист, кинорежиссёр.
Алмания, Лейпциг

***Ленар Гобәйдуллин** һәм **Лилия Гаделшина** фотолары.* ■

Болгар. Икмәк музее

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

2012 елның 21 маенда Болгарда «Икмәк музее» музей-туристлык комплексы ачылды. Ул Татарстан җирендә иген игү һәм икмәк пешерүнең борынгы заманнардан бүгенге көнгә кадәр тарихын күрсәтеп тора. Музей комплексында игенчелекнең иген үстерүдән башлап ипи пешерүгә кадәр бөтен циклы чагылдырыла, татар авылы колоритын саклаган хәлдә болгарларның һәм Казан татарларының көнкүреше һәм хуҗалык итү үзенчәлекләре күрсәтелә. Гомуми мәйданы – 5 гектар тирәсе.

Икмәк музее составына төп экспозиция, җил һәм су тегермәннәре, тегермәнче йорты, амбар, ындыр табагы, икмәк пешерү йорты, тимерче алачыгы, һөнәрче осталарның сәүдә рәтләре керә.

Икмәк музееның төп экспозициясе үзәк бинада, 320 кв.метр мәйданда урнашкан. Биредә Татарстан халыклары тормышында икмәкнең ролен күрсәтүче экспонатлар куелган.

Төп экспозиция игенчелек һәм икмәк җитештерүгә бәйле матди һәм рухи культураның үсеш тарихы, милли традицияләр, Татарстанның данлыклы игенчеләре династияләре белән таныштыра.

Бронза, борынгы тимер дәверләренә һәм борынгы урта гасырга караган уникаль экспонатлар беренче игенчеләр узган катлаулы юлны – таяк көрәктән һәм китмәннән башлап сукалы игенчелеккә кадәр чорны күрсәтеп тора.

Авыл хуҗалыгы эшләренең төрләре агрономия өлкәсендәге белем, игенчеләрнең күнекмәләре эволюциясе белән бергә, коралларның һәм техниканың кул җайланмаларыннан, җигүле кораллардан машиналарга кадәр үсеше аркылы күрсәтелә. Икенче зал Татарстан территориясендә икмәк җитештерүнең борынгы заманнардан башлап XXI гасыр башына кадәр тарихы белән таныштыра. ■

ЗӨЛӘЙХА*

Әзһәр Мөхәммәдиев

«Ага-Базар».
Б.Урманче рәсеме

Бибарс чыгу белән, шуны гына көтеп торган вәзир Баян, ишекне ачып, эчкә керде һәм үз урынына узды. Патша, үзен борчыган уйларын дәвам иткәндәй, сөйләп китте:

– Чыңгыз, Хәрәзмне кылычлаганнан соң, фарсы ягына баскынлык итәр өчен чирү җыя, ә аның баһадиры Сүбәдәй Каф тавы халыкларын талый. Аларны талаганнан соң, ул шәһри Болгар урынына арпа чәчтерергә җыенмыймы икән? Әллә Сүбәдәй чирүе генә ул кадәр куркыныч та түгелдер, вәзир? Ни дисәң дә, Болгар чикләре шактый сакка алынган бит. Аның Болгар йортын читләтеп кенә үтеп китүе мөмкин ләбаса!

– Ил коты, – диде Баян ихтирам белән, – әлбәттә, Сүбәдәй чирүе элмәгә[1] генә җибәрелгән дип саныйк. Әмма ул җитәрлек кадәр ишле булырга тиеш кебек. Чыңгыз хан, белүемчә, җилбәзәк бер гаскәр җитәкчесе генә түгел. Үзләре бик күп булмасалар да, ишләре, мөгаен, көчләп тупланган уйгырлар һәм кыргызлар булыр. Алар, чаралары калмагач, каршылык та күрсәтеп тормыйча, күптән үк мангуллар ягына авышты-

* «Зөләйха» – 2 нче саннан (2016) бирле чыгып килгән «Чыңгызхан хәйләсе» әсәренең дәвамы.
[1] Элмә – алдан җибәрелгән хәрәкәтчән гаскәр.

лар. Чыңгыз үз җайдакларын хәтәр эшкә тәвәккәлләп, чирүен куркыныч астына куя торган җитәкче түгел. Сүбәдәйнең мангуллардан торган чирүе генә дә, юк дигәндә, бер утыз меңлек булыр. Ә читләтеп үтүгә килгәндә исә, әфәндем, мангуллар үзләре тарафыннан бер таланган җирләрдән кат-кат яңадан йөрергә яратмыйлар. Сүбәдәй Каф тавыннан гына борылырмы, йә булмаса, Аладимер кенәзлегенә бәреп кергәннән соңмы, ләкин ни генә булмасын, барыбер Болгар йорты көчен сынап караячак, чөнки бу аның элмәсенең төп вазифасы булырга тиеш. Дөрес, Аладимердан башка да урысларның кенәзлекләре җитәрлек, мангулларның авызлары пешүе дә мөмкин...

– Мөмкин хәл түгел, пешмәс, дип уйлыйм, чөнки бердәйлек юк. Һәр урыс шәһәрендә башбаштак кенәз утыра, ә инде бик яхшы коралланган шәһәрнең дружинасы да мең кешедән артмый. Ә Сүбәдәйнең элмәсе исә, әйткәнеңчә, аз дигәндә, утыз меңнән дә ким булмас, дип сөйләштек. Чыңгызның яхшы өйрәтелгән уланнар кебек үк сугышларда чыныккан нойоннары бар. Димәк, Сүбәдәйнең сугыш чукмарлары Болгар йортына һөҗүм итмичә генә Туранга кире кайтып китмәячәк. Монысына без һәрьяктан да әзер булып торырга тиеш. Шуңа күрә дә мин, Сүбәдәйгә илче җибәреп, безгә аның кая таба юл тотарга җыенганлыгын алдан ук белеп, һичьюгында, чамалап булса да тора алырбыз, дип уйлыйм...

– Ил коты, мин Машаектан[2] килгән атчабар аша бу турыда хәбәр биреп торырга куштым.

– Саксин әмире яки Машаек әмире Басман, бәлки, хәбәр дә биреп торыр иде, тик аңа бит башта үзенең хәбәрдар булуы шарт. Ул үзе дә безнең кебек үк яңа хәбәргә мохтаҗ. Ә без җибәргән илче исә, һәрхәлдә, Сүбәдәйнең станында була алыр, дип ышаныйк.

– Кызыксынырга яраса, мондый мөһим эшне патша галиҗәнаплары кемгә тапшырырга уйлый?

– Әлбәттә, синең егеткә. Үткен акыллы, кыю һәм зиһенле, тырыш егет. Башкарып чыга алыр, дип уйлыйм. Чын, зур илчелек турында җитди итеп сөйләшү дә мөмкин түгел, вакыты ул түгел, тар.

Баян патшага гаҗәпләнүен яшерә алмыйча карады:

– Ил коты, Сүбәдәй баһадирның бурычы – илчелек кабул итү булмыйча, төрле халыклар яки илләрнең көчен сынау, аны ачыклау. Егетне әйтәм, артык яшь бит, җитмәсә, бу коточкыч куркыныч йөкләмә дә...

– Бөтен Болгар иле җимерелергә торганда, нәсел-нәсәпсез бер кыпчак егетенең тормышын куркыныч астына кую зыянлы булмас. Урап кайта алса, һичшиксез, файдасы тияр, кайта алмаса, һәлак булса, инде язмыш шулай язгандыр дип, дога кылырбыз...

***

Ул төнне Бибарс бик озак йоклый алмыйча уйланып ятты. Беренче карашка башта бу бурыч аңа җиңел генә булып күренгән иде. Уйлана торгач, ул аның җаваплы гына булып калмыйча, гаять куркыныч та икәнлеген аңлады. Көндез башыннан кичкән хәлләрне, сөйләшкән сүзләрне тагын бер кат күз алдыннан кичерде.

Патша белән сөйләшкәннән соң, ул вәзир Баянны көтеп торды. Бибарс патшаның аны илче итеп җибәрүе турында сөйләгәч, ул:

– Яңа гына әлеге хәбәрне солтан авызыннан ишеттем! – диде.

[2] Машаек – IX йөздә үк барлыкка килгән Әстерхан шәһәре.

Ул киң маңгаен җыерып, уйлана төшеп, сагышлы күзләре белән Бибарска таба борылып, беренче күргәндәй, игътибар белән карады.

– Аптыраган үрдәк койрыгы белән күлгә чума, дигәне шушы була торгандыр инде аның, – диде ул. – Әлбәттә, патшаның мондый карарга килүенең сәбәбе бар. Кичә Саксин атчабары куркыныч хәбәр китерде. Сүбәдәй баһадир Каф тавы итәгендә булган бәрелештә аланнарны һәм кыпчакларны пыран-заран китереп туздырган. Хәзер аның җайдаклары яраларын дәвалый, яңадан юлга әзерләнә. Аның тагын кайсы якка таба баскыннарын җибәрәчәген бер Алла үзе генә белә. Әлбәттә, безгә дә моны белеп тору бик мәслихәт булыр иде. Мин үзем хәл-әхвәлне Саксин яки Машаек атчабарлары аша белеп тору ягында идем. Патша, күрәсең, махсус илче җибәрү юлын кулай тапкан. Әлбәттә, кеше җибәреп хәлне ачыклап, белеп тору ышанычлырак. Тәҗрибәле илче күбрәк күрә. Ләкин кайбер эшләрне уйлап эшләр өчен вакытның үзенә дә вакыт бирү кирәк! Менә шул вакыт дигәне бездә юк диярлек, бөтенләй аз.

– Ярар, борчылмагыз, остаз! Берничә көндә барып җитәрмен мин анда.

– Куркыныч эш тә бу, Бибарс, дөресен әйтим. Сүбәдәй баһадирның вазифасы илчелек кабул итү түгел, ә күзәтчелек итү, мөмкин булса, көче җитсә, басып алу. Әй-йе, куркыныч эш бу... – диде ул беркадәр уйланып торганнан соң. – Җаваплы да. Бу мөһим эшне җиренә җиткереп эшләү генә түгел, ә исән-имин яңа хәбәрләр белән әйләнеп кайту да тиеш!

Ул көнне төшендә Бибарс ат менгән килеш зур бер илчелек башында нindидер биек-биек таулар аша үтеп, Сүбәдәй станын юллап тапты. Сүбәдәй баһадир Бибарс килгәнне күреп һәм куркынып, аны үзенең тирмәсеннән чыгып, баш иеп каршы алды. Бибарсның гаҗәпләнүенә каршы, Сүбәдәй баһадирның йөзе таныш булып чыкты: ул әлеге дивана булып кыланып йөргән шымчының йөзе иде...

Икенче көнне иртән иртүк остазы Бибарсны уятып, аны үзе белән төрле сугыш кораллары эшли торган тимерчелеккә алып китте. Шәһәр эчендә урнашкан тимерчелек дигәне шактый озын һәм зур итеп таштан салынган остаханә булып чыкты.

Ишекне ачып керү белән, Бибарс остаханә һавасының бик эссе булуын һәм анда йөзләгән тимерченең «чак-чок» килеп тимер корал эшкәртеп ятуын күрде. Бер күрекче күреген бертуктаусыз басып, өрдерә-өрдерә, зур-зур, эре-эре имән күмере салынган учакны кыздырып торса, икенчесе исә кып-кызыл булып кызган озынча тимерне кыскыч белән тотып алып һәм сандалга куеп чүки-чүки, кылыч ясый. Өченче оста аны яңадан тагын кып-кызыл булганчы кыздырып, чиләктәге махсус сыекчага тыгып чыныктыра һәм корычка әйләндерә иде. Икенче урында исә, оста тимерчеләр матур гына итеп артык зур булмаган, ләкин чапсаң, муен өзәрлек сугыш балталары яки сөңге очлары, йә булмаса «тимеркән» дип аталган тимер калканны да тишә ала торган ук башлары ясый иделәр.

Әмир Баян, як-якка бик каранмыйча гына, уртага салынган такта идәннән остаханәнең аргы башына атлады. Ул анда барып җиткәч, такталары тыгыз итеп эшләнгән авыр ишекне берничә тапкыр эткәч кенә ачып эчкә керә алды.

Бибарс биредәге һаваның эссе генә түгел, ә түзә алмаслык кайнар булуыннан, ишек такталарының ни өчен шулай тыгыз итеп эшләнүен аңлады. Уртасында печән кибәне зурлыгы ниндидер мич торган әлеге серле бүлмә – «тимерлүк» дип аталып, анда осталар беркем дә белмәгән ысул белән тимерне эретеп, балта-кылыч ясау өчен югары сыйфатлы корыч алалар икән.

Баян остаханәдә озак тормады, тиз борылды һәм урамга чыккач кына Бибарска карап әйтеп куйды:

– Остаханә башлыгы Халлачбине юллап кергән идек без монда, тик ул үзе амбарчы да икән әле. Аннан сиңа юлга яхшы бер корыч кылыч алырга кирәк булыр. Кылыч тотканың бармы?

– Бар, әлбәттә. Әти мәрхүмнең кылычы кулдан төшми иде. Тик ул вакытта әле миңа кылыч бик авыр булып тоела иде...

– Ә кылыч куллану алымнарын өйрәтмәдеме соң әтиең? Сугыш алымын белмәс – алдан үләр, ди бит мәкаль.

– Без бит кирмәндә туып үскән балалар идек, остаз. Теге: «Тегермәндә туган тычкан күк күкрәүдән курыкмас», – дигән кебек, нәрсә-нәрсә, ә имән агачыннан ясалган ныклы кылычлар белән дөбер-шатыр китереп сугышып үскән малайлар без.

– Сугыш алымнарын да өйрәндегезме?

– Ничек кенә әле! Чөнки кирмәннән чыккан һәр егетнең диярлек хыялы, ул да булса, сугыш алымнарын яхшы итеп өйрәнеп, кирмән хезмәтенә урнашу, ә инде мөмкинлек булса, Мисырга, йә Сүриягә барып, мәмлүк булып хезмәт итү һәм кесә тулы акча белән аннан кире әйләнеп кайту иде.

Озакламый барасы җирләренә барып җиттеләр. Корал амбары дигәне остаханә кебек үк озынча итеп эшкәртелмәгән таштан салынган зур гына бер бина булып чыкты. Халлачби аларны якты йөз белән каршы алды. Күрәсең, ул Баян белән яхшы ук таныш иде.

Амбар эченә керү белән Бибарсның игътибарын җәлеп иткән нәрсә, ул да булса, дивар буйлап кат-кат итеп эшләнгән киштәләрдә һәм сәндерәләрдә яңа ясалган меңләгән кылычның тәртип белән тезеп куелган булуы җәлеп итте. Урыны белән шулай ук күп санлы тимер баш киемнәре – шишәкләр һәм төз озын агач саплы, очлары ялтырап торган сөңгеләр тезеп куелган иде.

Ә икенче бер урында идәндә шактый биек итеп өелгән һәм чәнечкеләре як-якка тырпаеп торган шайтан таягы башы зурлыгында ясалган тимер «керпеләрне» күреп, сораулы күзләрен остазына юнәлдерде. Баян, өемнән берничә тимер чәнечкеле «керпене» алып, Бибарска якынрак килде.

Ул кулындагы берничә чәнечкене Бибарсның аяк астына – идәнгә чәчте. Алар ничек кенә төшсәләр дә, һәркайсының үткерләп очланган бер чәнечкесе туп-туры өскә таба карап тора иде...

– Бу чәнечкеле тимер «керпеләрне» дошманның атлы гаскәре яуга ташланыр алдыннан җиргә – аяк астына сибәләр. Ул ничек кенә төшсә дә, өч аягында баскан килеш кала, ә бер чәнечкесе барыбер өскә таба карап торачак.

Бибарс аның берсенә итеге белән басып караган иде, остаз елмаеп куйды да:

– Ю-ук! – диде ул сузып, – бу керпеләр җәяүлеләр өчен түгел, ә дошман нукәрләренең атларын аяксыз калдыру өчен кулланыла. Үзең аңлыйсың, сугышта атсыз калган җайдак ул инде кылыч ризыгына әверелә.

– Ә бу казаннардагы кара май ни-нәрсә өчен?

– Бу Каф тавының җир катыннан алынган кара май гарәпчә «нафта» дип атала. Әнә теге казан янында өелгән кызыл балчыктан яндырып ясалган шарга охшаган савытларның эчләре буш түгел, ә кара май тутырылган. Авызыннан чыгарып куелган мамык пилтәсенә ут төртеп дошман ныгытмасына ыргытсаң, шар чәлпәрәмә килә һәм майга ут кабынып, сүндереп булмый торган янгын чыга!

Дәвамы бар ■

Каргалы казаклары

Рөстәм Әминов

(Оренбург өлкәсендәге Татар Каргалысы авылының 1798-1821 елларда казак станицасы буларак тарихы)

Тарих фәнендә Татар Каргалысы авылы байлар, сәүдәгәрләр, мәгърифәтчеләр яшәгән төбәк буларак танылган. Аның 1798-1821 елларда Оренбург казак гаскәриләренең станицасы булганын, составына тирә-яктагы 17 авыл да кергәнлеген күпләр белмидер, мөгаен.

1744 елның 25 февралендә Оренбург краеның наместнигы, казан татарларының, сәүдә эшләрен җәелдерер өчен, Оребург шәһәре янында төпләнергә рөхсәт сорап мөрәҗәгать итүләре турында доклад әзерли. Бу урын ерак булу сәбәпле, алар рекрут йөкләмәсеннән дә азат ителүләрен һәм мәчет төзергә рөхсәт бирүләрен дә үтенәләр.

Сенат фәрманы нигезендә, 1744 елның 13 мартында И.И.Неплюевка Казан губернасыннан эшчеләре белән 200 хәлле татар гаиләсен чакырырга рөхсәт ителә. Беренче килеп төпләнгән кеше Сәгыйть (Сәед) Хаялин һәм аның иптәшләренә, патшабикә Елизавета Петрованың 1745 елгы 8 август фәрманы нигезендә, Сакмар елгасы буеннан Пречистен ныгытмасына кадәр 64 мең дисәтинә җир, Оренбург шәһәреннән 18 чакрым ераклыкта, Югары Каргалы елгасының Сакмарга койган тамагында яшәр өчен урын бирелә. Шулай итеп, Сәед бистәсе, ягъни Татар Каргалысы авылы барлыкка килә.

Сенатның 1784 елгы 7 ноябрь фәрманы нигезендә, Сәед бистәсе посад, ягъни зур шәһәрнең чите булган, анда ратуша оешкан, шәһәр үзидарә системасы да гамәлгә кертелгән[1]. Бистәнең посадка әверелеп китүе анда яшәүче халыкны төп ике төркемгә бүлгән: бер тарафта сәүдәгәрләр һәм мещаннар яшәсә, икенче якта игенчеләр көн күргән.

Игенче халкы исә, 1787 елның 16 декабрендәге фәрман нигезендә, Уфа даими булмаган гаскәриләре составына теркәлә һәм башкортлар, мишәрләр кебек үк чик буйларына хәрби командировкаларга җибәрелә. Каргалылар чик буена якын гына яшәү сәбәпле (нибары 20 чакрым), чиратны сакламыйча, ешрак, аеруча гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан вакытларда, хәрби йомышлар белән китә торган булганнар. 1796 елдан аларны ерак җирләргә дә, гадәттә Моздок чигенә, кәрваннарны саклау һәм дөяләрне каршы алып, озатып җибәрү кебек эшләр өчен җибәрәләр.

Әмма моның белән каргалыларның матди хәле һич кенә дә яхшырмый, алар элеккечә игенчелектән кергән барлы-юклы табышка яши, нәтиҗәдә, крестьяннарның салым буенча бурычлары үсә: 1786-1792 елларда җан башына түләнергә тиешле сумма 17,5 меңгә, ә рекрут акчасы 24,5 меңгә җыела.

1792 елның 5 июнендә игенче татар-

Оренбург татар казаклары Морад һәм Шаһгали Кочуровлар

ларга мещан һәм сәүдәгәрләр катлавына язылырга мөмкинлек бирә торган фәрман басылып чыга. Шулай итеп, Сенат каргалылардан салым буенча бурычларын түләтеп бетерергә уйлый.

Татар Каргалысында яшәүчеләрнең санына килгәндә, 1795 елгы 5 нче халык санын алу мәгълүматлары буенча, авылдагы 1000 хуҗалыкта 9463 ир-ат һәм хатын-кыз яшәгән. Бу күрсәткеч Сәед бистәсенең заманы өчен шактый зур булганлыгы турында сөйли.

1798 елның 31 мартында император Павел Iнең фәрманы һәм Сенатның апрель аендагы карары нигезендә, каргалыларның 42 мең сумлык салым бурычы юкка чыгарыла, әмма хәрби хезмәттән баш тарту турындагы үтенечләре кире кагыла.

1798 елның 10 апрелендә Оренбург казак гаскәренә идарә итүнең кантонлы системасы кертелә. Тиздән Каргалыдагы крестьяннар мәсьәләсе дә хәл ителә. 1798 елның 25 июлендә Оренбург генерал-губернаторы О.А.Игельстром гаскәри канцеляриягә, Сәед посадындагы татарлар артта калалар, дип белдерә һәм мәсьәләне игенчеләрне Оренбург казаклары составына кертеп хәл итәргә куша. Шулай итеп, 4 нче кантонга кертелгән Каргалы станицасы оеша, аңа 2948 кеше языла, шулардан 1737 кеше, ягъни халыкның 58%ы хәрби эшкә яраксыз һәм кече яшьтә, ә 1211 кеше (ягъни 41,1%ы) хәрби хезмәткә сәләтле дип табыла.

Каргалы станицасы составына бистәдән 200 чакрым читтә урнашкан 17 авыл да керә. Алар: Айдар, Арслан, Балыклы, Бигәнәш, Булгак, Югары Кузлы,

[1] Шуны да искәртик: Каргалыда шәһәр үзидарәсе бик кыска гына вакыт эчендә булган. 1828 елда Сәед посадындагы ратушаны бетерәләр. Төп сәбәп – үзидарәдәге байгура-түрәләрнең урыс телен начар белүе. Ратуша бетерелгәннән соң, шәһәр сәүдәгәрләре һәм мещаннар Оренбург магистратына буйсына. Аларга үз старосталарын, хөкемдар, мал-мөлкәтне бәяләүче (оценщик) һәм утырыш вәкилләрен тәкъдим итү хокукы бирелә.

Түбән Кузлы, Кундрабаш, Стәрлебаш, Тәтер, Тәтер-Арыслан, Тәтер Ибрай, Өсле Тамак, Югары Чебенле, Түбән Чебенле, Яшергән һәм башка авыллар. Бу авылларга XVIII гасырның икенче яртысында нигез салынган. Каргалы станицасындагы 17 авылның 13е – Стәрлетамак өязенә, Югары һәм Түбән Кузлы, шулай ук Югары һәм Түбән Чебенле авыллары Оренбург өязенә кергән.

Каргалылар, чик буенда урнашкан казакъ кавеме белән урыс хакимиятенең үзара мөнәсәбәте начар булу сәбәпле, Оренбург казак гаскәриләре составына кертелгән. Звериноголовск крепостеннан алып Чиләбенең көньяк өлешләре, Каспий диңгезендәге Гурьев шәһәренә кадәрге каравыл чиге Оренбург түрәләренә куркынычсызлыкны тәэмин итәр өчен яңа көч-куәт эзләргә мәҗбүр иткән. Казакъ телен, дала халкының гореф-гадәтләрен бик яхшы белгән татарлар бу очракта иң яхшы кандидат булган.

Сәед казакларына генерал-губернатор гаять мөһим вазифа – Оренбург чик буен контрольдә тотуны йөкли. 1799 елның маенда казаклар белән идарә итү өчен Оренбург чик буе комиссиясе төзелә. Аңа солтан-хаким, ыруг башлыгын тәгаенләү, аерым кабиләләрнең күченү урынын билгеләү, дәүләт салымнарын җыю, җинаять һәм гражданлык эшләрен тикшерү, казакълар белән каршылыклы мәсьәләрне хәл итү кебек вазифалар йөкләнә. Әмма Оренбург чик буе комиссиясенең төп бурычы – казакъларның борынгыдан килгән ханлык хакимиятен юкка чыгару һәм төрки далада урыс дәүләтенең йогынтысын, Оренбург ведомствосын урнаштыру була. 1824 елда урыс хакимияте Кече җүздәге ханлык хакимиятен бетерүгә ирешә, шуннан соң солтан-хаким вазифасы кертелә, ә соңгы хан Шергазы Оренбургка яшәргә күчерелә.

Каргалы авылында станица идарәсе урнаша, аның белән хәрби старшина җитәкчелек итә башлый. Бу вазифага Хәбибулла Әхмәров, ә аның вәкилләре итеп Мостафа Мортазин белән Кадыйр Арсланов сайлана. Алар, берләшеп, «Каргалы казак станицасы вәкиллеге»н тәшкил итәләр, аның составына язу-сызу эшләре белән шөгыльләнә торган кешеләр дә кертелә. Шуның өстенә, каргалылар йөзбашларга һәм бишйөзбашларга да бүленә. Беренче бишйөзбашның җитәкчесе итеп полковник Гобәйдулла Рәхмәтуллин, икенчесенең – полковник Сөләйманов (исеме күрсәтелмәгән), өченчесенең – Габделмән Сәгыйтов тәгаенләнә.

Каргалы казакларының хәрби командировка өчен шушы киемнәре әзер булырга тиеш дип билгеләнә: 1) баш киеме; 2) чикмән; 3) кафтан; 4) шаровар (юка материядән тегелгән, биле һәм балак очы бөрмәле, озын, киң чалбар); 5) күн итекләр; 6) оек; 7) башлык; 8) тун; 9) кирәк кадәр эчке кием-салым. Шулай ук казакларның сөңге, мылтык, лядунка (атлы гаскәринең патрон сумкасы), кылыч белән коралланган булуы шарт. Атларга килгәндә, ике казакка өч ат каралган, аларның икесе казакның үзенә хезмәт итсә, берсе йөк ташу максатыннан файдаланылган. Кием-салым, атлар каргалыларның үз хисабыннан булган, корал, дары һәм кургаш казнадан бирелгән. Каргалы станицасындагы җинаять һәм башка төрле эшләрне станица вәкилләре үзләре хәл иткән, ә аеруча мөһимнәре хәрби канцеляриягә тәкъдим ителгән.

Татар Каргалысындагы кварталларның күп һәм шактый киң булуы сәбәпле (3 сәүдә һәм 6 казак), полиция казаклардан оештырылган. Аның берәр приставы, хөкемдары, полиция йөзбашы һәм язу-сызу эшләре белән шөгыльләнә торган кешесе булган. Һәр кварталда да надзиратель, йөзбашы, салкын коралларны чистарту остасы, десятник, төнге каравылчы билгеләнгән, шуның өстенә, һәр 30 йорттан дүрт кеше каравылда торырга тиеш булган.

Каргалылар Оренбургтагы татар казакларының санын ишәйтүгә үзләреннән зур өлеш керткән, алар,

«Ревизская сказка»да Каргалы авылында яшәүче казак татарлары турында мәгълүмат. 1816 ел

төрле җирләргә күченеп, татар авылларын арттырган. Каргалы татарларын башка җирләргә күчеп китәргә игенлек җирләре аз булу гына түгел, ә башка сәбәп тә этәргән – 1800 елда авылда көчле янгын булып, 220 гаилә йортсыз кала.

1800 елның 8 апрелендә Сәед бистәсендә җир биләмәсе, төзелеш һәм утын өчен агач аз булу, шулай ук чик буенда сак хезмәтен башкару һәм казакъ кавеменең һөҗүменнән саклану өчен, Оренбург хәрби губернаторы Н.Н.Бахметовка 70 гаилә каргалы казагын Сухарник елгасы буена – Чесноковкага күчерергә рөхсәт ителә. Күчүчеләргә хәрби кием-салым алыр өчен өч ел дәвамында ташлама ясала. Нәтиҗәдә, Чесноковкага барлыгы 187 ир-ат һәм 147 хатын-кыз күченә.

1801 елның 17 маенда Н.Н.Бахметов янгыннан зыян күргән Каргалы казакларына Никольский һәм Гирьял (татарлар Айгырҗал диләр) ныгытмаларына күченергә рөхсәт итә. Никольскийга китеп барган 105 гаилә (298 ир-ат), әлеге ныгытмадан 20 чакрым читтәге «Дөя тавы» аймагында төпләнә. Полковник Габделмән Сәгыйтов тәкъдим иткән исемлеккә күз салсак, күченүчеләр арасында 3 полковник, 5 язу-сызу эше белән шөгыльләнүче, 3 йөзбашы, иллебашлары, хорунжийлар һәм 28 отставкадагы 29-70 яшьлек түбән чинлылар булуы теркәлгән.

Гирьял ныгытмасына морза Арсланов нәселеннән 47 гаилә күченә (166 ир-ат). Каргалыдан түрә-кара, кече яшьтәгеләр, карт-коры һәм отставкадагы – җәмгысе 50 хуҗалык килеп төпләнә, аларның 250се ир-ат булуы теркәлгән. Күченүчеләргә станица башлыгын сайлау эше үз карамакларына калдырылган, ә килеп төпләнгәнче алар белән идарә итәргә Оренбургтан ике йөзбашы билгеләнгән. Аларга, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатыннан, ныгытмадан берникадәр читтәрәк мәчет тә төзергә рөхсәт ителгәнен чыганаклардан укып беләбез. Почта ташудан кала, бар-

лык хезмәтләргә дә өч ел ташламалар каралган.

Берникадәр соңрак, 1805 елда яңа оешкан Рычков станицасына да каргалылардан 50 хуҗалык күчерелә. Әмма 1821 елда аларны моннан кысрыклап чыгаралар һәм станицада нибары отставкадагы һәм кече яшьтәге 16 каргалы гына кала.

Каргалылар белән казакъ кавеменең үзара мөнәсәбәтләренә, дөресрәге, казакъларның каргалыларга китергән җәбер-золымына да тукталып үтәргә кирәк. 1800 елның 25 сентябрендә казакълар Каргалыдагы сәүдәгәрләрнең һәм казакларның 400 атын урлап китәләр, шуның өстенә ике казак көтүчесен дә әсир итеп алалар, ә өченчесе шляхта үтерелгән килеш табыла. Казакълар артыннан җибәрелгән каргалылар, явызларны тотып үч ала алмыйча, кире кайтырга мәҗбүр була. 1803 елның 9 декабрендә казакъ кавеменнән 30 кеше Чебенледән кайтып килүче полковник Булатовны, аның янындагы сәүдәгәр һәм эшчене кулга төшерә. Шулай да эшчеләрнең берсе җитез генә качып китәргә өлгерә һәм бу турыда станица идарәсенә хәбәр итә.

Әгәр дә без Каргалыда яшәгән казакларның хәрби командировкалары турында сөйләмәсәк, язмабыз һич кенә дә тулы булмас иде. 1799 елның апрель аенда Каргалы станицасының йөзбашы Гобәйдулла Кайсаров, казак дуслары белән Урта Кыргыз Урдасыннан берничә депутатны озатып, Санкт-Петербург каласына бара. 1798 елның 18 октябрендә булган хан сайлауларына тәртип сагында торучы гаскәрнең куәтен арттырыр өчен, Каргалы станицасыннан иң яхшы 500 казак Оренбургка җибәрелә. Күрүебезчә, каргалылар, чик буен саклаудан тыш, полиция хезмәтен дә башкарган, шунлыктан аларның үз хуҗалыкларында эшләргә, иген игәргә вакытлары калмаган.

1810 елда Татар Каргалысы авылында яшәүчеләрнең саны 20 меңгә җитә. Алар, гадәттәгечә, мещан, сәүдәгәр, крестьян һәм казак булган. Шул елгы мәгълүмат буенча, авылда 9 мәчет эшләгән, шуларның җидесе – таштан, икесе агачтан салынган.

1816 елгы «Ревизская сказка» мәгълүматлары буенча, Оренбург өязенең Каргалы станицасында 446 ир-ат һәм 259 хатын-кыз казак яшәгән. Шулардан 698 кеше – татар милләтеннән, 2 урыс ир-аты һәм шул ук сандагы марҗа яшәгән. 99 кеше, халык санын алган вакытта армиядә булу сәбәпле, «Ревизская сказка»га теркәлмәгән. Бу вакытта Каргалы станицасында күпхатынлы ир-атлар да булган, андыйлар барлыгы – 9. Аерым алганда йөзбашы Дәүләтша Закиров (51 яшь), Хәбибулла Әхмәров (81 яшь), хорунжий Монасыйп Таһиров (36 яшь), гади казаклар Биккол Мөслимов (38 яшь), Мостафа Биктимеров (47 яшь), Мөхәммәт Сөләйманов (45 яшь), Сәгыйть Әбләҗев (67 яшь), Исхак Әминов (48 яшь), Сөләйман Усмановлар (48 яшь) икешәр хатын белән дөнья куган.

1812-1816 еллар арасында Каргалы станицасы таркалуга йөз тотып, аның халкы 9 нчы башкорт кантонына языла башлый. Шуның нәтиҗәсендә, Оренбург казак гаскәриләре составындагы каргалыларның саны нык кими.

Каргалы станицасындагы татар казаклары Оренбург һәм Сәед бистәсендәге мәдрәсәләрдә белем алган. 1810 елгы мәгълүматка караганда, Каргалының үзендә генә дә 8 мәдрәсә булган, шуларның икесендә татар укыган.

Оренбургтагы мәдрәсәдә 15 ир-ат мөселман гыйлем туплаган (анда барлыгы 27 кеше, шуларның 12се хатын-кыз булуы игътибарны җәлеп итә). Уку йортын типтәр ахуны Габдессәләм Габдерәхимов тәэмин итеп торган, уку да аның шәхси йортында оештырылган. Мәдрәсәдә ислам кануннары һәм дөрес итеп укырга-язарга өйрәтелгән. Шунда 8 яшьлек татар казагы Гыйсмәтулла Рәхмәтуллин да белем алган.

Татар Каргалысындагы мәдрәсәне мулла һәм мөдәррис Габдерахман

Мөхәммәт улы Шәрипов тәэмин итеп торган. Анда барлыгы 155 кеше гыйлем эстәгән. Мәдрәсә икегә бүленеп, беренче бүлектә 79 кеше, икенчесендә 76 кеше укыган. Дәресләр беренче гильдия сәүдәгәр Гобәйдулла Мөхәммәтрәхимов акчасына төзелгән таш бинада узган. Беренче бүлектә казак татарлары – мөгаллим Гомәр Әбҗәлилов (24 яшь), отставкадагы казак Сөләйман Акмәмәтов (20 яшь), Гали Әбҗәлилов (17 яшь), Шәфи Акмәмәтов (14 яшь), Мәһди Сәфәров (9 яшь), икенче бүлектә – Мөхәммәтрәхим Госманов (13 яшь), Исхак Салихов (12 яшь), Мөхәммәдьяр Рамазанов (10 яшь), Мөхәммәдьяр Бикчәнтәев (17 яшь), Габделфәнис Габделвахитов (8 яшь) булган. Ягъни казаклар барлык укучыларның 6,4%ын тәшкил иткән. Биредә дә гарәп, фарсы, төрек һәм татар телләрендә ислам дине кануннары, Коръән нигезләре өйрәтелгән.

Икенче мәдрәсә мулла һәм мөдәррис Габдерәшит Габделкәримов карамагында булган. Дәресләр аның агач йортында уздырылган. 43 шәкерт арасында казаклар – Исхак Абдуллов (61 яшь), Габделгаффар Зәбиров (35 яшь), Габделлатыйф Ихсанов (18 яшь), Солтан Мусин (45 яшь) – барлыгы 4 кеше (9,3%).

1819 елның 5 гыйнварында Оренбург казак гаскәриләренең Каргалы станицасындагы 467 кешене казаклыктан чыгару һәм аларны ясаклы итү, теләгән шөгыльләрен үзләре табу мөмкинлеге турындагы фәрман имзалана. Хәрби губернатор П.К.Эссен фикеренчә, моның төп сәбәбе, аның үз сүзләре белән әйткәндә: «...каргалылар гомумән хезмәткә яраксызлар, Оренбург гаскәренең санын файдасызга арттыру белән шөгыльләнергә теләмим...»

Шулай итеп, 1821 елда Каргалы казак станица идарәсе бетерелә. Каргалыларның күбесе Оренбург казак гаскәриләре составыннан чыгарыла һәм 9 нчы башкорт кантонына күчерелә. Шунысын да әйтергә кирәк: шулвакыттан әлеге казаклар архив документларында «башкорт» дип языла башлый, әмма аларның этник татар икәнлеге барыбызга да мәгълүм. 1821 елның маенда Каргалы станицасында нибары 53 казак ир-аты булуы теркәлгән.

Югары һәм Түбән Чебенле авыллары халкы да 9 нчы башкорт кантонына күчерелә, әмма 1842 елның 24 февралендә Югары Чебенленең 51 кешесе һәм Түбән Чебенленең 52 кешесе яңадан Оренбург казак гаскәренә теркәлә. Соңрак чебенлеләр тулысынча Оренбург казаклары сафына күчеп бетәләр.

Шулай итеп, Оренбург төбәгендә кантонлы идарә системасын гамәлгә ашырган елларда, Сәед бистәсенең крестьяннары һәм якын-тирә авыл халкы Оренбург казак гаскәриләре составына кертелә һәм Каргалы авылы нигездә мөселман татарларыннан гына торган станица үзәгенә әверелә. XVIII гасыр азагы-XIX гасыр башына Каргалы – тугыз мәчетле, Урал буе һәм казакъ даласында даны таралган мәктәп-мәдрәсәле авыл, Оренбург татарларының сәүдә һәм икътисади үзәге булган. Хәрби-йомышлылар сафына кертелү, һичшиксез, татар крестьяннарының социаль-икътисади хәлен яхшырткан. Җир җитмәгән очракта, мәсьәлә халыкны башка авылларга күчерү белән хәл ителгән.

Оренбург казак гаскәриләренең бердәнбер татар станицасы гомере кыска булу (1798-1821) шушылар белән аңлатыла: беренчедән, яңа гаскәри йөкләмәләргә күнегү өчен вакыт кирәк булган, бу эш белән шөгыльләнергә татарлар үзләре үк бик ашкынып тормаган, алар кушкан әмерләрне ихтыяри-мәҗбүри башкарган, каргалылар өчен сәүдә эше күпкә кызыклырак һәм табышлырак булган; икенчедән, казак даласында урыс хакимияте ныгу, тынычлык урнашу белән, Оренбург таможнясенә татар казаклары кирәк булмый башлый. ■

«Илдә финанс тәртибе бетте...»

Рәмзи Вәлиев

(Кәлимулла Вәлиевнең тормыш юлы һәм эшчәнлеге)

1960 елның сентябре. Мин, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты студенты, гадәттәгечә, Казаннан туган авылым Карашәмгә кайтышлый Албаба станциясендә төшеп, Төньяк Норлат районының башкарма комитетына юнәлдем. Анда әтием Кәлимулла район финанс бүлегендә баш бухгалтер булып эшли. Ул да район үзәгеннән һәр шимбә авылыбызга кайта. Әти – сугыш инвалиды. Шуңа күрә аңа бер ат көчле «машина» бирделәр.

Бүген дә сәгать биштән соң шушы атны җигеп кайтырга кузгалдык. Норлат авылын чыгып, ат арбасында акыртын гына әткәчем (без аңа шулай дип әйтә идек) белән сөйләшеп кайтабыз. Әти кайчак дилбегәне тарткалап алашага җан кертә, тау төшәбез, күперне чыгып янә югарыга үрмәлибез. Юл такыр. Алда – зур «рушша урманы» (рощадыр инде ул, халык аны үзенчә рушша диеп кенә җибәрә). Урман буйлап кайтуы нинди рәхәт, авыру әтиемә бу саф һава аеруча файдалы. Монда җиткәч, ул иркенрәк сөйләшә, кайвакыт җырлап та җибәрә. Күбрәк дөнья хәлләре турында сөйләшәбез. Әти авызыннан дәүләт, ил, вазгыять турында заманы өчен үтә дә кискен сүзләр ычкынгалый иде. «Бу дәүләт, улым, озак яши алмастыр...» – дип әйткәне дә исемдә. Әлеге көтелмәгән, хәтта куркыныч сүзләрне ишетеп: «Нигә шулай әйтәсең, әткәчем?» – дидем. Университетта КПСС тарихын, фәнни коммунизм, марксизм фәлсәфәсен укып, Никита Хрущевка ышанып, тиздән коммунизм булачагын көтеп йөргәнгә бу фикер шактый сәер булып тоелды. Ә ул бик тыныч кына: «Илдә финанс тәртибе бетте, улым», – диде. Әңгәмә шуның белән өзелде. Икътисад-финанс өлкәсе белән әллә ни кызыксынмаганга, артыгын төпченмәдем. Атыбыз, тау башына менеп җиткәч, шактый тиз юырта башлады. Әтием, дилбегәне тарткалап, атны тагын да алга әйдәде. Бәлкем ул миннән, университет студентыннан, ниндидер фикер дә көткәндер, ә мин ләм-мим, берни дәшмәдем, кырык ел чамасы әлеге сөйләшү турында бөтенләй онyттым.

Ул вакытта гап-гади студентка финанс тәртибе әллә ни кызык түгел иде шул... Әти дә бу темага башка кире кайтмады. Бары тик СССР дигән бөек дәүләт юкка чыгып, капитализм чоры илне кабат басып алгач кына ми күзәнәкләре уйлана башлады. Әтиемнең ярты гасыр элек әйткән сүзләре хәзер дә җанга һич тынгы бирми. СССР җимерелү-таркалу юлына 60 нчы еллар башында ук баскан икән, дип уйлап куям. Ул бик аңлаешлы һәм җитди итеп нәтиҗә ясый: «Илдә финанс тәртибе бетте», – ди. Хәзер исә

Кәлимулла Вәлиев хатыны Шәмсекамәр белән Казанда. 1930 ел. Әтием кулында апабыз Фәридә (1928). Әле дә исән.Әнием кулындагы Динә кечкенәдән мәрхүм булган.



О В Е Р Е Н И Е

сего тов. Валиев К.

сполкомом, в качестве его

Уташкинскому сельсовету по

енно-политических кампаний

товок, мобилизация средств и

..... предоставляется право

лекать к ответственности



1941 г.

В НАРКОМФИН ТАТАРСКОЙ АССР.

В Комиссию по рацпредложениям.

Копия: Нурлатский райфо Татарской АССР

тов. Валееву.

Посылаю для сведения выписку из протоко[ла]
Центральной комиссии по рацпредложениям от
за № 29 с решением по предложению т. Валеева
райфо/.

Кәлимулла Вәлиевнең «Ярыш» газетасында басылган фотосы. 1960 ел



Выписка из протокола совещания ... предложениям при НКФ ...

Постановили: Согласиться с заключением

\- 3 -

рацпредложениям при НКФ Тат...
сти дополнения формы № 3 ...
"остаток" и это предложение ...
НКФ СССР.

2. Предложение о дополнении ведомости ф. № 9 на выдачу зарплаты графой "должность", считать нецелесообразным, т.к. при проверке расходов по зарплате, ревизор должен пользоваться книгой лицевых счетов рабочих и служащих (ф. № 9), в которой имеются все необходимые для этого сведения, в том числе и "должность".

...ль Центральной Комиссии
...ацпредложениям
...ь Народного Комиссара
...нсов РСФСР - ГУСЕВ.
...арь Комиссии - КАРПОВ.
...ерно:



Кәлимулла Вәлиевнең иң соңгы фоторәсеме.

Россиядә генә түгел, ә бөтен дөньяда да финанс тәртибе юк. Ил-җиребезнең киләчәге ничек булыр? Монысы инде башка тема...

***

Кәлимулла Миңнулла улы Вәлиев (1904-1974) Яшел Үзән (элекке Төньяк Норлат) районының Карашәм авылында туып үскән. Инкыйлабка кадәр Шырдан авылындагы мәдрәсәдә җиде сыйныфны тәмамлап, 1917 елда «Мөхәммәдия»дә укый башлый. Казанны аклардан коткаргач, ул яшәгән тулай торакка әсир төрек солдатларын кертәләр һәм этием иң соңгылардан булып мәдрәсәне ташлап китәргә мәҗбүр була.

Ул болар турында безгә әллә ни сөйләмәде. Шулай да Гайнанетдин Вәиси үтерелгән көннәрдә мәдрәсәдән киткәнлеге турында әйткәне истә. Тарихтан мәгълүм ки, 1918 елның 1 мартында вәисовчыларның җитәкчесе Сәрдәр Гайнанетдин әл-Болгари үтерелеп, аның склад, штабларын туздыралар... Күрәсең, яшь егет шуларны шәйләп калган. Өйгә кайтып кергәч, бабабыз Миңнулла: «Улым, укуыңны ташлап нигә кайттың? Әллә тәмәке тарттыңмы?» – ди. Улы барысын да сөйләп биргәч, бабай тына, аны әрләми, соңрак этиемне биш чакрым ераклыктагы Урыс Әҗәле авылы мәктәбенә бирә. Ул анда урыс телен үзләштерә, тиз арада эшкә урнашу теләге дә туа. Әмма кая барып сугылырга?

1920 елларның башы – Татарстанда икетеллелекнең гамәлгә кергән вакыты. Бу эш Кәшшаф Мөхтәров хакимияте тарафыннан эшләнә, 1921 елда Татарстанда беренче суверенитет игълан ителә, рус һәм татар телләре дәүләт теле дип танылa. Татар телен, дәүләт теле буларак, хакимият органнарына кертү активлаша. Русларның да күпчелеге татар телен өйрәнүне хуплап кабул итә. Рәүф Сабиров дәүләт органнарын татарлаштыру эшен 1924 елда ук тәмамларга планлаштыра. 1923 елның июнь аенда Мәскәүдә РКП(б) ҮК тарафыннан оештырылган яшерен киңәшмәдә ул түбәндәгеләрне сөйли: «Бездә 51% татар, 40% урыс, 8% – калганнары... Кантоннарда татарлар күбрәк булганга күрә, татарчалаштыру авыр булмас. Без инде бу эшкә керештек һәм уңышларга да ирештек. 56 волостьта бөтен кәнсәләр эше татарчалаштырылды. 4 кантонда тәҗрибә уздырыла. Волостьларның бүлекләре халык белән аралашуны бары тик татар телендә генә алып бара. Шулай итеп, әгәр дә без актив рәвештә эш йөртсәк, бер ел эчендә татар телен бөтен волость һәм кантоннарга, Татарстанның үзәк учреждениеләренә дә кертәчәкбез». Рәүф Сабиров, коммунист һәм чын күңеленнән партиягә ихлас хезмәт итүче буларак, Үзәк комитетның, совет органнарының да бу өлкәдә булышачагына ихлас ышана. Алгарак китеп шуны әйтергә кирәк: әлеге яшертен киңәшмәдән соң Сталин тырышлыгы белән «солтангалиевчелек» тудырылып, Халык комиссарлары советы рәисе Кәшшаф Гыйльман улы Мөхтәров, аның фикердәшләре Рәүф Сабиров, Ариф Енбаев һәм башкалар эштән азат ителә. Кызганыч, 1921 елны башланып киткән суверенитетка 1923 елда ук «тәре» куела...

Шушы кыска гына суверенлык чорында татарның зыялы егетләре, ике дәүләт телен дә камил белгәнлектән, волость, кантон һәм үзәктәге дәүләт оешмаларына эшкә урнашып калды. Суверенитет ике телне, аеруча татарчаны яхшы белүче кадрларга ихтыяҗ тудырды. Менә шуннан файдаланып, минем этием Кәлимулла Вәлиев тә 1923 елны Урыс Әҗәле волостена күчереп язучы булып эшкә урнаша. Ул монда тиз арада абруй яулап ала. Яшь һәм булдыклы егетне Әрәгә (Тугаево) авыл

советы рәисе итеп җибәрәләр. Бу вакытта Әрәдә 979 хуҗалык булып, 1633 ир-ат һәм хатын-кыз яшәгән. Башка хуҗалыклардагы кебек үк әрәлеләр дә дәүләт капитализмы, ягъни Яңа икътисади сәясәт (НЭП) чорын кичерә. В.И.Ленин: «Эшчеләр хакимияте тарафыннан капитализмны кирәк дәрәҗәдә генә рөхсәт итеп, крестьяннар белән бәйләнешне ныгытып, аларда советларга ышанычны арттырырга кирәк. Крестьяннар Совет хакимиятенең алар файдасына хәрәкәтен тоеп торырга тиешләр. Әмма моны ничек эшләргә? Бу җәһәттән безнең тәҗрибәбез юк», – ди һәм аны бары тик практикада гына тормышка ашырып булачагын ассызыклый.

Совет хакимиятенең башлангыч чорында килеп туган бу мәсьәләләрне уңай хәл итүгә Вәлиев Кәлимулла Миңнулла улы да үзенең саллы өлешен кертә. Авылда туып үскән егет, яшь булуына да карамастан, теоретик яктан әзерлексез булса да, практикада шактый уңышларга ирешеп, Әрә халкын тынычландыра һәм үз ягына (әлбәттә, Совет ягына) җәлеп итүгә ирешә. Ул шунда эшләгән елларда игенче Низаметдин кызына, безнең булачак әниебез Шәмсекамәргә өйләнә. Әтиемне бөтен Әрә халкы ярата, ул биредә халыкны үз итеп, намус белән эшли. Аның тырышлыгын, халык арасында хөрмәт һәм ихтирам казануын Совет түрәләре дә чамалый. 1927 елда Төньяк Норлат районының Норлат дәүләт банкы инспекторы итеп эшкә чакыралар, бераз эшләгәч, Чаллы кантонының Камай волостена иминиятләү вәкиле итеп җибәрәләр. 1931 елның ноябрендә янәдән Норлатка кайтып, район финанс бүлегендә (райфода) инспектор булып эшли башлый. 1932 елдан баш бухгалтер вазифасын башкара.

1920 нче еллардагы Яңа икътисади сәясәт авыл халкына ирек һәм Совет властена ышаныч тудыра. Хуҗалыкта булган артык малны базарда сату мөмкинлеге барлыкка килә. Авылларга, крестьян хуҗалыкларына иң кирәкле товарлар кайткан: тоз, керосин, мануфактура, сабын, шырпы, кадак һ.б. Совет мәктәпләре ачылган. Нәтиҗәдә авылларда тормыш уңай якка үзгәрә. «Балалар туу артты, яңа йортлар төзелде, халыкның настроениесе үзгәрде», – дип язып калдырган Карашәм авылы егете Рәфгәт Абдюшев. Әлеге уңай үзгәрешләрне гамәлгә ашыруда, аеруча татар крестьяннарын акчалы, мал-мөлкәтле итүдә әтием Кәлимулланың тырышлыгы гаять зур.

Тормыш җайлана гына башлый дигәндә, 1922 елда көтмәгәндә авылда «кызыл әтәч» чыгып, йортыбыз янып китә. Гаилә авыр хәлдә кала. Әниемнең шул турыда әрнеп сөйләгәне исемдә калган. Инкыйлабка кадәр үк сәүдә эшен кәсеп итеп, Себер урманында старатель булып аз-маз алтын тупларга өлгергән бабам Миңнулла Вәлиев, тиз арада бик матур яңа йорт төзи. «Бабаңның ниндидер сабын кисәкләре бар иде», – дип әниемнең сөйләгәне исемдә. Ул шул алтын булгандыр инде... Без дә шушы иркен йортта алты бала үстек. Алга китеп шуны да әйтим: бары тик 1960 елларда гына әтием Кәлимулла көч-хәл белән кечкенә генә өй төзи. Шуның өстенә аның кредит акчаларын түләү өчен абыебыз Фәрит, Казакъстанның Җизказганына барып, шахтер булып эшләде. Ә инкыйлабка кадәр мал-мөлкәт туплап өлгергән, аннан соң гап-гади почтальон булып эшләгән бабам Миңнулла 1922 елда берүзе мәһабәт йорт өлгерткән. Бу шул еллардагы дәүләт суверенлыгының һәм Ленин нигез салган Яңа икътисади сәясәтнең күркәм бер нәтиҗәсе, дип уйлыйм.

Кәлимулла Вәлиев үз белемен күтәрү өстендә дә эшли: Бөтенсоюз

финанс-икътисад институтына читтән торып укырга керә. 1935 елда аны уңышлы тәмамлап, диплом ала, финанс эшен тирәннән аңлаучы югары белемле белгеч булып өлгерә. Әтием эшләгән елларда Норлат районы финанс бүлегендә бөтен проблемаларны хәл итәрлек профессионал коллектив туплана. Ул һәрвакыт еллык хисапны беренчеләрдән булып Казанга тапшыра. Шуңа күрә дә Финанс халык комиссары тарафыннан ел саен диярлек, ә кайбер елны хәтта ике-дүрт мәртәбә акчалата бүләкләнә. Менә шул хактагы боерыкларның берсе: «За досрочное составление бухгалтерских отчетов в полном объеме установленных норм и хорошего качества премировать Валеева К.М. деньгами 100 рублей». Шулай итеп, 1933 елның 13 апрелендә аңа бер айлык хезмәт хакы күләмендә премия бирелә. Бу әллә ни зур сумма булмаса да, ишле гаиләгә ярап куя.

Татарстан Финанс халык комиссариаты әтием белән даими кызыксынып тора һәм 1936 елның февралендә аннан үзе хакындагы документларын җибәрүен сорый. Шул ук елны ул «технический» һәм «деловая» аттестацияләр уза. Кәлимулла Миңнулла улы хезмәт дәверендә төрле органнар тарафыннан командировкаларга җибәрелә. Мөгаен, Норлат районының барлык авылларында да булгандыр ул. Әтиемнең шәхси архивында мандатлар, командировкага җибәрелү турындагы документлар сакланып калган. Таныклыкларның берсеннән күренгәнчә, ул 1931 елның мартында Өтәшкә авылына язгы чәчү, икмәк әзерләү, оештыру эшләрен башкару өчен, 1930 елның апрелендә исә туган авылы Карашәмгә колхозлаштыру эшләрендә булышу өчен җибәрелә. Шундый ук командировка белән Урысбага авыл советына да бара, әмма монда аңа акча җыю эшләрен җайлау өстенә буталчык цифрлар белән эшләү дә өстәлә. Моны ул профессионалларча үти һәм авылдагыларга практик дәрес биреп кайта. Шул ук елның июнь аенда, бишьеллыкның өченче елына багышланган заемга язылу проблемаларын хәл итү, бөтен мөмкинлекләрне мобилизовать итү мәшәкатьләре башлана. Менә боларны мөзакәрә кылу өчен ул авыл советы пленумы уздыра, анда колхозчы комсомол һәм коммунистлар актив катнаша.

Болардан башка әтиемә сайлаулар уздырганда да күп көч куярга туры килә. Мондый эшләр 1941 елда партиягә кергәннән соң тагын да арта. Шуны да әйтергә кирәк: бу вакытта инде ул авыл советларын гына түгел, ә югарыдагы җитәкчеләрне дә яхшы белә һәм аларга булыша, түрә-кара белән уртак тел таба, финанс өлкәсендә киңәшләр биреп, җиңелрәк юлларны булдыра. Әтием авылларга контролер буларак түгел, консультант, өйрәтүче булып килә, аеруча исәп-хисап эшен башкаручыларга, җитәкчеләргә катлаулы мәсьәләләрне чишү юлларын өйрәтә, финанс өлкәсендәге буталчыкларны булдырмас өчен көрәшә. Шулай итеп, ул «район үзеге уполномоченные» гына түгел, ә халык укытучысы кебек хәрәкәт итә. Финансист, бухгалтер һәм хисапчылар кыен хәлгә тарысалар, нинди инструкцияләр барын, үзгәрешләрне абайламый калсалар, төшенеп җитмәсәләр, еш кына «Кәлим абыйга» мөрәҗәгать итә торган булганнар. Гомумән алганда, ул кешеләрдән, авыл халкыннан, хуҗалыктан җитешсезлек-кимчелек эзләмәде, киресенчә, уңай факторларга таянып эш итте.

Иҗади хезмәт иясе буларак, әтием исәп-хисап, салым, контроль системасын үзгәртү мәсьәләләре буенча үз фикерләрен туплап, үзәк финанс һәм статистика органнарына да

Сулдан уңга: Бертуган Ринат, Хәмит, Рәмзи Вәлиевләр. 2014 ел

тәкъдимнәрен җибәреп тора һәм уңай хәбәрләр ала. 1941 елның 18 мартында аның салым өлкәсендәге тәкъдимен кабул итеп, СССР финанс органнарына файдалануга тәкъдим итәләр. Бу турыдагы чыганаклар аның тарафыннан бер папкага җыеп куелган.

1941 елның декабрендә әтием сугышка китә. Ул Казанда тупланган дивизия составында, Суслонгер аркылы үтеп, Смоленск якларына барып җитә. 1942 елның 12 декабрендә «Смоленск казаны»нда барган көчле сугышта ике аягы нык яралана. Аңа беренче ярдәмне күрсәтәләр, тылга озаталар, соңрак эшелон белән Себергә җибәрәләр. Әмма ул төрле юллар белән Казанда калуга ирешә һәм госпитальдә дәвалана. Беркадәр вакыттан әтиемне туган авлына кайтаралар. Монда инде төп «табиб» – әниебез Шәмсекамәр Низаметдин кызы булуы бәхәссез. Ул әтиемне гомере буе бик яхшы тәрбияләп тотты.

Әтием ун ел чамасы бик авырлык белән генә йөрде. Кайткан дәвердә җәрәхәтен ачып күрсәткәләде. Аннан кан, үлек агып торды, без шуннан сөяк кыйпылчыкларын чүпли идек. Вакыт – кешене терелтә. Акрын гына булса да, әтиебез ике култык таягы ярдәмендә, соңрак чатанлап, бик аксап хәрәкәт итә башлады. 1943 елның декабреннән 1944 елның декабренә кадәр район финанс бүлеген җитәкләде. 1945 елның октябреннән тугыз ай Казан госпиталендә ятты. Аннан кайтып, 1946 елның июнендә бюджет инспекторы вазифасына кереште. Аңа, сугыш инвалиды буларак, Казанда бушлай махсус аяк киемнәре тегеп биргәләделәр. Мотоколяскасы да бар, әмма аны инвалид түгел, сау кеше дә йөртә алмый иде. Энем Хәмит кенә әтине урманга яки су буена алып баргалады. Эшеннән бик тә хәлсез ат бирделәр. Аны җигеп юлга чыгу гаять куркыныч, без, малайлар гына, шактый газаплар белән булса да, Норлатка әтине алып барып, мәктәпкә китә идек.

Әти фронттан кайткач, шулпада азрак бәрәңге, умач күренә башлады. Аның кайтканын белеп, Норлаттан бераз бәрәңге һәм он да биргән булганнар икән. Соңрак әтиебез талоннарның

тиешледән азрак биргәнлекләрен, бу кара эшне аның дустының хатыны эшләгәнен дә белеп алган. Әтиебез кайтмаган булса, без исән калмаган да булыр идек... Сугыш һәм аннан соңгы елларда әнием һәм Фәридә апам алабутадан ипи пешерә. Ул ипи кара һәм әче була иде. Без урмандагы әкәләне, имән чикләвеген дә җыеп ашадык... Җәй көннәрендә капчыклап алабута, әчки, какы, кәҗә сакалы, ат кузгалагы һ.б үләннәрне дә җыйдык. Язын исә кырдан черек бәрәңге җыеп, аннан көлчәләр пешердек. Шунысы кызык: авыл халкы никадәр генә ач булса да, гөмбә җыймады, балык тотмады. Бары тик әсир немецлар күлебезне җәтмәҗылым белән сөзгәч кенә, балыкның күп икәнлеге беленде...

1945 елда бабабыз вафат булды. Шуны да әйтергә кирәк: әни бабайдан гомере буе «тел яшерде». Төрки халыкларда борын-борыннан килгән йола бу: киленнәр каенаталары белән сөйләшмәгән, «тел яшергән». Миңнулла Вәли улы үзенең соңгы көннәрендә генә әнигә: «Шәмсекамәр, минем тиз арада китеп баруым бар, бер утырып сөйләшик инде», – дигән. Шушы сөйләшүдән соң күпмедер вакыт узгач, бабай аңа үзенең киңәшләрен бирә, бал кортларын ничек карарга кирәклеген сөйли. Без авылда бердәнбер умарта тотучы гаилә – ипи-май булмаганда да, өстәлебездә бал булды. Әнием авыруларны, карт әби-бабайларны, күршетирәне дә баллы итте.

Бухгалтер, «райфо хуҗасы» астрономия белән дә кызыксына: Венера, Марс кебек планеталар турында бик белеп, яратып сөйли. Халыкка Кояш, Ай, планеталардан Җирнең ничә чакрым ераклыкта булуын, алардан безгә информациянең күпме вакыт узгач кына килеп җитүен аңлата. Без, балалар да, әтиебезнең Галәм турындагы «лекцияләрен» бик кызыксынып тыңлый идек. Әйтергә кирәк, бу мәгълүматларның күбесен физика-астрономия укытучылары да тәгаен генә әйтә алмый, ә Кәлим Миңнулла улы төгәл белә, чөнки финанс эшендә яхшы хәтер кирәк...

Әтием үз хезмәте, аның уңыш һәм проблемалары турында гадәттә әниебез белән генә киңәшә иде. Мин аның кычкырганын, безне орышканын бер дә хәтерләмим. Ул безне утын кисәргә дә көлеп-шаярып кына чакыра иде. Теләртеләмәс кенә эшкә тотынган малайлар, кызып китеп, 5 кубометр утынны кисеп-ярып куя идек. Ярылган утынны сарайга ташыйбыз. Ә аны тигез һәм матур итеп өеп куючы әтиебез. Кичке аш вакытында ул безне мактый: «Балалар, сез булмасагыз, мин ни эшләр идем?» – ди. Әтиебез мактагач, безгә канат үскән кебек тоела, шатланабыз. Күрәсең, ул оста тәрбияче дә булган. Аның максаты – балаларны эш, хезмәт белән тәрбияләү иде.

Әтиебез, район үзәгендә эшләгәнгә күрә, өйгә атнага бер генә кайтты. Аның белән өйгә ипи керә, кайвакыт кулга конфет, прәннек тә эләгә. Аллага шөкер, авылның башка балалары кебек без чабата киеп йөрмәдек. Дөньялар җайлана башлагач, сугыштан соң әти безгә ботинка-түфлиләр дә алып кайта башлады. Без исә укырга ябыштык...

1950 нче елларда әтиебез шактый рәтләнде, аксак булса да бирешми, күп эшли. Балалары да канатлана башлады. Кызы Фәридәне Чувашиянең Урмай авылына урыс теле укытучысы итеп җибәрәләр. Улы Фәрит, 10 классны тәмамлап, армия сафларына китә. Фәкыйрегез дә 1956 елны Вольск шәһәрендәге авиация училищесына укырга керә. Шулай итеп, әти-әнигә тагын өч баланы карыйсы кала. Альберт, Ринат, Хәмит мәктәптә укуларын дәвам итәләр.

XX гасырның 60 нчы елларын-

да әтиемнең яралары үзен ныграк сиздерә башлый, шуның өстенә – үпкә чире. Әмма ул бернигә карамый үз вазифасын төгәл итеп үтәвен дәвам итә. «Ярыш» газетасының 1960 елгы 18 август санында: «Иптәш Кәлим Вәлиев 30 елдан бирле инде район финанс бүлегенең баш бухгалтеры булып эшли. Ул коллективта намуслы эше белән үзен танытты, тыйнак һәм дисциплиналы работникларның берсе булып тора. Үзенә тапшырылган эшне төгәл итеп башкара», – дип язылган һәм әтиемнең фоторәсеме дә бирелгән.

Кәлимулла Вәлиев озак еллар эшләү дәверендә җитәкчеләр белән яхшы мөгамәләдә булды. Бары тик Төньяк Норлат районы бетерелер алдыннан гына алар белән араны бозды. 1960 нчы елларда җитәкчеләр шау-гөр итеп банкет ясау, күңел ачуларны практикага кертеп җибәрә. Баш бухгалтер аларга акча табып бирергә тиеш була. Күңел ачу өчен дәүләт акчасын туздыруны башына да китермәгән әтием, рәиснең кәеф-сафа өчен акча сорап язган кәгазенә: «На вашу пьянку подписываюсь в последний раз!» – дип имза куя. Үҗәтлеге сәбәпле, әтиемне тиз арада лаеклы ялга озатырга тырышалар. Рәис аңа: «Кәлим Миңнуллович, сез бик авыру кеше, персональ пенсия бирик», – ди. Әтием: «Юк, мин әле дәүләт акчасы сагында торачакмын!» – дип җавап кайтара. Шуның белән сөйләшү тәмам. Бәлки җимерелеп бара торган дәүләтнең акчасын сакларга кирәк тә булмагандыр, ә киресенчә, урларга, баерга һәм миллионер булып калырга... Әмма «Кәлим абый»ның андый гамәлне кылырга кулы күтәрелми.

1963 елда колхозларны берләштерү сәясәте башлана, Төньяк Норлат районы да Яшел Үзәнгә кушыла. Шулай итеп, әтиебез эшсез кала. Ул, Яшел Үзәнгә эшкә чакырсалар да бармаска булды, авылга кайтып, хезмәт хаксыз, пенсиясез бер ел өйдә, әнием, балалары тәрбиясендә яшәде. Ә банкетлар остасы булган район башкарма комитеты рәисе шат: «Кәлим абый» – дәүләт акчасын саклаучы эшсез калды... Ә үзе, соңрак эшнең тагын да «мактаулырагына» тотынды. Идел үзәнлегендәге гаять гүзәл урыннарны Казан түрәләренә, дус-ишләренә бүлеп дан казанды. Аның кебек башбаштаклар, инкыйлаб нәтиҗәләрен юкка чыгарып, илне кабат капитализм трассасына алып чыкты. Болай да социализм төзеп әлсерәгән халык яңадан карак байлар, фермер, бандитлар изүенә дучар буды. Ата-аналар, аларның балалары да бу тормыштан туеп, үз теләкләре белән бакый дөньяга күчте, авылда өйләнү, бала табулар азайды. Затлы сарай кебек урта мәктәпләр ябылып, алар урынына кәҗә абзарыннан да начар башлангыч уку йортлары гына калды.

1960 нчы елларда вак авылларны юкка чыгару, хуҗалыкларны берләштерү сәясәте, «финанс тәртибенең бетүе» үз нәтиҗәләрен озак көттермәде. 1990 нчы еллар башында ил тулысы белән таркалды... Әмма Кәлимулла Миңнулла улы боларны күрмәде. Ул 1974 елны Казанга кызы янына килгәч, кинәт вафат була. Без әтине авылга алып кайтып җирләдек. Аңа нибары 70 яшь иде.

Инде менә әтиемнең мәрхүм булуына да 45 ел узып китгән. Кәлимулла Миңнулла улы – үз заманының иң акыллы, тырыш, хезмәт сөючән, гадел һәм намуслы, авыр хәлдә калганда да югалып калмый торган баһадиры, көрәшчесе иде. Аның йорты Карашәм авылында әле дә бар, шунда ук – бакча, умарталык... Анда әтием кебек үк финанс органнарында эшләп, лаеклы ялга чыккан энем Ринат Вәлиев яши. Без монда һәр җәй саен кайтабыз. Үткәннәрне искә алып, әти-әни каберен зиярәт кылабыз... ■

АКЧУРИННАР МИРАСЫ

Якуб Акчурин йорты

Наил Таиров, Илһам Таиров

Ульяновск өлкәсенең Барыш районы Зөябаш авылындагы әлеге күркәм йорт, өлкән буын кешеләренең сөйләвенә караганда, Якубның әтисе Сөләйман Абдулла улы тарафыннан XIX гасырның уртасында ук төзелгән. Сөләйманның оныгы, күренекле сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе Йосыф Хәсән улы Акчура биредә туган, дип фаразлана.

Ике катлы агач йорт таш нигез өстенә салынган. Бүлмәләрдәге биек түшәм гүзәл орнамент белән, баскыч тотынгычы агачтан зәвыклы итеп юнып, барлык ишекләре һәм тәрәзә яңаклары имән агачыннан затлы итеп эшләнгән. Өйнең камин һәм фарфор мичен бүген дә күрергә мөмкин. Акчуриннар заманында йортның ишегалдында күптөрле хуҗалык корылмалары: баз, ат абзары, мунча һәм хезмәтчеләр өчен махсус өй дә булган. Йортның тирә-ягында төрле агач-куаклар үскән. Сөләйман вафат булганнан соң, йорт аның кече улы Якубка, ә ан-

нары оныгы Галигә мирас булып калган. Совет хакимиятенең беренче елларыннан ук биредә хастаханә эшләде. Авыл халкы исә әлеге бинаны, гасыр дәвамында медицина учреждениесе карамагында булуына карамастан, хәзер дә «Якуб бай» йорты дип йөртә.

***

Якуб – Сөләйманның икенче хатыны Мәхмүбҗамалдан 1854 елда туган кече улы. Аңа ун яшь тулгач, әтисе вафат була. 1870 нче еллардан фабрика белән Якуб идарә итә башлый. Аның төп бурычы: фабриканы чимал белән тәэмин итү һәм әзер продукцияне сату эшен оештыру. Еллар узган саен, фабрикада эшләр катлаулана, Якуб үзенә башкаларның ярдәме кирәклеген тоя башлый. Туганнан туган энесенең мәшәкатьләре Акчуриннар нәселенең мәртәбәле шәхесе Тимербулат Курамша улын битараф калдырмый. Шуның нәтиҗәсе буларак, Тимербулат һәм Якуб 1891 елның азагында «Акчуриннарның Зөябаштагы постау мануфактуралары ширкәте»н оештырып җибәрә. Гаиләнең мал-мөлкәтен саклап калу максатыннан булса кирәк, Якуб Тимербулатның кызы Мәргубәгә өйләнә. Аларның никахыннан телсез-чукрак Гали туа.

1892 елда Якуб туганнары Ибраһим һәм Исмәгыйль Курамша улларыннан Зөябаш янындагы юу корылмасын сатып ала. Шуның белән күпмедер дәрәҗәдә фабриканы йон белән тәэмин итү мәсьәләсе җайга салына.

Әлбәттә, туганнарның берләшеп ширкәт оештырып җибәрүе фабрика эшенә уңай йогынты ясаган. Шуның нәтиҗәсе буларак, XIX гасырның 90 нчы елларында Зөябаш постау фабрикасы Мәскәүдә оештырылган политехник күргәзмәдә алтын медаль, 1896 елда Бөтенроссия сәнәгать күргәзмәсендә бронза медаль белән бүләкләнә. Я.С.Акчурин башкаларның мескенлегенә, хәерчелегенә дә битараф кала алмаган. 1899 елгы ачлык вакытында, аеруча азык-төлек җитмәгән яз айларында, Зөябашта ашханә ачып җибәрә, анда айдан артык авылның ач-ялангач 55 баласы туклана. Акчуриннар үтенече буенча, «Кызыл хач» җәмгыяте дә авылга авыруларны дәвалар өчен студент медикларны җибәрә. Иганәче Санкт-Петербургтагы мөселман хәйрия җәмгыятенең дә хакыйки әгъзасы булган. Ирле-хатынлы Якуб һәм Мәргубә Акчуриннарның бай китапханәсендә татар, гарәп, рус һәм француз телләрендә басылган китаплар тупланган.

Якуб Акчурин 1903 елның 13 декабрендә 49 яшендә вафат була һәм Зөябаш авылы зиратында әтисе янына җирләнә. Аның каберенә кара мәрмәрдән затлы таш куелган.

Әтисе вафат булгач, фабрика һәм зур хуҗалык белән идарә итү эшен Гали үз өстенә ала. 1918 елның 15 ноябрендә фабрика хөкүмәт тарафыннан тартып алына, мәһабәт йорт та хакимият карамагына күчә. Гали һәм аның гаиләсе мал-мөлкәтсез, фәкыйрьмескен хәлдә кала. Башка туганнарыннан аермалы буларак, ул туган җирен ташлап китәргә ашыкмый, үз кул көче белән гаиләсен туендыра: эшчеләренең аяк киемен төзәтә башлый. Эшчеләр исә үзләренең элеккеге хуҗаларына төрлечә мөнәсәбәт белдергән: кемдер аны кызганган, кайберләре исә битараф кыланган, ә беришләре аны оятсыз рәвештә мыскыл иткән. Безгә Галине күреп белгән кешеләр, ягъни аның клиентлары белән очрашып сөйләшергә туры килде. Алар барысы да хәерче «бай»ның аяк киемнәрен төзәтү эшендә зур оста булганлыгы турында сөйләделәр.

Истәлекләргә караганда, Гали Акчурин илнең төрле почмагында яшәүче

Баскыч тотынгычы, балкон, тәрәзә йөзлеге агачтан зәвыклы итеп эшләнгән

Бер төркем татар газета-журнал мөхәррирләре Якуб Акчурин йорты янында. 2016 ел, июнь

туганнарына да барып йөргән. Мөгаен, бу аның үзенә яшәргә кулай урын эзләп йөрүе булгандыр. Шулай итеп, 1920 елларда Гали Зөябаш авылыннан бөтенләйгә чыгып китә. Танышбелешләре аны Казан, Мәскәү һәм Уфа шәһәрләренең базар, урам чатларында аяк киеме төзәтүче һәм слесарь буларак күргәләгән. Шулай итеп, Гали үзенең алтын куллары белән икмәклек акча юнәткән. Ул төзәткән самавырлар бик тиз арада яңа хуҗалы булганнар.

Марат Закир төтен юлын тикшерә

Бүлмәләрдәге биек түшәм гүзәл орнамент белән бизәлгән



***

Озак еллар Зөябаш, (Калны) Калда, Заречное, Акшуат халкына, килгән кунакларга медицина хезмәте күрсәтеп килгән участок хастаханәсе хәзерге вакытта ябык. Зөябаш авылының түгел, ә Барыш районының бай тарихлы, затлы, күркәм милли архитектура ядкяре бүген җимерелү, юкка чыгу алдында. Әлеге хуҗасыз йортны тарихи-мәдәни объектлар исемлегенә кертү, аны саклау, төзекләндерү кичектергесез актуаль мәсьәләләрнең берсе.

РЕДАКЦИЯДӘН: Зөябаш авылындагылар безгә бу йортка Габдулла Тукай да кунакка килгән, дип сөйләгән иде. Әмма Наил Таиров, бу мәсьәләне тарихи чыганаклар белән тикшерергә һәм расларга кирәклеге турында әйтте.

Фоторәсемнәр белән тулысынча һәм видеорепортаж белән beznenmiras.ru сайтыннан танышырга мөмкин.

Ленар Гобәйдуллин фотолары ■

Хөсрәү би язмышы

(Казан ханлыгы тарихыннан бер ләүхә)

Рәшит Галләм

«Костров князь» буларак, бу Казан биенең (кенәзенең) исеме рус елъязмаларында искә алына. Мәскәүнең XVI гасырда Нугай Урдасы белән мөнәсәбәтләренә бәйле, Илчелек кенәгәләрендә «Хостров князь» яисә «Хосров князь», дип тә бирелә. Күрәсең, аның асыл исеме «Хөсрәү» булган («Хөсрәү би» – «Хөсрәү кенәз»). Бу исем фарсы телендә «данлы, шөһрәтле» мәгънәсенә ия (мәсәлән, Хөсрәү атлы иң атаклы шәхесләрдән берсе – ул Шәрыкның легендар урта гасыр хакиме Хөсрәү Ширин).

Казан ханлыгы чорында Хөсрәү бинең биләмәләре («җәйге резиденциясе») Казаннан көнчыгыштарак, хәзерге Татарстан Җөмһүриятенең Питрәч муниципаль районына караган Шәехзадә авылында булган, күрәсең. Чөнки Казан өязенең 1565-1968 елларга караган җир-йортларны теркәү кенәгәсендә бу авылда «электә» (ягъни ханлык дәверендә) «Хөсрәү бинеке булган» йорт, каралты-кура теркәлгән («двор, что был Кострова князя»).

Шунысы кызык, Хөсрәү би урта гасыр елъязмаларында еш кына Казан ханлыгының икенче бер күренекле шәхесе Нургали Ширин (ул русча чыганакларда «Нур-Али Ширин» яисә «Муралей князь» дип бирелә) белән беррәттән искә алына. Соңгысы Казан алыныр алдыннан дәүләттә олы карачы (баш вәзир, дәүләт киңәшчесе) булып тора.

Бу уңайдан, күпчелек галимнәр аксөяк Ширинна ыруының көньяк-көнбатыш Җидесу өлкәсендәге Кашгар төбәгеннән чыгуын тәкрарлый. Ханлыкта тотрыклы бер традиция буларак, бу нәселдән булган аксөякләр (биләр – кенәзләр) гомер бакый ханлыкта олы карачы вазифасын үтәп килгәннәр. Әйтик, шул ук кенәз Нургали Ширинның әтисе Булат Ширин да, үз вакытында, Казан ханлыгында олы карачы (баш вәзир, дәүләт киңәшчесе) булып тора. Олы карачыдан тыш, дәүләттә башка карачылар да була (барлыгы дүртәү дип фаразлана).

Күрәсең, Хөсрәү би белән Нургали биләрнең тарихи документларда еш кына бергә телгә алынуы бер дә очраклы түгел. Беренчедән, бу Хөсрәү бинең, Нургали би белән беррәттән, дәүләттә карачы (әмир, дәүләт киңәшчесе) вазифасын башкаруы белән аңлатылса, икенчедән, аларның үзара нindидер бер туган-тумачалык мөнәсәбәтләрендә булу ихтималы да юк түгел. Гомумән алганда, карачы (вәзир, дәүләт киңәшчесе) буларак, Хөсрәү би Казан ханлыгының соңгы

Касыйм шәһәренең XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы күренекле сәүдәгәре һәм хәйриячесе Әхмәт Хәйрулла улы Кастров хатыны Хәдичә (ул Мәскәүнең Җамигъ мәчетенә нигез салучы сәүдәгәр Салих Ерзин кызы) һәм аларның уллары Хәсән. Мәскәү, 1897 ел

дәверендә дәүләттә иң күренекле, йогынтылы аксөякләрдән (кенәзләрдән) берсе була. Шул сыйфатта, Хөсрәү би («Костров князь») 1552 елда Казанны яулап алыну алдыннан булган катлаулы сәяси вакыйгаларда, ханлыктагы төрле феодал фиркаләрнең, идарәче ыру-төркемнәренең Казан тәхете өчен үзара көрәшендә катнаша.

Мәскәү дәүләтенең көчәюе, ханлыкны бертуктаусыз борчып, аның эчке эшләренә тыкшынып торуы шартларында, Казан аксөякләренең беришләре, вазгыятьне исәпкә алып, Мәскәү белән дустанә, протекторатлык мөнәсәбәтләре кору ягында булса, икенчеләре Кырым ханлыгына, аның артында торучы Госманлы Төркиясенә

таянып, Мәскәү экспансиясенә каршы тору фикерен алга сөрә.

Мөгаен, Хөсрәү бинең дә әле Казан алыныр алдыннан ук Мәскәү дәүләтендә пәйда булуы да әнә шул сәяси көрәш, ызгыш белән аңлатыла. Күренекле тарихчы-археолог А.Х.Халиков фаразы буенча, бу күченү 1550 елда була. Әмма чынлыкта елъязма чыганаклар аның Мәскәү дәүләтенә 1549 елның көзеннән калмый күченүен күрсәтә. Чөнки кайбер тарихи мәгълүматлар буенча, Хөсрәү би Мәдһиш (Явыз) Иванның Казанга 1549 елның көзге, шулай ук, 1550 елның язгы уңышсыз походларында катнаша.

Бу уңайдан шуны ассызыклап үтик, тарихи традиция буенча, бу чорда татар, нугай аксөякләре Алтын Урда мирасына бәйле барлык ил-җирләрне, шул исәптән Мәскәү дәүләте җирләрен дә, үз санап, бу киңлекләрдә дәүләттән-дәүләткә, хезмәттән-хезмәткә шактый иркен күченеп йөриләр. Шунлыктан, ул вакытларда Казан, нугай биләренең, мирзаларының, казакларының Мәскәү дәүләтенә хезмәткә күчүләре гайре табигый хәл булмый.

1551 елның августында Хөсрәү би («Костров князь»), Казан тәхетенә Мәдһиш (Явыз) Иван меңгергән Шаһгали, аның яраннары белән берлектә, яңадан Казанга кайта. Дәүләттә олы карачы итеп билгеләнгән Нургали, Ширин белән берлектә, карачы вазифасында тәгаенләнә.

Әмма Мәскәүнең экспансия сәясәте нәтиҗәсендә, бу вакытта инде Казан тирәсендә вакыйгалар шактый «куерган» була. Ихтыяри-мәҗбүри килешү нигезендә, 1551 елның маенда ханлыкның Тау ягындагы барлык җирләре Мәскәү кулына күчә. Шул рәвешле, Казан ханлыгы төньяктан һәм көнбатыштан Мәскәү дәүләте җирләре белән чолганып алына. Көньяк далалардагы нугай мирзаларының бер өлеше дә рус патшасы белән берлектә эш йөртә. Шунлыктан, Казан ханлыгы өчен үтә катлаулы вазгыять килеп туа.

Бу шартларда Казан аксөякләре, кискен рәвештә, Шаһгалидән Тау ягын киредән Казан ханлыгына кайтару өчен чаралар күрүне таләп итә. Әлеге юнәлештә берәр эш кылмаса, Казан тәхетендә утырып кала алмаячагын аңлаган Шаһгали шул елның көзендә Мәскәүгә махсус дәүләт илчелеген юллый. Олы карачы Нургали Ширин җитәкчелегендәге бу илчелектә хан сарае әһеле Шаһгаббас би Шамов, Галимәрдән хуҗа, Габдулла бакшы (язу-документ тутыру эшләрен алып баручы дәүләт сәркатибе) белән беррәттән, дәүләт карачысы Хөсрәү би дә була.

Мәскәүдә илчелекнең максатлары моннан гыйбарәт: 1) рус патшасыннан Тау ягын киредән ханлыкка кайтарып бирүне сорарга; 2) кайтарып бирмәсә, аннан Казан файдасына салымнар җыярга рөхсәт итсен; 3) рөхсәт итмәсә, аларның бер өлешен булса да җыярга мөмкинлек бирсен; 4) патша булачак килешүне үтәячәге турында ант итәргә тиеш.

Әмма теләкләре, үз-үзенә ышанычы арта төшеп, бу вакытта инде Казан ханлыгын шактый көчәеп киткән Мәскәү дәүләтенә кушарга ниятләгән рус патшасы бернинди ташламаларга да бармый. Сөйләшүләр өзелә, илчеләр Мәскәүдә тоткарлана. Үзе үк Казан тәхетенә меңгергән Шаһгали ханның көтелмәгән адымына ачуы чыккан Явыз Иванда, аны Казан тәхетеннән төшертеп, Мәскәүгә кайтарту планы туа. Шулвакытта Мәскәүгә Казанда Шаһгалинең үзенә оппозициядә булган 72 асыл затны (бертуган кенәз Бибарс, Җанбарс Растовларны һ.б.) массакүләм үтертүе турындагы хәбәр килеп ирешә. Ул Казан илчеләрен

зур пошаманга сала. Казанга әйләнеп кайткан очракта, алар үзләренең дә Шаһгали корбанына әйләнүләреннән куркалар. Чөнки, елъязмалар хәбәр итүенчә, Нургали Ширин белән Хөсрәү би дә Казанда үтертелгән аксөякләр белән бергә эш йөрткән.

Патша Мөдһиш (Явыз) Иванның алар белән бернинди сөйләшүләргә дә бармаячагын, ә Шаһгалине Казан тәхетеннән төшерергә ниятләгәнен белгәч, Нургали Ширин белән Хөсрәү би, хатыннары һәм балалары белән Мәскәүдә калдыруларын сорап, рус патшасына гарызнамә юллыйлар. Соңыннан шунда калып, рус дәүләтенә хезмәт итә башлыйлар.

Патша Мөдһиш (Явыз) Иван 1552 елның февралендә, Шаһгалине тәхетеннән төшерү максатында Мәскәүдән Казанга Алексей Адашевны юллаганда, Нургали Ширин белән Хөсрәү бинең Казан кешесе Тереул дуван аша «бөтен Казан җиренә» хат юллаулары да мәгълүм. Әмма бу хат тексты сакланмаган.

Алга таба Казан ханлыгының язмышы мәгълүм – 1552 елның мартында Шаһгали хан Казан тәхетеннән төшертелеп, Мәскәүгә кайтартыла. Шул ук елның 2 октябрендә (яңа стиль белән 12 октябрьдә) Казан рус явы тарафыннан алына, талана-бөлдерелә. Ханлыкта яшәүче халыклар (бигрәк тә татарлар, марилар) азатлык сугышына күтәрелү сәбәпле, Урта Идел буе биш елга диярлек сугыш хәрәкәтләре кырына әйләнә. Әмма бу инде тарихның башка сәхифәсе...

Хөсрәү бинең алдагы язмышы нинди булды икән соң? Әлегә бу хакта мәгълүматлар әллә ни күп түгел. Мәсәлән, разряд кенәгәләрендә «Казан кенәзе Костров»ның, Борнаш атлы икенче бер татар аксөяге, башка «иптәшләре», рус дворяннары белән берлектә, Мөдһиш (Явыз) Иванның Балтыйк буена (Литвага) оештырган 1557 елгы явында (Ливон сугышында) катнашуы теркәлгән. Шулай ук, Хөсрәү бинең баштарак, «иптәшләре белән берлектә», Түбән Новгород шәһәре тирәсендә урнашканлыгы-яшәгәнлеге ачыкланды. Соңрак (мөгаен, XVII гасырдан да калмыйча), аның варислары Касыйм шәһәрендә пәйда була.

Тора-бара, Казан кенәзе Хөсрәү бинең варислары православие диненә түнтәрелеп, руслашкан дворян һәм дворян сословиесенә кертелмәгән татар-мөселман нәселләренә тармаклана. Беренчеләре «Костров» фамилиясендә йөрсә (мәсәлән, алар арасында М.Җәлил ис. татар опера һәм балет театрының элекке прима-балеринасы Елена Юрьевна Кострованы атап үтәргә була), икенчеләре «Кастров» фамилиясендә мәгълүм. Соңгылары арасында да шактый танылган шәхесләр бар. Мәсәлән, XIX гасырның икенче яртысында – XX йөз башында яшәгән, кыйммәтле мехлар белән сәүдә иткән гильдияле сәүдәгәр Әхмәт Хәйрулла улы Кастров, үз вакытында, Касыйм шәһәрнең иң атаклы байларыннан, хәйриячеләреннән берсе була. Шулай ук, күпләр аның Мәскәүдә яшәгән кызын – Мирсәет Солтангалиев, Муса Җәлил, Салих Сәйдәшев кебек күп кенә күренекле татар шәхесләре белән аралашкан, 100 яшен тутырып, әле чагыштырмача күптән түгел генә бакый дөньяга күчкән җәмәгать эшлеклесе Рауза апа Кастрованы да хәтерлидер.

Гомумән алганда, Кастровларның нәсел тарихы үзе бер китапка лаек. Аларның бүгенге буын вәкилләреннән күбесе Мәскәү һәм Касыйм шәһәрләрендә яши. Шулай итеп, Казан ханлыгы чорыннан килгән Хөсрәү би кавеме әле дә исән, буыннар чылбыры өзелми... ■

ХАТ ЭЗЕННӘН

Рауза Бикколова: *«Бабаларым затлы кешеләр иде...»*

Редакциябезгә 96 яшьлек Рауза Мөхәммәт кызы Бикколова-Ганиевадан шундый хат килеп иреште:

«Әссәламегаләйкүм үә рәхмәтуллаһү үә бәрәкәтеһү, «Безнең мирас» журналы редакциясендә эшләүче кардәшләрем. Сезгә кайнар сәлам, иң изге теләкләр!!!

Мин – хезмәт һәм тыл ветераны, 1920 елда Буа районының Яңа Тинчәле авылында тудым. Хәзерге вакытта бертуган Бикколовларны күреп белүче исән кешеләрдән берүзем. Әтием Мөхәммәт – атаклы мәгърифәтче, язучы Касыйм һәм Ибраһим Бикколовларның бертуган энесе.

Минем сезгә өч шатлыгымны җиткерәсем килә. Беренчедән,«Безнең мирас» журналында бабаларым (Рауза апа күп туганнарына бабам, ди. – Ред.) Касыйм белән Ибраһим Бикколовларның һәм Гаяз Усмановның тәрбияви, әдәби һәм публицистик әсәрләрен һәрдаим бастырдыгыз һәм киләчәктә дә бастырырсыз, дигән өметтә калам. Рәхмәт сезгә! Икенче шатлыгым: ошбу елны Буа шәһәренә һәм Яңа Тинчәле авылына «Бертуган Бикколовлар» дигән китапны тәкъдир итү тантанасына чакырылып, абыйларым турында тарихи һәм биографик җыентыкны кулга алу бәхетен кичердем. Әлеге китапны төзегән галимнәрдән авылдашым Флюра Сәйфуллинага һәм Илһам Гомәровка, иганәче авылдашым Радик Гайззатуллинга, бәйрәмгә килгән язучыларга, якташларыма рәхмәтем чиксез зур. Өченче шатлыгым: туган авылым Яңа Тинчәледә узган гасырның 20-30 нчы елларына кадәр генә түгел, хәзерге заманда да белемле, талантлы, ихлас күңелле, үз милләтен сөюче, шәфкатьле якташларым, авылдашларым бар икән, дип шатланып, горурланып кайттым».

Хат бездә зур кызыксыну уятты: «Безнең мирас» журналын даими рәвештә укып баручы Рауза апа Ш.Мәрҗани һәм Р.Фәхреддиннәр хезмәтендә язылган затлы, зыялы шәхесләр – Бикколовлар турында ни- нәрсә хәтерли? Шул сорауга җавап эзләп, хатта күрсәтелгән адрес буенча Яшел Үзән шәһәренә юл тоттык.

Ибраһим Бикколов

Касыйм Бикколов

ӘТИЕМ ҺӘМ АБЫЙЛАР

Әтием Мөхәммәт 1924 елның сентябрь аенда вафат булган. Сандыкта алтын һәм көмеш ике сәгать бар иде. Әбием Маһиҗамал аларның әтиемә бирелгән бүләк икәнлеген әйтте. Аның сөйләвенчә, әтием 28 яшендә үлгән, әмма кыска гына гомерендә ул укытучы, җәмәгать эшлеклесе буларак зур казанышларга ирешкән.

Ызбабыз бик зур иде. Аның бер ягында без, ә икенче ягында әтиемнең абыйсы Хәмит яшәде. Ул укытучы, агроном, бухгалтер булды, тавыклар үстерергә бик яратты. Тавыкларны исемнәре белән атый иде. Йорттан чыгар да: «Җәүһәр, Зөбәрҗәт...» – дип кычкырыр, ә кошлар моның сүзен тыңлар иде.

Ибраһим – дәү абыем 1929 елда Казаннан авылга кайтты. Аның миңа пенал һәм шигырьләр китабы алып кайтканы исемдә. Бу абыемның 1938 елда юкка чыкканлыгы турында Шәрәф Байчура дигән журналист миңа: «Мин аның белән бергә утырган кешене күрдем. Ул кеше миңа Ибраһимны төнге 12дә алып чыгып китүләрен һәм бүтән аны күрмәүләре турында сөйләде», – диде.

Касыйм бабай белән янәшә яшәдек, аның йортына еш барып йөри идем. Ул Җамали бабай мәчетенең имамы булды. Аларның кечкенә генә ызбалары бар, мунчалары юк иде. Сыер асрадылар, атлары юк. Матур гына түбә астында җәй көне чәй эчүләре хәтердә калган. Алар бик пөхтә-матур яшәделәр. Касыйм бабайның олы улы Җәүдәт абый, авылдан Донбасс якларына чыгып китеп, 1929 елда миңа яулык алып кайтканы хәтердә. Бу минем өчен зур шатлык булды. Ә икенче баласы Шаһзанан апа кешеләргә әйберләр чигә иде, миңа әкиятләр сөйләде. Мидхәт абый өздереп гармун уйнарга яратты. Скрипкачы иде, хәтта бу уен коралын үзе ясады. Ә миңа агачтан төннәр буе уенчыклар ясый иде, мәрхүм. Ул агач эшенең чын остасы булды. Өстәл, самавыр, утыргычлар, сәгатьләрнең барысын да үзе ясады. Дүртенче балалары – Әсхәт абый. Касыйм бабай бар балаларын да эшчән, тырыш кешеләр итеп тәрбияләде.

Хәзерге вакытта мин бу кешеләрне күргән бердәнбер кеше. 1930 нчы еллардагы мәхшәрләрдән соң аларның исемен әйтергә дә куркып йөрдек. Бервакыт «Азат хатын» журналын алсам,

Фатыйх Әмирханның тууына йөз ел тулу уңаеннан мәкалә басылган. Бер фото астына: «Ибраһим Бикколов, әдипнең дусты, укытучы, тәрҗемәче», – дип язылган. Телевизордан Касыйм Бикколыйның китабын күрсәтеп: «Моны укыган кеше бәхетле булачак», – дип сөйләделәр, соңрак кулыма аның гарәби язудагы кайбер китаплары да килеп керде. Шуннан соң гына мин Ибраһим һәм Касыйм абыйларның нинди зур кеше булганлыгын белдем.

ҖАМАЛИ БАБАЙ

1950 нче елларда Яңа Тинчәле авылына кайткач, зиратта бабаларым Яһүдә, Габделлатыйф һәм Җамалетдиннарның, Касыйм абыйның кабер ташларын таптым, гарәби язуларын укыдым. Әтием Мөхәммәт каберенә таш куйдырдым.

Җамали бабам* үзе, аның бертуганнары (ягъни Габделлатиф бабайның уллары) Зарифулла, Шакирҗан, соңрак бабамның улы Касыйм, Зарифулланың уллары Гаяз һәм Миргасим авылыбызның дүрт мәчетендә имамлык итте. Габделлатыйф бабайның бер кызының улы – Гаяз Усманов. Мин аның балалары белән бергә уйнап үстем. Касыйм һәм Гаяз бабайлар бергәләп китаплар да язганнар**.

1914 елда вафат булган Җамали бабам искиткеч яхшы, игелекле кеше булган. Чит бер авылда, танышларына баргач, кечкенә ятим баланы башкалары гел какканын күргән. Юлга чыкканда бабам: «Бу баланы миңа бирәсеңме?» – дип сораган. Теге кеше, үз балалары да күп булгач, ятимне бирергә булган. Бабам аны алып кайтып, тәрбия кылган. Бу – Кәлимулла бабай. Хәзер дә аның оныклары белән аралашып яшим. Тинчәледә бернинди туганым, хәтта элеккеге күршеләрем дә юк, фәкать Кәлимулла бабамның балаларына гына

Яңа Тинчәле авылында Җамалетдин Бикколов тарафыннан төзетелгән мәчет. 1970 нче еллар азагында сүтелгән.

кайтып йөрим.

Кәлимулла бабайның төп йортында кече улының хатыны Фәридә исән-сау. Мин аннан: «Кәлимулла бабайны яхшы карамаганнардыр инде, ятим бала булган бит...» – дип сорыйм. Ул әйтә: «Юк, безнең әти алай сөйләмәде. Бервакыт Кәлимулла бабай майланмаган кабартма ашап утыра икән. Җамали бабай кергән дә, моннан соң Кәлимулланың аерым әйбер ашаганын күрмим, башка балалар белән тигез булсын, дигән». Ул үсеп җиткәч тә, Җамалетдин хәзрәт аны өйләндереп, йорт салып бирә һәм башка чыгара.

Бездән ике-өч йорт аша гына Василә әби бар иде һәм ул безгә һаман килеп йөрде. Берзаман ул әйтә: «Син бабаңның нинди кеше икәнен беләсеңме? Бервакытны, – ди, – мин җәй көнне комгандагы суны мичтә кайнатып, чәй эчеп утырам. Шулвакыт Җамали хәзрәт ки-

---

* Габделлатыйф бине Яһүдә бине Биккол әт-Тинчәле һәм аның балалары турында Р.Фәхреддинең «Асар» исемле хезмәтендә тәфсилләп языла, Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар» әсәрендә исеме телгә алына.

** Бу шәхесләрнең «Әхлак» исемле әсәре журналның 2014-2015 елгы саннарында басылды.

леп керде дә самавыр юклыкны күреп алды. Берничә көн үткәч, ул безгә самавыр күтәреп кереп килде: «Менә, моннан соң комганнан чәй эчмә, самавырдан эч», – диде. Синең бабаң һәрвакыт кешеләргә булышып, халык өчен тырышып яшәде».

Җамали бабамның алдан күрүчәнлеге турында әүвәлгеләрнең сөйләгәннәре шактый.

Көннәрдән беркөнне Җамалетдин хәзрәт янына берәү килергә уйлаган, әмма сәдака бирергә акчасы юк икән. Хатыны: «Менә ике йомырка алып бар», – дигән. Ир кеше ир кешегә ничек йомырка күтәреп барсын инде?! Хатыны бер тиен акча табып кайткан һәм ир хәзрәткә киткән. Шунда бабам: «Йомырка алып килергә уңайсызландыңмыни?» – дигән.

Бабамның кара күннән ясалган повозкасы бар иде. Ул шуңа утырган, ә Кәлимулла бабам – күчер. Бара торгач, бабам: «Кәлимулла, атыңны туктат әле! – ди. – Безнең артыбызда бер бабай бар, аның арба көпчәге төшкән». Кәлимулла бабай төшеп караса, дөрестән дә, бер карт бабай арба көпчәген куя алмый азаплана.

Безнең Иске Шәйморза янында елга ага. Көннәрдән беркөнне бабам әйтә: «Кәлимулла, елгада күпер юк, ясыйлар – бозыла, хәзер дә ул ватык. Шунда берәү аты белән баткан, чыга алмый газаплана. Бар әле, син шуңа булыш!» Кәлимулла бабай ышанмыйча гына барып караса, дөрестән дә, анда арбасы белән берәү баткан икән.

МАҺИҖАМАЛ АБЫСТАЙ

Маһиҗамал әбием – Җамали бабамның өченче хатыны. Аңа кадәрге хатыннары яшьли вафат булган. Әби – Шамил Усмановның әтисе Хәйрулла белән бертуган. Ул мин белгәндә сукыр иде. Аның бу күлмәгенең (фотодагы) җиңеннән тотып-тотып карый идем. Ул: «Бу күлмәк мин үлгәннән соң сиңа калыр», – диде. Әбием сукыр булса да,

Маһиҗамал абыстай – Җамалетдин Бикколовның хатыны. 1929 ел

вак-төяк әйберләрне тегә иде. Әтиемнең абыйсы Хәмит белән энесе Әхмәт басмачыларга каршы көрәшкәннәр, шунда яшәп тә калганнар. Алар әбиемә тәм-том җибәргәли иде. Мин дә шулар белән сыйланырга әбиемә еш кердем.

Әмма Маһиҗамал әби, әтием өйләнгәч, әниемне яратмаган, чөнки әнием – мужик кызы. Ә әбием – мулла кызы, шул замандагы фикер буенча, аның килене дә мулла кызы булырга тиеш.

Әнием сөйләгәннәрдән шул истә. 1921 елгы ачлык. Әтием янына Шакирҗан керә дә: «Мөхәммәт, ачлыктан үләбез, берәр нәрсә бир әле», – дип әйтә Әти әбинең сүзеннән чыкмаска өйрәнгән. Әби нәрсә әйтә – тыңларга. Әти сорагач, әби: «Үзеңә ашарга тапмаганда, ничек бирәсең?» – дигән. Маһиҗамал әби катырак кеше иде, ә бабам Җамалетдин (1914 елда вафат) андый булмаган, әбиемне нык тоткан. Әтием келәткә кергән дә, чалбар-костюм кесәсенә иген тутырып, бабайга ашлык биргән. Көннәрдән беркөнне игенне урганнар, әмма аны алып кайтырга ат юк икән. Әнием Шакирҗан бабайга киткән,

Әнием Фатыйма Бикколова укучылары белән. Башкортстан, Авыргазы районы, Курманай авылы. 1932 ел

ә аның инде бу вакытта ике аты булган. Шакирҗан: «Юк, үз игеннәремне алып кайтасым бар», – дип әйткән. Әнием елый-елый капкадан чыгып барганда, туктатып: «Фатыйма, кер әле. Ике атым да синеке, игенеңне алып кайт. Ирең Мөхәммәт өчен бирәм. Ул мине үлемнән саклап калган иде», – дигән.

ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Мин 1920 елның 3 июлендә Яңа Тинчәле авылында туганмын. 1930 елның мәхшәрләрен күргән кеше мин. Шул елда без, мулла балалары буларак, авылдан куылдык. Әниемне ни өчендер утыртырга тиешләр иде. Аны утыртмасыннар өчен, төнлә качып киттек. Башкортстанга барып урнаштык, әнием анда Авыргазыда укытучы булып эшләде. Бер-ике елдан соң Яңа Тинчәлегә кире әйләнеп кайттык. Безгә кайткач та тынычлык булмады. Касыйм мулланың нәселе, диделәр безгә. Аны «солтангалиевче», милләтче, татар халкын яклый, дип каралттылар.

Соңыннан без Бакуга, әниемнең сеңлесе янына киттек. Анда барсак, безнең кебекләргә бөтенләй урын юк икән. Әнием тамак хакына кешегә хезмәт итте, мин дә балалар карадым. Аннан Ашхабадка киттек, шунда педучилищеда укыдым. Юллама белән Чарджуйга җибәрделәр, анда мәктәптә укыттым. 1930 нчы елларда аякларыма салкын тидердем булса кирәк, шешә башладылар. Врачлар аннан китәргә кушты һәм шулай итеп, 1946 елда Яшел Үзәнгә кайтып төпләндем. Монда татар мәктәбендә урын булмады, урысныкына исә керергә курыктым. Ательеда тегәргә өйрәндем һәм тегүче булып эшләп, пенсиягә чыктым. Соңыннан мәчет төзелешендә бухгалтер булып эшләдем. Ирем Мөнир белән 5 бала үстердек...

Йортыбыз янындагы китапханә – минем бәхетем. Мин анда һәр атнада, кайчакта һәр көн булам. Төрле журналлар, аеруча «Безнең мирас» һәм «Түгәрәк уен» белән кызыксынам. Бабаларым барысы да укымышлы булганнар, миндә дә шулар канының бер тамчысы бар, ахрысы, китап-журналларны укыйсым, кемгә дә булса белгәнемне өйрәтәсем килә...

Мин хәзер 96 яшькә җиткән әби. Аллаһы Тәгалә мине хөрмәт иткән: зиһенем бар, күзем күрә (Рауза апа күзлексез укый!), авыру аякларым да йөри, дөрес, ишетеп бетермим... Ай да бер генә төн түгәрәк булып тора, аннан кими...

Рауза Бикколова сөйләгәннәрне ***Марат Закир*** *һәм* ***Ленар Гобәйдуллин*** *язып алды.* ■

Уңышлы башламнар

Лирон Хәмидуллин

Әдәби, мәдәни һәм тарихи мирасыбызны эзләп-барлап, даими рәвештә киң катлам җәмәгатьчелеккә җиткереп торучы альманах, журнал ише басмаларыбыз Совет хакимияте чорында сирәк күренеш булды. Рус мәдәнияте тарихында исә андый мәҗмугалар элек-электән бар иде. Мәсәлән, узган гасырның алтмышынчы елларыннан башлап мин «Наука и жизнь» журналын даими рәвештә укып барырга тырыштым. Анда Россия тарихына кагылышлы шактый кызыклы һәм гыйбрәтле хезмәтләр басыла килде.

Шул исәптән рәсми танылган тарихчы галимнәрнең төрки халыклар тарихына багышланган кайбер уйдырмаларын тәнкыйтьләп язган бик дәлилле хезмәтләр дә күренгәли иде. Мәсәлән, 1960-1970 елларда шундый хезмәтләрдән тарих фәннәре докторы А.Л.Монгайтның берничә җитди мәкаләсе урнаштырылды. Мәгълүм ки, бу галим төрки кавемнәр тарихын да яхшы үзләштергән шәхесләрдән иде. (Бәлки тумышы белән дә яһүдиләр динен тотучы төркиләрдән — караим нәселеннән булгандыр.) Миндә А.Монгайтның Көнчыгыш Европа төбәгендә яшәүче төркиләр (болгар, кыпчаклар) иленә XII гасырда сәяхәт иткән испан гарәбе Әбү Хәмид әл-Гарнати сәяхәтнамәсенең русча тәрҗемәдә аның тарафыннан чыгарылган китабы да бар. Бик бай эчтәлекле китап ул. Гадәттә рус тарихчылары (шул исәптән Европа галимнәренең дә күпчелеге) беренче меңьеллык урталарында «тарих мәйданына кинәт күтәрелеп чыккан», элек бик сирәк кенә телгә алынган гарәпләрне зур тарихтан бер читтәрәк итеп күрсәтергә тырышалар иде. Һәм менә шул гарәпләрнең хәзерге Испания җирләрендә яшәгәннәре арасыннан 8-12 йөзләр тирәсендә бөтендөнья күләмендә танылган йөзләгән галим-

нәр калкып чыга. Һәм шул гарәпләр арасында әл-Гарнати, Әбүл Хәйян кебек төрки халыклар тормышы вә тарихы белән кызыксынучылары да була. Әллә соң алар тумыштан ук та төрки кавем вәкиле булганмы? Багдадта туган, X гасырда яшәгән галим Әбелхәсән әл-Мәсгуди хезмәтләрендә хәлифәт гаскәрләрендә төркиләрнең күп булуы, гаскәр башлыкларының күпчелеге төркиләрдән торганлыгы әйтеп кителә, дигән мәгълүмат бар. Димәк, испан гарәпләре арасында да Якын Көнчыгыш төбәгеннән чыккан төрле милләт вәкилләре булганлыгында шик юк. Хәер, яһүдиләр динен тотучы берәүнең Испаниядән Итил каласына, хәзәрләр иле каһаны исеменә хат язганлыгы да мәгълүм ич.

Кайбер Европа галимнәренең раславынча, югары белем бирүгә йөз тоткан беренче уку йортлары да иң әүвәл «Гарәпләр Испаниясе»ндә барлыкка килгән. (Шундый бер хезмәт белән миңа язучыларның Малеевка иҗат йортында танышырга туры килде. Ул иҗат йортының китапханәсе бик бай иде.) Гарәпләрнең күпчелеге Испания ярымутравыннан куып җибәрелгәч, шул уку йортларында укыткан кайбер мөгаллимнәр соңрак шундый ук уку йортларын хәзерге Франциянең көньягында – Урта диңгез буйларында ачканнар, дип язылган иде ул китапта. Димәк, «беренче университетларны ачуда» да гарәпләрнең өлеше булган. Испан гарәпләренең архитектура үрнәкләре әле дә күпләрнең күңелен җәлеп итә. Язма мираслары да бай булган аларның. Шул хезмәтләрнең дә күпчелеге заманында Европа телләренә дә тәрҗемә ителгәннәр. Аеруча Франция фәннәр академиясе галимнәренең борынгы чор Азия халыклары әдәбиятына һәм тормышына багланышлы язмаларны күпләп үз телләренә тәрҗемә итеп бастырганлыклары мәгълүм. Тик андый шәхесләрнең хезмәтен безнең алга да китереп салырдай В.Бартольд, И.Крачковский, А.Монгайтларның бик аз булуы гына күңелдә ризасызлык тудыра.

Гарәбстанның үзендә дә ул чорда мәдәният бик алга киткән була. Мәскәүгә бер баруымда мин 6-8 йөзләрдә иҗат иткән гарәп шагыйрьләренең бер җыентыгын да алып кайткан идем. Аларны академик И.Ю.Крачковский туплап чыгарган. Китапка кереш сүзендә: Европада ул дәвердә әле мондый иҗат җимешләре берән-сәрән генә булган, дигән сүзләр дә теркәлгән иде сыман. (Соңрак ул китапны мин үзебезнең бер шагыйрьгә бүләк иттем. Шуңа күрә алдагы җөмләне «сыман» сүзе белән төгәллим.)

Унынчы гасырда яшәгән Әбелхәсән Әл-Мәсгуди әл-Багдади (896-956) иҗаты белән дә бик кызыксынам. Аның X гасыр урталарында ук «Хәзәр диңгезе»нә исем биргән хәзәрләр һәм болгарлар турында мәгълүмат туплау өчен дип, Итил каласы тарафына сәяхәт кылганлыгы да мәгълүм. Шул сәяхәтенә багышлап, ул китап та язган. Тарихчы В.М.Бейлис хәбәр итүенчә, бу сәяхәтче галим Идел буе болгарлары дәүләте турында да кызыклы фактлар китергән шул сәяхәтнамәсенә багышланган хезмәтендә. Ул сәяхәтнамә китабы белән Төркиядә яшәгәндә Зәки Вәлидинең таныш булганлыгы турында да хәбәрләр бар. Рус авторлары әлеге сәяхәтнамә китабының исемен «Золотые копи и россыпи самоцветов» дип язалар. Җәмгысе ул автор шундый бай эчтәлекле дистәләп зур хезмәт язып калдырган. Аның кайбер хезмәтләре белән Ш.Мәрҗани хәзрәтләре дә таныш булган, дигән хәбәрләр дә күренгәли. Шушы олуг сәяхәтче һәм галимнең бернечә кита-

бы арасыннан үзебезнең болгар белән хәзәрләргә кагылышлысын күптән инде табып аласы һәм тәрҗемә итеп чыгарасы да бит – үз монгайтларыбыз өлгереп җитмәгән шул әле. Аның һәм башка бик күп гарәп, фарсы, кытай тарихчыларының төркиләргә кагылышлы хезмәтләре бүгенге көн Россия галимнәрен әллә ни кызыксындырмый бит. Алар безгә кирәк. Ә шул ук Әл-Мәсгудига багышланган, мин язып биргән кыскача гына мәгълүматны да «Татар энциклопедиясе»н чыгаручылар, нишләптер, сызып ташлады. Ул хәбәрнең кыскача өлеше фәкать «Энциклопедия сүзлеге»нә (415 бит) генә «эләгеп» калды.

Бу юлларны мин үзебезнең мирасны барлауга багышланган калын-калын мәҗмугаларның әлегәчә дәвамлы рәвештә чыкмавын күрсәтер өчен китердем. Дөрес, 1950 нче еллар урталарыннан башлап үзебезнең Тел, әдәбият һәм тарих институтыбыз (ТӘТИ) ике-өч елга бер мәртәбә фәнни эчтәлекле шундый китаплар чыгарырга тырышты. 12-14 табак күләмендәге андый җыентыклар, билгеле инде, үз галимнәребезнең уй-фикерләрен барлап, туплап чыгара иде. Ул җыентыклар ара-тирә башка авторларның төрки-татарлар тарихына кагылышлы кызыклы гына хезмәтләрен дә бастыргалады. Мәсәлән, гомерен читтә уздырган күренекле тел галиме Нәҗипов Әмир Нәҗип улы (1899-1991) шундый җыентыкларның берсендә Әл-Мәсгуди, Әбүл Хәйян Андалусидай борынгы галимнәрнең хезмәтләрен искә алып, күләмле генә очерк бастырган иде. Гарәп Испаниясеннән (Андалусиядән) чыккан зур галим Әбүл Хәйян төркиләр тормышына да зур әһәмият биргән – аның унлап язма хезмәте (китабы) арасында берничәсе шулар тормышына багышланган, дип язган иде ул. Соңрак аның кайбер шәкертләре – Үзбәкстан галимнәре дә Әбүл Хәйян мирасын искә алгаладылар. Бу галимнең бер хезмәте төрки телле кавемнәрнең кайсы кыйтгаларда таралып яшәүләрен ачыклауга багышланган, калган икесе гарәп-төркиләр сүзлегеннән тора, дип яздылар. Бу авторның шушы соңгы хезмәтләрен генә булса да эзләп табып, бүгенге галимнәр кулына тапшырсаң бер дә зыян итмәс иде дип беләм. Дөрес, бәлки андый эшләр инде башкарылгандыр, мин генә шул хакта берни дә белмимдер. Күптән инде Әмир ага Нәҗип биографиясен киң җәмәгатьчелеккә ирештергән Фәнүзә ханым Нуриева белән очрашасым килә. Бу җәһәттән ул күп нәрсә беләдер кебек.

Әйе, ТӘСИ галимнәре 1990 елларгача шундый ике дистәләп китап чыгарды шикелле. Хәзер китапханәмдә шундый ике-өч җыентык кына саклана. «Казан утлары» һәм башка журналлар да ара-тирә тарих, тел мәсьәләләренә кагылышлы фәнни хезмәтләргә урын биргәләделәр, ләкин ул эш дәвамлы рәвештә башкарылмады. Андый дәвамлылыкка омтылыш та бик сизелмәде, чөнки мондый мәҗмугалар эшчәнлегенең төп максаты – бүгенге чор әдәбиятын халыкка җиткерүдән гыйбарәт ич. Хәер, «Казан утлары»ның яңа гасыр башында нәшер ителгән бер-ике еллык санын актаргалагач, борынгы төркиләр тарихына багышланган ике-өч хезмәткә юлыктым, тәки. Шуларның бер-икесен, әйтик, шактый кызыклы мәгълүмат тупланган «Хәзәрләр» язмасын (авторы Мөсәгыйт Хәбибуллин), бүгенге буын укучысын да таныштыру өчен кабат бастырып чыгарсаң да зыян итмәс иде (2001 ел, №6).

Ахыры бар ■

Мансур Ярмиев: **«Без татар булуыбыз белән горурланып яшәргә тиеш!..»**

(Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры директоры ***Мансур Зиннур улы Ярмиев*** *белән драматург* ***Рәдиф Сәгъди*** *әңгәмәсе)*

– Бүгенге икътисади катлаулы заманда кечкенә театрларга гына түгел, зур театрларга да яшәве авыр. Мәктәп балаларын театрга җәлеп итү яки мәктәпләрдә спектакль кую зур проблемага әверелде. Югыйсә, театр зур тәрбия чарасы. Шундый кыен шартларда яшьләр театры ничек эш итә?

– Габдулла Кариев исемендәге яшь тамашачы театры 28 ел эшчәнлек чорында балалар, яшүсмерләр белән эшләүне җайга салды, шулай да бу юнәлештә башкарасы эшләр бар, дип саныйм. Элегрәк спектакльне мәктәпкә бернинди каршылыксыз барганнар да куйганнар, ә хәзер заман икенче, уку йортларына тиз генә керепбулмый. Репертуарыбызга килсәк, андагы күп спектакльләр мәктәпнең дәрес һәм тәрбия эшләре программасына кергән. Наркотикларга кагылышлы спектаклебез булу сәбәпле, Наркотикларга каршы идарә белән килешү төзелде. Юл хәрәкәте иминлеге темасына өч пьеса сәхнәләштерәбез. Килешү нигезендә безгә төрле районнарда булырга туры килә.

Безнең, Аллага шөкер, балалар белән бәйләнеш нык. Дөрес, бүгенге көндә хәлләр тел җәһәтеннән дә катлаулы. Элек шәһәр баласы татарча аңлый иде, ә хәзер укучыларга колакчалар таратыр-

га мәҗбүрбез, тәрҗемә сорыйлар. Менә шунысы йөрәккә тия.

– *Театрның булачак бинасы ни хәлдә?*

– Алафузов театры бинасы – опера һәм балет театрының баласы. Андагы кебек акустиканы минем бер җирдә дә ишеткәнем юк. Әгәр дә театрда төзекләндерү эшләре башлана икән, анда элеккеге кебек акустика калмаячак – сәнгать югалачак. Театрның сәхнәсе зур, әйбәт. Мин анда үзем рәхәтләнеп җырлап йөри идем. Элекке бинаны киләчәктә дә сәнгать коллективларына бирергә кирәк. Сәхнә мәдәнияткә хезмәт итәргә тиеш. Мин эшләгән елларда анда хәтта банкларны да кертеп карадылар.

Театрыбызның булачак бинасы – Офицерлар йортында бөтен нәрсә яңгырый, аваз кире кайта. Иң яхшысы – үзәктә. Шунысы шатландыра: Камал, Тинчурин, Курчак театрлары якында гына, шулай итеп, тулы бер комплекс барлыкка киләчәк. Без олы театрларга яшьләрне әзерлибез, әмма олылар өчен дә спектакльләребез бар. Камал, Тинчурин театры артистларының ничек уйнаганын тамашачы яхшы белә, ә безнең театр олы яшьтәгеләр өчен әле дә сер булып кала. Дөрес, артистларның талантын беләләр, әмма яңа залда яңа театр булачак һәм анда сәнгать әһелләребез бөтенләй башка яктан ачылыр, дип өметләнәм.

– *«Безнең мирас» журналы, халкыбыз мирасын туплап кына калмыйча, хәтта югалганнарын да табып кайтара. Бүгенге көндә яшьләр театры милли драматургларыбызның әсәрләрен халкыбызга җиткерүдә ниләр эшли?*

– «Безнең мирас» журналы редакциясе белән дусларча мөгамәләдә яшибез. Аларны балаларга спектакльләр куйганда чакырабыз. Язылу вакытында да ярдәм күрсәтәбез.

«Безнең мирас» кебек үк, без дә үзебезнең классик мирасыбызга йөз белән борылдык. Әмма элеккеге әсәрләрне хәзерге заман халкы бик үк кабул итеп бетерми. Шулай да алар булырга тиеш. Быел Габдулла Кариевның тууына – 130 ел. Ул Тукай белән Җаекта бергә укыган, мәдрәсә бетергән, коръәнхафиз, кари булган. Аның «Артист» исемле әсәре театрыбызның йөзек ка-

Рәдиф Сәгъди һәм Мансур Ярмиев

«Галиябану» (М.Фәйзи)

шына әйләнергә тиеш. Без һәр сезонны «Артист» белән ачып, шуның белән ябарга уйлыйбыз...

– Озак еллар сәхнәдә барсын, дисәң, аны көн саен күрсәтергә ярамый булып чыга...

– «Артист» – Г.Кариевның бердәнбер әсәре. Әлеге спектакльдә бөтен труппа, артистларыбыз уйный. Киләчәктә ул зур мәдәни чараларда гына уйналачак.

Рабит Батулланың «Кичер мине, әнкәй» исемле әсәрен дә сәхнәләштердек, әмма үзебезчә. Бу әсәр онытылып бара иде... Шәүкәт Биктимеров, Равил Шәрәфиевләр уйнаганны без һич кенә дә алмаштыра алмыйбыз. Мин, егетләр, азапланмагыз, дим. Башка театрлар киләләр дә «Әлдермештән Әлмәндәр»не классик артистларыбыз уйнаган рәвештә кабатлап яңадан сәхнәләштерергә омтылалар, әмма ха-

«Йосыф -Зөләйха» (Кол Гали)

«Казан ятиме» (Р. Зәйдулла)

лык кабул итми, булдыра алмыйлар, чөнки әсәр халык хәтерендә әле дә саклана. Ә «Кичер мине, әнкәй»не оныттылар... Хәтта өлкән буын кешеләре дә! Шуның өчен, әсәр сәхнәдә яхшы бара.

Аны аз гына яраклаштырып җибәрдек тә яңа куелышны халык кабул итте. Туфан Миңнуллинның «Нигез ташлары»н күп җирләрдә елыйелый карадылар.

– *Анда бит драматургия бар!..*

– «Айрыз батыр» эпосын сәхнәләштердек. Бу әсәрне фестивальдә яратып карыйлар, әмма ул гади көннәрдә тамашачыны җыя алмый. Кырымлылар сорагач, шунда барып, аны Кырым татар тамашачысына да күрсәттек. Халык бөтен нәрсәне аңлап, җылы кабул итте.

– *Татар телен, татар милләтен саклап калуда сезнеңчә без нишләргә тиеш?*

– Үткән белән чагыштырганда, без тизлек заманында яшибез. Кемдер каядыр ашыга... Кемдер берәүне узарга тырыша. Юлда барганда да, әкрен генә барасың икән, машинада синең юлыңны кисеп керә башлыйлар. Ә инде кызу барсаң, штрафы килә.

Өч-дүрт урыс янында син үзең генә булсаң, алар белән урысча сөйләшергә мөмкин түгел иде. Безнең акцент белән сөйләшкәннән алар көлде генә. Хәзер исә без урысча сөйләшкәннән бер кеше дә көлми.

Татар теленең дәрәҗәсе үсте. Безнең белән урысча белсен, дип, урысча сөйләшәләр иде, ә хәзер, киресенчә, балаларны татарчага өйрәтергә тырышабыз.

Бүген Чабаксарда – чуваш, Йошкар-Олада мари теле юк. Ә Казанда татар теле бар. Без моңа сөенергә тиеш. Бала бакчага барганчы әни, әти, дип татарча эндәшә икән, туган телен гомере буе онытмаячак. Әгәр без «мама», «папа», дип әйттерсәк – эш харап. Күп нәрсә хатын-кыздан тора. Ә ир кеше моны аннан таләп итәргә тиеш. Мәскәүгә татар кирәк түгел, шуңа, авыр чакта ярдәм алыр өчен, анда гомер иткән миллионга якын милләттәшебезгә үз татары кирәк!.. Без, үзебезнең татарлыгыбызны саклап, татар булуыбызга шатланып, горурланып яшәргә тиеш. Кайсы гына төбәккә барсак та, татар дигән затлы милләтнең хөрмәткә лаеклы булуын күрәбез. ■

Алардан шәп мирас калды

Рәфикъ Юныс

Арча районының Сеҗе авылы зиратында күптән түгел ике кабер ташы куелды. Әхмәт Галиев белән Гөлчәчәк Галиевага. Гади түгел, затлы кабертташлар бу. Алар астында яткан адәм балалары исә бигрәк тә затлы. Милләтебезнең асылташлары дисәң дә буладыр аларны.

Янәшә ятуларының сәбәпчесе исә – Мирхәйдәр Фәйзи. Аның «Галиябану»ы беркем дә аера алмаслык итеп очраштыра аларны! Сеҗе Галиябануы белән Хәлиле гомер буена рәхмәт укып яшиләр аңарга. Рәфыйк Шәрәфиев язуынча («Татарстан яшьләре», 2015 елгы 12 февраль саны), рәхмәтләрен аның Балтач районы Шода авылындагы музей-йортына да җиткергән әле алар. «Бәхетле пар ул чакта, күп кенә китаплардан тыш, музейга ун мең сум акча да калдырды. Узган ел тагын шуның кадәр акча җибәрделәр», – дип язган иде адашым (мин аңа олылап «Адашетдин» дип дәшәм).

Галиевләр калдырган мирасның бер өлеше – саф мәхәббәт үрнәге. Галиябану белән Хәлилне сәхнәдән тормышка күчереп, мәхәббәтләрен үлгәнче, ягъни 63 ел буена сүндерми яшәтә алган гаҗәеп пар бит бу! Һәм пычракка бата барган, балалар, үсмерләр, яшьләр телевизордан гел атышлар һәм ятышлар күреп үскән бу заманда – бик тә кыйммәтле үрнәк! Әхмәт абый һәм Гөлчәчәк апа турындагы «Без аларны җуймаска тиеш!» дигән зур язмамны (8 сентябрьдә чыкты), нәкъ менә «Татарстан яшьләре»нә бирүем тикмәгә түгел инде.

Алар калдырган мирасның «матди» өлешенә күчик. Әхмәт абый 1972 елдан башлап 23 ел буена Казан Компрессор заводына җитәкчелек итте. Бик көчле директор булды ул. Өч тапкыр орден белән бүләкләнде. 1991 елда ул үз заводын Татарстан карамагына күчерттерде. Татарстандагы завод-фабрикаларның 80 проценты – Союзга, 18 проценты – Рәсәйгә һәм нибары 2 проценты, алары да бәләкәчләр генә, Татарстанга караган чакта бит бу! Һәм әле, директорларын күндереп, тагын ике заводны Татарстанныкы иттертә. Һәм шул рәвешле Татарстан җитәкчеләрен дә шул эшкә этәрә. Нәтиҗәдә, Татарстаннныкылар өлеше 92 процентка җитә! «Ни уйлап алындыгыз сез бу эшкә?» – дигән соравыма Әхмәт абыйның җавабы мондый булды: «Икътисадның ни икәнен аңлаганнан килеп чыкты бу. Байлыгың, милкең юк икән, синең бер хокукың да юк». Коточкыч авыр эшне үз өстенә ала Әхмәт абый. Ул компрессор машиналарының Татарстанга бик аз өлеше генә кирәк бит. Заводка көчле икътисади басым ясала. Компрессорлар өчен акча элек дүрт көн эчендә килеп җитә торган булса, инде өчәр, дүртәр, бишәр ай йөри башлый. Акчасыз нишли аласың? Өстәвенә, бөтен эшләп чыгару күләменең 25 процентын тәшкил иткән хәрби заказлар да туктатыла. Ягъни акча бик нык кими һәм әле 1570 кеше эшсез торып кала. Мондый хәлдә теләсә кайсы башка директор «Биреләм!» дип ике кулын күтәрер иде. Әхмәт Галиев исә уникаль шәхес шул. Аның җитәкчелегендә яңа төр техниканы үтә тиз эшләү ысулларын табалар, ныгытып экспортка эшли башлыйлар. Һәм әле, шаккатмалы хәл, 1993-1995 елларда завод Парижда (ике тапкыр), Мадридта, Копенгагенда, Женевада халыкара конкурсларда җиңүчеләр арасында була!

Тагын шул Мирхәйдәр Фәйзигә рәхмәт инде. Ул бүләк иткән «Галиябану» турында «Хәлиле» менә ни ди:

«Инде танылып кына килгәндә, 15 ел яратып эшләгән мәктәп директоры вазифасын калдырырга мәҗбүр булды. Әгәр дә бу «югалтуларга» бармаган булса, мин техник фәннәр буенча кандидатлык һәм докторлык дәрәҗәләренә ирешә алмаган булыр идем. Мин җитәкләгән Компрессор фәнни-производство берләшмәсендә дистәләгән яңа типтагы компрессор машиналары җитештерелмәгән булыр иде».

Монысы исә Гөлчәчәк апа сүзе:

– Җиңел булмады, коллективның да җибәрәсе килмәде. Үз карьерама караганда ир хакын хаклауны кирәгрәк дип санадым.

1996 елны эштән киткәндә Әхмәт Галиевтән әнә шундый көчле завод һәм аның башлангычы белән индустриаль куәт алган Татарстан мирас булып калган иде. Ләкин... 2006 елгы әңгәмәбез вакытында «Татарстан җитәкчеләренең иң зур хатасы ни булды?» – дип сорагач, болай диде ул: «Мөстәкыйльлекне якламау. Чигендек. Нык чигендек. Төп гаеп – хөкүмәттә, югарыда утырганнарда. Яулаган бөтен нәрсәне дә диярлек җуйдык». «Сез башлаган теге олы эштән ни калды?» – дигән соравыма исә җавабы мондый булды: «Берни дә калмады. Янә бар да Россия кулында хәзер». Безнең көнелләрдә исә аннан мирас булып киләчәккә «Татарстан үз милкенә үзе хуҗа булырга тиеш!» – дигән инану һәм өстәге түрәләр гамен дә, үз гамен дә түгел, завод гамен, эшчеләре-хезмәткәрләре һәм тулаем Татарстан халкы гамен алга сөргән, татар халкының матур киләчәге өчен җан аткан куш йөрәкле җитәкче образы барсын иде... Хәер, аннан калган тәгаен нәрсәләр дә аз түгел әле. Менә аларның кайберләре. Өч меңнән артык гаилә фатирлы була. Заманча бик шәп итеп төзеп, биш балалар бакчасы ачалар. Эш хакы да шәп кенә арта... Татар мәдәниятенә дә ярдәм күрсәткәләде әле Әхмәт абый.

Өйдә дә һәм хәтта завод эшләрендә дә таянычы булган, аңа рухи көч тә биреп торган Гөлчәчәк апа исә халык күңелендә киләчәк елларга Әхмәт абый белән заводчы буларак та янәшә

барырга тиеш. Ләкин аның үзеннән дә шәп мирас калды әле. Әхмәт абый эштән китүгә ул, ниһаять, күңелендә ташып торган иҗади дәрткә юл ача һәм «Тулгак», «Өзелгән өмет», «Газзәбану» кебек халык бик-бик яратып һәм уңай тәэсир алып укыган повесть-романнар иҗат итә. Татарстан китап нәшрияты 2013 елда, үләренә ярты еллап кала, автордан бернинди тәкъдим-үтенечсез үз теләге белән чыгарып, Гөлчәчәк апага зур сөенеч китергән (бәлкем, беркадәр гомерен дә озайткандыр әле) «Әсәрләр» дигән китабында алар кабат, бу юлы өчесе бергә дөнья күрде. 2007 елда «Мәгариф» нәшрияты нәшер иткән «Күңелемә якын затлар»га исә Фәнис Яруллин, Нурихан Фәттах, Таһир Якупов, Тәбриз Мөбарәков, Факил Сафин һәм Рәфикъ Юныс турындагы очерклары кергән.

Хәзер биредәге фоторәсемнәргә дә күз салыйк әле. «Галябану» белән «Хәлил»не таныгансыздыр инде. Икенче фоторәсемдә исә шул ук парны «Сөембикә» журналы юбилеенда икәүләп җырлап торган килеш күрәсез. Рәсем вакыт җәһәтеннән бик тә кызыклы тоелды миңа. «Сөембикә»гә 75 яшь 2001 елның августында тулган бит. Ә Әхмәт абый, туу таныклыгы «әйтүенчә» шул августның унысында җитмеш яшен тутырган (чынлыкта исә 30 апрельдә). Һәм алар 1951 елның 30 апрелендә язылышканнар. Ягъни яңа гаилә нәкъ менә Әхмәт абыйга 20 яшь тулган көнне туган! Фотода, димәк, дүрт ай элек алтын туйларын үткәргән Галиевләр җырлый икән бит! Һәм җырның да ниндиен әле – «Гаилә җыры»н!..

Гөлчәчәк апа – 2014 елның 11 маенда, Әхмәт абый исә 2015 елның 24 гыйнварында вафат булдылар. Кабер ташларын кую исә быел 10 августта, ягъни Әхмәт абыйның рәсми туган көненә туры китереп башкарылды. Бу сәнгати ташларны шул үз заводы – «Компрессормаш» берләшмәсе ясатты инде. Фоторәсемдә ул чакны зиратта булганнарның бер өлешен, башлыча Әхмәт абыйның хезмәттәшләрен күрәсез. ■

САНИЯ ГЫЙФФӘТ (1899-1957)

Фәридә Гаффарова

«Кечкенә генә гәүдәдә зур рух яшәткән бу шагыйрь хатынның Ерак Көнчыгыштан Финляндиягә кадәр сузылган төрки дөньяда даны, тавышы, ә карлы яки комлы сәхрәләрдә исә – эзе бар! Аның Казан сөйләмендә язган шигъри юлларының кайберләре әле бүген дә дога булып һаман да кабатланалар. Тумыштан нечкә күңелгә ия булган һәм бик иртә – 12 яшьтән үк шигырь яза башлаган Сания Гыйффәтнең үзенчәлеге һәм өстенлеге аның милли шагыйрь булуындадыр». Бу юллар Төркиядә чыккан «Төрек юрду» журналының 1957 елның март санында шагыйрә Сания Гыйффәтнең вафаты уңае белән бирелгән мәкаләдән алынды. Авторы – әдәбиятчы, фольклорчы, археолог Хәмит Зөбәер Кошай. Кем ул Сания Гыйффәт? Бүген без аны беләбезме?

Ни кызганыч, бүгенге мәктәп укучылары да, студентлар да, хәтта әдәбиятсөнгать әһелләренең дә күбесе Сания Гыйффәтнең ни иҗаты белән, ни милли эшчәнлеге белән таныш түгел. Ә бит XX йөз башы татар әдәбиятында аның да тавышы, урыны бар. Мөһаҗирлектәге татарларның телен, динен, гомумән, милли йөзен саклауда аның да өлеше зур лабаса!

Сания Гыйффәт 1899 елда Чистайда сәүдәгәр гаиләсендә туа. Әнисе Галия бик иртә вафат була. Кечкенә Сания үз чоры өчен бик укымышлы булган әбисе тәрбиясендә үсә. Аннан ишеткән төрле әкиятләр, халык җырлары, риваятьләр нечкә күңелле ятим кызның хыял дөньясын баета, үсмер күңелендә беренче шигъри юллар бөреләнә. Бераздан Санияне әнисенең туганы – Томскида яшәгән һәм шунда чыккан «Сибирия» газетасында эшләгән Фатыйма Фәридә үз гаиләсенә ала. Белемгә, яңалыкка омтылышы зур булган кыз апасының татар, төрек, рус язучыларының әсәрләреннән торган шактый зур китапханәсендәге китаплар аша дөнья белән таныша. Фатыйма Фәридә ире Вагыйз Нәүрүзов редакторлыгында чыгып килгән «Сибирия» газетасында, ә ул бу җәһәттән татарча газеталар арасында бердәнбер була — «Хатын-кыз дөньясы» дигән бүлекне алып бара. Фатыйма Фәридәнең җәдидчелек хәрәкәтен кайнар яклавы, газета-журналлардагы хатын-кызларның тигез хокуклылыгын яклаган мәкаләләре яшь Саниягә бик нык тәэсир итә. Аның «Үлсәм әгәр...» дигән беренче шигыре 12 яшендә «Сибирия» газетасында басыла. Фатыйма Фәридә бераздан Санияне Буби мәдрәсәсенә илтә һәм ул берничә ел Буби кызлар мәктәбендә укый, соңрак укытучы дипломы ала.

Гаяз Исхакый, Сания Гыйффәт, кызы Лалә

Сания Гыйффәт бик яшьли олы галим, милләтпәрвәр Закир Кадыйрига кияүгә чыга. Ул галимнең хатыны гына түгел, ә аның татар милләтенең тәрәккыятенә багышланган эшчәнлегендә ярдәмчесе дә, киңәшчесе дә була. Шигъри җанлы Сания Гыйффәтнең Закир Кадыйри Уфада чыгарып килгән «Тормыш» газетасында шактый гына шигырьләре, мәкаләләре басыла. Бу чорда ул милләт тормышын кайгырткан, милләт борчуларын үзәккә куйган «Ни өчен?», «Үткән вакыт», «Ничек уйлыйсың?» кебек шигырьләре белән милли шагыйрә булып таныла.

1917 елның 22 июлендә XX йөз башы милли хәрәкәте һәм татар зыялылары тормышка ашырырга омтылган, хыялланган тарихи вакыйга була – Казанда Бөтенроссия мөселманнарының, ягъни Бөтенроссия мөселман вәкилләренең, хәрбиләрнең һәм дин әһелләренең Берләштерелгән съездында Эчке Русия һәм Себер төрки-татарларының Милли-мәдәни мохтарияте игълан ителә. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, озак еллар буй-

сындырылып, кимсетелеп яшәгән татар халкы кабат үзенең дәүләтчелеген торгызуга омтыла. Шушы уңай белән киләчәккә зур өметләр баглаган Сания Гыйффәтнең милли хисләр белән тулган һәм Февраль революциясе биргән мөмкинлекләрдән файдаланырга чакырган «Ил», «Яңадан туабыз», «Төшме бу», «Таң ата» кебек шигырьләре «Тормыш» газетасында басыла.

Милли бәйсезлек идеясен тормышка ашыру юлында янып йөргән фидаи затларның бар өметен сүндереп, Милли-мәдәни мохтариятнең Милли идарәсе совет хөкүмәте указы белән куып таратылганнан соң, С.Гыйффәт илдәге сәяси көчләрне ачы тәнкыйтьләгән «Юк!», «Кая сез?» дигән шигырьләрен яза.

1918 елның җәендә инде Милли идарә әгъзалары Уфадан чыгып качарга мәҗбүр булалар. Алар белән бергә Милли идарәнең Мәгариф министрлыгы әгъзасы булган Закир Кадыйри да Петропавловск шәһәренә барып чыга. Аның артыннан Сания Гыйффәт тә Уфадан Петропавловскига килә, «Кече Милли Мәҗлес» чыгарган «Маяк» газетасында эшли. Соңрак ире артыннан Маньчжуриягә китә. Татар, башкорт, казакъ, азәрбәйҗан мөһаҗирләре, тиздән илгә әйләнеп кайтуларына өметләнеп, Кытайның Россия белән чиктәш районнарында бергә тупланып яшәргә омтылганнар. Күп санлы мөһаҗирләр үзләренең балаларына ана телләрендә белем-тәрбия бирергә теләгәннәр. Закир Кадыйри алар өчен татар балалар бакчасы, башлангыч мәктәп ачуга ирешә. Әмма большевиклар монда да тынычлык бирмиләр. Закир Кадыйри, гаиләсен алып, Маньчжуриядәге Хайлар шәһәренә күчеп китә. Хайларда татарлар, башкортлар, казакълар шактый күп була. Аларның анда үз башлангыч мәктәпләре эшли. Сания Гыйффәт әлеге мәктәптә татар теле, әдәбияты укыта башлый. Ә Закир Кадыйри исә Төркиягә китә. Сания Гыйффәт бары тик ике елдан соң гына, ике баласы белән, зур авырлыклар, кыенлыклар кичеп, ире янына Төркиягә килеп җитә ала.

Биредә яшәгәндә дә ул шигырьләр, драма әсәрләре яза. Гаяз Исхакый чыгарган «Милли юл», «Яңа милли юл» журналларында аның «Улымның җыры» (1934 ел, 8 сан), «Төрек сүзе», «Гази һәм Корылтайга» (1933 ел, 3 сан), «Теләгәндә» (1932 ел, 11 сан), «Исмәгыйль бабайга» (1933 ел, 7 сан) кебек шигырьләре һәм мәкаләләре басыла. Йосыф Акчура вафатының бер еллыгы уңае белән, Г.Исхакый «Яңа милли юл» журналының 1935 елгы 6 нчы санын аңа багышлап чыгара. Бу санда С.Гыйффәтнең дә Й.Акчура турында «Иртәгесе көн» дигән бик хисле язылган мәкаләсе бар. Анда: «Йосыф бәк үлеме барлык төрки халык вәкилләрен ул шулай күрергә теләгәнчә берләштергән, җыйган иде», – дип, ул Й.Акчураның милли эшчәнлегеңдәге төрки бердәмлек идеясын сакларга чакырган.

Шулай ук С.Гыйффәт З.Кадыйриның язган хезмәтләрен, шул исәптән, гарәпчәдән төрекчәгә тәрҗемә иткән «Милләтләр һәм хөкемдарлар тарихы»ның биш томлыгын чистага күчерергә дә булышкан. С.Гыйффәт аның ярдәмчесе һәм язган хезмәтләренең беренче укучысы булган. 1937 елда алар, фин татарлары чакыруы буенча, Финляндиягә күчеп китә. Закир Кадыйри андагы мөселман җәмгыятен җитәкли, ә Сания Гыйффәт балаларга белем бирә, аларны укыту өчен «Уку китабы» дигән дәреслекне дә үзе төзи. Дәреслекнең күп өлешен Г.Тукай, Дәрдемәнд, Г.Исхакый әсәрләре алып

тора. Бу чорда Румыниядән, Эстониядән күчеп килгән татарлар белән берлектә Финляндия татарлары тарафыннан аның большевиклар золымын сурәтләгән «Хәят борчуы» исемле драмасы сәхнәләштерелә. Ә «Тормыш көзгесе» исемле 4 пәрдәлек драмасы 1937 елда Хельсинкида китап итеп басыла. Шулай ук аның «Хан бүләге», «Яңа авыл» исемле драмалары да кульъязма рәвешендә күбәйтелә һәм сәхнәдә уйнала.

1937 елда мөһаҗирлектәге татар җәмәгатьчелеге Гаяз Исхакыйның әдәби эшчәнлегенең 40 еллыгын билгеләп үгә. Аңа язучы буларак та, милли эшлекле буларак та тирән хөрмәт белән караган Сания Гыйффәтнең «Яңа милли юл» журналының 4 нче санында «Гаяз Исхакый хезмәтенең 40 еллыгы уңаеннан» дигән мәкаләсе басыла. Әлеге мәкаләсендә шагыйрә әдипнең әдәби эшчәнлегенә югары бәя бирә, аның әсәрләренең гүзәллек тудыру өчен генә язылган әсәрләр түгеллегенә басым ясап, әсәрләренең үзе дөрес санаган фикерләрен милләткә җиткерү өчен язылган икәнен күрсәтә. Ул Гаяз Исхакыйның «Кәләпүшче кыз», «Бай улы», «Өч хатын белән тормыш», «Ике йөз елдан соң инкыйраз» кебек әсәрләренә анализ ясый, темалар татар тормышының үзеннән алынган, аларда халыкның яралы, кимсетелгән җаны ята, ди. Халык күңелен, җанын борчыган мәсьәләләр күтәрелгәнгә күрә, Гаяз Исхакыйның әсәрләре ничә кат укылса да, яңа булып кала, ә үлемсез, тиңдәшсез «Зөләйха» драмасында татар халкының коточкыч куркыныч тарихы шулкадәр оста, чын итеп сурәтләнә ки, әсәрне укыган һәр татарда кара көчләргә каршы тору хисе уяна. «Әгәр Гаяз Исхакый бары тик шушы әсәрен генә язган булса да, бу әсәре аның исемен мәңге яшәтер иде», – дип яза Сания Гыйффәт үзенең мәкаләсендә.

1939 елда алар кире Төркиягә әйләнеп кайталар һәм гомерләренең ахырына кадәр инде шунда яшиләр.

Сания Гыйффәт тә Төркиядә татар мөһаҗирләреннән Садри Максуди, Камал Локман, Хәмит Зөбәер, Гаяз Исхакый, Фуад Туктаровлар белән аралашып һәм алар кебек үк, большевиклар дәүләтенең җимереләчәгенә һәм татар халкының бәйсез дәүләтчелеген төзиячәгенә өмет белән яшәгән.

1954 елда «Милли байрак» журналында чыккан «Антыбыз» шигыре шул турыда сөйли:

Күтәрелгән байрак төшмәс кулдан,
җил-яңгырлар, карлар яуса да.
Чыккан юлдан кире кайту булмас,
Юл өстендә ниләр ятса да.
Милли юлның йомшак эзләрендә
Ил рәхәтен эзләп тапканчы,
Бу эзләрне күзләп юл алырбыз
Хөр көннәргә барып чыкканчы.
Билне бәйләп,
итәк-җиңне сызганып,
Тырышырбыз илгә кайтканчы,
Илне баскан динсез дошманнарны
Күкрәгеннән алып атканчы.
Талаучылар китеп, кайгы бетеп,
Тоткын илне җәннәт иткәнче,
Тузган илне җыеп, йортны төзеп,
Үзирекле көнгә җиткәнче.

Сания Гыйффәт 1957 елның 12 апрелендә 58 яшендә Анкарада йөрәк авыруыннан вафат була. Аның кабере өстенә рәхмәтле Финляндия татарлары бүләк итеп җибәргән истәлек ташы куела.

Үзенең милли хисләр белән сугарылган шигырьләре аша татар милли хәрәкәте идеяләрен кайнар яклаган һәм татар мөһаҗирләрендә киләчәккә өмет уятып, шул өметне сүндермичә яшәтә алган Сания Гыйффәтнең дә кабере — мәңгелек йорты – газиз туган җирдән еракта, чит туфракта... ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни (Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Руми камка, тансык тавар — бикасап,
Казнаң тулмаса да, килер бихисап.

Кәвәл, тази, бөгтәл, тагый, аркуни[1]
Атлыксага тулыр, нәфсең арттырыр.

Токымлы дөяләр, йөз меңнән ашыр,
Языда — елкылар, кутанда[2] качыр.

Язы — таулар тулы куй көтүләре,
И, холыклым, сансыз күп кол-көңнәрең[3].

Козларда кутазлар[4], сансыз-исәпсез,
Далада мөгезле мал — сыер, үгез.

Тау кыялардагы тәкә вә җәйрән,
Котылмаслар синнән, ай, батыр мәргән.

Болан, пошый, сайгак[5] булсын, йә ивүк
Сиңа табыш булыр, и изге холык.

Кулан һәм тау аты, тагы күктәкә
Тотып китерерләр сиңа, и, белкә.

Бүре, төлке, кабан, каплан, аю да
Котылмас, төшәрләр синең авыңа.

Кугукош, курдайлар, торна һәм *югак,*
Вә *тойгон,* йә *йөгдек,* йә *төтлеч,* йә *как,*

Һавада очучы карагош, җүре[6]
Качалмастыр синнән, айә, күкбүре[7].

Очарны очырмас синең шоңкарың,
Йөгерекне йөгертмәс гепард, этләрең.

Аталы киекләр атасыз калыр,
Аналы — анасыз, үксез каңгырыр.

Бу кадәр мөмкинлек тә синең өчен
Аз кебек, әлбәттә, и, егет, көчлем.

Бер уйлап карасаң, бу ич комсызлык,
Комсызлык ач эттәй: һич тә булмас тук.

Бу байлык барчасы тамакка, өскә
Җыйдың, тик ни файда — кала ич, үлсәк.

Бу дөнья байлыгын җыйгач, ахыры
Шул — әҗәл килә дә өзә тамырыңны.

Канәгать кешеләр әнә ни сөйли:
«Рухи байлык башы канәгатьлек», ди.

**Бу дөнья байлыгын җыйгач, ахыры
Шул — әҗәл килә дә өзә тамырыңны.**

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.
[1] Бу сәтырда борынгы затлы ат токымнары санала.
[2] Кутан — түбәсез балчык, кәс (торф) абзар.
[3] Көң — кол катын.
[4] Коз — тауның кояш төшкән ягы, кутаз — як (тауларда яшәүчән мөгезле хайван).
[5] Бу атамалар шартлы, оригиналда бүтән, бигүк ачык булмаган атамалар.
[6] Курсив белән язылган атамаларның хәзерге эквивалентлары төгәл билгеле түгел.
[7] Күкбүре — төрки халыкларның тотемы, аларны ияртеп йөргән юламан бүре.

Комсыз кулга кертеп бөтен дөньяны,
Мактанса да, бай дип булмый һич аны.

Фәкыйрьнең фәкыйре шул инде үзе,
Кем һаман баегып та туймас күзе.
Тынычлык тапмас һич комсызның җаны,
Йа, Ходай, гөнаһын ярлыка аның.

Комсызга котлы көн тәтемәс һич тә:
Яшәү котлылыгы канәгатьлектә.

Ач күзле тутыра алмас нәфесен —
Кара туфрак кына тутырыр күзен...

Минем белгәннәрем шулар, илбик.
Үзем аңлаганча аңлатып бирдем.

Һәм мин сөйләгәнне аңладың бугай,
Күзең күп нәрсәгә ачылыр шулай.

Файдасы тиядер, тотсаң, сүземнең,
Ә тотмасаң сиңа бурыч, йөк инде.

Ни, ди, ишет, ушлы кешеләр теле
(Әгәр тыңлый белсәң, сиңа бер гыйлем):

«Нәсыйхәт кешегә файдасыз түгел —
Тыңлаучы булса, син сөйлә бер үгет.

Әгәр ул игътибар итмәсә һич, син
Аралашма аның белән — чәнчелсен».

ИЛБИКНЕҢ СҮЗЕ

Боларны ишеткәч илбик егълады,
Әйтте: — И, инсанның уяу угланы,

Син инде оҗмахлы — хәстәрен күрдең,
Ә мин билегемә бәйләнгән инде.

Мин инде аңладым — ачылды күзем,
Мин утка атканмын үземне үзем.

Тугрылыктан чыгып читкә киткәнмен,
И, олуг, син тугры юлны күрсәттең.

Дога кыл, Уйгырмыш, зинһар, миңа син.
Алла тәүфыйк бирсен, рәхмәт әйләсен.



Ач күзле тутыра алмас нәфесен —
Кара туфрак кына тутырыр күзен...

УЙГЫРМЫШНЫҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Уйгырмыш әйтте: — И, бием,
Ходайдан теләгәнчә тәүфыйк телим.

Акыл илә бастыр горурлыгыңны,
Горур булды — хур булды Адәм углы.

Сине һәлак итә җан-тән рәхәте:
Азынса, тыелмас булыр шулхәтле.

Бу дөнья бик иске һәм күпне күргән:
Бик күп биләрне ул төшерде түрдән.

Картайтты ул бик күп сындәй ирләрне,
Элгәрләр артыннан сине җибәрер.

Алар китте сиңа урын калдырып,
Утырдың — әзер бул китәргә торып.

**Үлемне онытма: борын төбендә.
Үзеңне онытма: нур ул йөзеңдә.**

И, илбик, үлемне онытма, кара,
Ул шиксез, килеп тә җитәр тиз ара.

Үзеңне онытма, и, илбик, саклан,
Асылыңны уйла, әгәр онытсаң.

Бу ике нәрсәне җуйсаң әгәр син,
Аңнан ераклашып, юлдан язарсың.

Ни ди, нәфесеннән үзен йолган ир,
Нәфесен акылга әсир кылган ир:

Үлемне онытма: борын төбендә.
Үзеңне онытма: нур ул йөзеңдә.

Күңлең кәперәйсә, «син — фани» диген,
Минлегең «мин!» дисәң, «син — мәни» диген.

Торадыр поскында, күренми үлем,
Тик алмыйча калмас ул синнән йолым.

«Барсына ирештe», дисәң үзеңне:
Хәтереңә төшер ачы үлемне.

Никадәр эш бар бу дөньядан башка,
Аларны эшлисе үлем юл ачса.

Нинди вакыйгалар булыр кабердә,
Тәмам черегәнче син кара җирдә.

Бу хәлләрне белеп уйлаган кеше
Ничек тыныч йоклый һәм ашый ашын.

Ни ди, ишет, сиңа белек бирүче,
Белемеңдә һиммәт юлын күрүче.

«Бөек бел һиммәтне, идез күңелне,
Куя бир дөньяның фани чүбеген.

Бу дөнья бер төнәк, анда күп елан,
Аны ташла якты төшкә чык, углан.

Татлы җанга соңгы кием — кара җир,
Шуларны уйла син, и, холыклы ир.

Бу дөнья төнәк ул, караңгы кое,
Бәла, михнәт монда, әшәке, кыен.

Табарсыңмы тынгы төнәктә торып?
Ушың җый: нишлисең монда утырып.

Куйсана дөньяның көпшәк туфрагын,
Мәңгелек җир эстә, ә бу җир — сагым[8].

Бу томан-тузаннан коткар үзеңне,
Пакь, мәңгелек илгә юнәлт күзеңне.

Ничә мең ел яшә — ахырда үлем
Куып җитәр сине, и, якты көнем.

Никадәр арттырсаң дөнья кууны,
Шулкадәр артыр гамь, и батыр углы.

Ничә мең ел яшәп ир теләсә теләк,
Теләге үтәлмәс барыбер төп-төгәл».

Ишетче, инсафлым, ни дигән бер зат
(Заман угы тигән күңлеңдә газап):

«Тулы мең ел яшә, үтәп теләгең,
Уңышың булса да, җитмәс төгәллек.

Теләкле теләкнең төгәлен теләр,
Теләге төкәнсә, ул нишләр? Үләр».

Сүзнең файдасы юк артык сөйләнсә,
Йә вакытны алса шаккаткыч нәрсә.

Сүзнең файдасы шул — аны ишеткәч,
Кеше сайлый уң юл, тизрәк эш итә.

Күп сөйләдем инде, ишеткән сүзнең
Тотып төп мәгънәсен, үстер син үзең.

**Татлы җанга соңгы кием — кара җир,
Шуларны уйла син, и, холыклы ир.**

[8] Сагым — мираж, проекция.

Тыелмады телем — күбрәк тибрәлде,
Сүзем киселмәде — суты түкәлде.

Ходай бирсен тәүфыйк сиңа, и, илбик,
Һәм кулыңнан килсен барча изгелек.

Теләгеңне Тәңре үтәсен синең,
Догаңда онытма, и, илбик, мине».

Сүзен кисте. Торып аякка басты.
— Утыр, – дип ил башы аны туктатты.

Китертте төрледән алдына аш-су,
Әйтте: — Изге зат аз гына ял алчы.

Илбик әйткәч, авыз итте Уйгырмыш,
Китергәнне ашап эчте бер тыныш.

Ләкин үтәгәчтен тиешле шартны,
«Аллаһу әкбәр» дип аштан баш тартты.

Шуннан соң Уйгырмыш хушлашу сүзен
Әйтте һәм озатты ил башы үзе.

Уйгырмыш чыкканчы сәрай-бинадин
Калышмады илбик аннан бер адым.

Саубуллашкач инде Уйгырмыш, күрче,
Гамьле төстә илбик аңар кул бирде.

Таугача Үгделмеш аны озатты,
Кулларын үбәргә бераз туктатты.

— Кайт инде, кардәшем, —
дигәч Уйгырмыш,
Ниһаять, өенә китте Үгделмеш.

Килеп керде өйгә күңле буш хәлдә,
Йоклый алмый ятты, белми нишләргә.

Көнчыгыштан кояш йөзе күренде,
Җир өстенә аккош төсе өртелде.

Күтәрелгәч кояш күкрәк тиңгеле,
Җир йөзе агарды кафур шикелле.

Кояш тәмам баскач аякларына
Фәрештә шикелле нурланды дөнья.

**Хәзинә һәм гаскәр — бийләрнең көче,
Алар шулар белән ала үз үчен.**

Үгделмеш торды һәм түшәген төрде,
Юынды, намазга ихлас йөгенде.

Киенде, аннары өйдән чыкты да,
Каршигә юнәлде уйчан, тын гына.

Карши капкасыннан үткәч үк йөреп,
Чакырды илбик, бу күренде кереп.

Илбик сораштырды Уйгырмыш хәлен —
Озакмы калганын, кайчан киткәнен.

Азак илбик әйтте: — И, Үгделмешем,
Ачы булды инде ашаган ашым.

Бу көннән соң ничек яшәмәк кирәк?
Бөгелеп үк төштем, басалмыйм үрә.

Нигә инде миңа билек, ил йөге,
Яшәү тамырымны бу кайгым өзде.

Ир-атсыз идарә ителми халык,
Бий ничек эшләсен берүзе калып.

Ир-ат тапсаң, шиксез, кирәк мал-туар,
Югыйсә батырлар җыелмас аңар.

Ни ди, ишет, гаскәр башы булган ир,
Эшен ташлап бийгә хезмәт кылган ир,

Хәзинә һәм гаскәр — бийләрнең көче,
Алар шулар белән ала үз үчен.

Шул ике белән тик бий бөек була,
Икесе җыелса таҗ киеп була.

Җыям, дисәң гаскәр күп әйбер кирәк,
Җыям, дисәң әйбер бер гомер кирәк.

Иңемдә бер башым, бер тамагым бар,
Нигә шунча халык йөген алырга?

Дәвамы бар ■

ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ

Романга бәян

Чыңгыз Айтматов
(1928-2008)

Башы журналның 8 нче санында. Тәрҗемәче – Мөдәррис Вәлиев.

«Еллар узды һәм гаилә тормышының иске рәвешенә хаҗәт тә әкренләп бетүгә таба барды. Ләкин иң зур бәла – олаудагы гаилә чирүгә йөк булып әверелде, зур орышлар, бигрәк тә һөҗүм вакытында һәм сулар кичкәндә тиз хәрәкәт итәргә комачаулый башлады. Дала хакименең, чирү артыннан олау-олау булып баручы хатыннарга, Кояш баешына яу җиңү белән төгәлләнгәнче, бала табуны тыярга, дигән боерыгы да шул сәбәпле килеп чыкты. Ул әйтте:

– Башта Кояш баешы илләрен буйсындырыйк, өзәңгеләрдән төшик, атларны тугарыйк әле, – менә ул чакта олаудагы хатыннар, күпме телиләр – шулхәтле бала тапсыннар. Ә аңарчы төмәннәрдә бала табу хәбәрен минем колакларым ишетмәскә тиеш...

Дошманын җиңү хакына, табигатьнең үзеннән һәм Раббыдан мәсхәрәле көлеп, Чыңгызхан хәтта тормыш кануннарын да сибереп түкте. Ул Раббыбызны да үзенә хезмәт иттермәкче булды бугай, чөнки балага узу – үзе үк Ходайдан вәхи-хәбәр бит.

Хәер, халык арасында да, чирүдә дә мондый башбаштаклыкка беркем ризасызлык белгертмәде һәм каршы торырга уйламады, ул вакытка инде Чыңгызхан хакимлеге шултикле күз күрмәгән көчкә ирешкән һәм дөньяның кендегенә әверелгән иде ки, әмер бирүченең бала тудыруны тыю турындагы моңарчы колак ишетмәгән боерыгына барысы да берсүзсез буйсынды, ә инде карышкан кешенең баш өстенә, билгеле ки, котылгысыз үлем балтасы эленеп куелган иде...

Кояш баешына таба сәфәренә чыкканнан бирле, бөек хакан, менә инде ничәнче көн, юл буенча үзгә, гадәттән тыш рух халәте кичерә. Тыштан ул, мондый дәрәҗәдәге затка тиеш булганча, – тынычлыкка калып, йокымсырый төшкән лачын сыман, кырыс төскә кереп, бар дөньядан читләшкән бер кыяфәттә йөргән була. Ә югыйсә үзенең күңеле күктә, ара-тирә ул җырлап җибәрә, хәтта әле шигырьләр дә иҗат итә:

...Иң хәтәр мәлләрдә, яңгырлы төннәрдә,
төтенлеге белән киез тирмәм каплап,
төнге сакчыларым тора мине саклап,
тора һәм изрәтеп йокыга талдыра.
Бүген юлда сезгә рәхмәт әйтер идем,
дөнья күргән һәм инде чал кергән
сакчыларым:
мине сез бит,
бары тик сез
хан тәхетенә күтәрдегез!
Кышның кары, ап-ак бураннары,
калтыратып җанга сырганнары,
яңгырларның вагы, коен булып органнары,
һәм дә тагын болай гына яуганнары –
барысы-барысы
яуга баручы тирмәмнең бусагасы аша
үтә алмый торды, –
йөрәгем калканы шул сакчыларым булды!
Бүген юлда рәхмәт әйтер идем,

минем кару белмәс һәм
какшамас төнге сакчыларым:
Чыңгызханны бары тик сез күтәрдегез!..
Дошманның каен тузыннан ясалган ук савытын,
аның ишетелер-ишетелмәс кенә кыштырдавын сизеп алып,
сүндердегез фетнә утын
һәм сүттегез мәкер авын,
минем уяу төнге сакчыларым.
Бөтен гореф-гадәтләрне бозып,
сезгә рәхмәт әйтер идем мин бу көнне...
Өер башлыгына тугры бүреләр көтүе,
ай нурында ялларын торгызып,
күзгә күренмәслек бер түгәрәк сызып,
аны урап ала чыкканда ауга.
Кояш баешына таба ачкач яуны,
аерылмас чал яллы көтүем,
ак казык тешләре тәхетемнең,
беләм:
тоташтырып төнне көнгә,
ару-талусыз барасыз алга,
минем белән бергә һаман...
Шуңа сезгә рәхмәтемне җырга салам...

Бу шигырьнең, әгәр ул кеше ишетерлек итеп яңгыраса, Чыңгызхан авызыннан чыгуы һич урынсыз булыр иде, – ярыймы соң инде аңа эчендәгесен тышка бушату! Әмма юлда, иртәдән кичкә кадәр ияр өстендә чагында, ул үзенә мондый рәхәт мизгелләрне генә булса да бүләк итә ала иде.

Күңел тантанасының төп сәбәпчесе – менә инде унҗиденче көн, иртән уянып чыгу белән кичен йокыга талганчы, Чыңгызханның баш өстендә ак болыт йөзеп баруы: ул кайсы тарафка гына юнәлсә дә, күктәге болыт аннан калышмый. Күрәзәченең алдан хәбәр бирүе чын булып чыкты. Кем уйлаган диген син аны! Ә бит ул әкәмәт җан иясен, ачу китергеч һәм акылга сыймаслык тәкәллефсезлеге, оятсызлыгы өчен, шул сәгатьтә үк үтереп ташлаган булсаң? Ярый әле, башы җитеп, мосафирның гөнаһсыз җанын кыймады. Күрәсең, язмышның әмере шулай булгандыр.

Яу сәфәренә чыккан беренче көнне үк, барча төмәннәр, олаулар һәм көтүләр, ташу вакытындагы кара-кучкыл елгалар төсле, күз күрер җирне, офыкларны иңләп, Кояш баешына таба юнәлгәндә, төш мәлендә арыган атын алыштырырга тукталгач, Чыңгызхан очраклы гына өскә карап алды, әмма салмак кына йөзүче кечкенә ак болытка – ә ул, ихтимал, нәкъ аның баш очында катып калган булгандыр, – һичберсе игътибар итмәде, күк йөзендә аның кебек әзме болыт әрле-бирле йөри.

Ул, үз уйларына чумып, иярендә утырган көе, борчылып, тирә-юнен күзәтте, тыңлаучан һәм тырыша-тырмаша дөньяны яуларга ашкынучы күпмеңле чирүенең хәрәкәтенә күз салгалап барды, – алар аның шәхси ихтыярына шулкадәр буйсынган һәм аның ниятләрен тормышка ашыруга шултикле ихласлык белән бирелгәннәр ки, әйтерсең лә болар арасында берсе дә, күңеленнән генә булса да,

аның кебек үк хакимлек итәргә теләүче кешеләр түгел, ә ат тезгенен аралап торган кул бармаклары иде, – аз гына читтәрәк торып үзен озата баручы кизүвыллар һәм ясавыллар алдыннан юлын дәвам итте.

Яңадан күккә күтәрелеп карады, әмма үз өстендә әлеге дә баягы болытны күрсә дә, Чыңгызхан бу юлы шулай ук моны бернигә дә юрамады. Юк, ул, дөньяны яулап алу уе белән шашкан илбасар өстәге болытның ни өчен астагы җайдак белән бер юнәлештә баруы турында уйлап та карамады. Хәер, алар арасында нинди бәйләнеш булырга мөмкин, ди?

Ул болыт сәфәр чыкканнарның берсенең дә күзенә ташланмады, һичкемнең анда эше юк, көпә-көндез таң калырлык могҗиза булыр, дип, һичберәүнең дә башына килмәде. Аяк астына карап барырга кирәк чакта, күзең белән иксез-чиксез күк йөзен айкау кемгә хаҗәт. Чирү, үзәннәр һәм калкулыклар аша, юллар һәм юлсыз җирләр буйлап, җир өстендәге галәмәт зур кара болыт сыман, тояклар һәм тәгәрмәчләр астыннан тузан күтәреп, узылган араларны бәлки мәңгегә кире кайтарып ала алмаслык итеп артында калдыра-калдыра, үз ибе белән алга атлый бирә. Һәм боларның барысы да ханның мавыгуларына, дуамал ихтыярына яраклашып, шуларга риза булып башкарыла, унар меңнәрчә кеше аның – данга, канга, хакимлеккә, яңа җирләр яулауга сусаган иблиснең куалавына, үзенчә илһамландыруына әзер торып, ягъни камчысына буйсынып, перәннегенә ымсынып, көтү шикелле каядыр бара да бара.

Алар шулай юлда булдылар, менә инде көн дә кичкә таба авышты. Караңгы төшкән җирдә төнгелеккә туктыйсы бар, ә иртә таңнан – тагын кузгаласы.

Хан һәм аның яраннары, аларга хезмәт күрсәтүче чербиләр (интендантлар) бу төнне кичәр өчен алдан ук сарай тирмәләрен корып куйдылар. Алар инде алда, ак гөмбәзләре белән ерактан күренеп-чакырып торалар иде. Төп тирмә янында хан һоруңы – ачык кызыл каймалы, уттай ефәк һәм алтын җепләр белән чигелгән, киң иңендәге авызыннан ялкын ургылдыручы аждаһалы кара әләм җилдә җилферди. Юлдан күзләрен алмыйча, кизүвыллар – сайлап алынган төксе чырайлы пәһлеваннар, әмер бирүчене көтеп, әзер торалар. Монда кичке мәҗлес – бергәләшеп ашап-эчеп алу булачак, тәгам кылгач, шунда ук, Чыңгызхан сәргаскәрнойоннар белән, сәфәрнең беренче көне нәтиҗәләрен тикшерү һәм алдагы көнгә ниләр эшлисен киңәшер өчен, тәүге очрашуны үткәрергә җыена. Бөек ташкынның кузгалуы Чыңгызханны аралашу җаена таба тарта – бу кичтә ул нойоннар өчен күңел ачу мәҗлесе оештырырга да каршы түгел, исәбе – алар сөйләгәнне тыңларга һәм аларга үз боерыкларын җиткерергә; аның авызыннан чыккан акыллы сүзләр, аларның барысы да һәм һәркайсы аерым-аерым, өсте алынмаган сөт кебек, игътибар куерыгына әверелеп тыңланганда, Дөньяның Дүрт Тарафына әйтелгән шикелле булачак, тиздән җиһанның һәр тарафы һичбер карусыз аның авызына карап торачак, шуның өчен чирү белән бара да бит инде ул, – үз сүзен сүз итәргә дип. Ә сүз – ул мәңгелек көч.

Әмма соңра Чыңгызхан мәҗлес үткәрү уеннан кире кайтты. Күңелендәге тынычсызлык аның япа-ялгызы гына калуын таләп итте. Һәм менә ни өчен...

Ялга тукталу урынына җитәрәк, Чыңгызхан кабат – инде өченче мәртәбә баш очындагы таныш болытка игътибар итте. Һәм шул мәлдә аның йөрәге жу итеп китте. Акылга сыймаслык сизенүеннән хәйран калып, аның тәненә салкын йөгерде һәм күз күремендәге җир йөзеп киткәндәй булды – ул атының ялына көч-хәл белән ябышып өлгерде. Мондый хәлгә аның әле беркайчан тарыганы юк, чөнки кара

күкрәкле Этуген Җирендә, җиһанның яшәү һәм хакимлек өчен Күк-Тәңре тарафыннан бүләк итеп бирелгән шул какшамас нигезендә, чынлыкта булган берни дә моңарчы аны шулкадәр, көтелмәгәнлектән аһ итәрлек хәлгә төшереп, аптыраштта калдыра алмады, инде барысы да баштан кичерелгән, дөньядагы бернәрсәнең дә аның үтә аек акылын хәйран итәргә, канлы эшләрдә күпне күргән күңелен сокландырырга яки кайгыга салырга көченнән килмәс кебек иде, һичкайчан, үзенең ханлык дәрәҗәсен төшереп, ниндидер хатын-кыз шикелле, ат ялына куркып ябышканы булмады. Мондый хәлнең булуы мөмкин түгел һәм ул булырга тиеш тә түгел, чөнки күптән инде, яшь-яшел чагында, елгадан тоткан вак балык аркасында сүзгә килеп, ә чынлыкта иртә уянган бүре тоемы белән, аларга язмышның бер ияреңдә утырырга язмаганлыгын аңлап алганлыктан, карындаш үсмер энекәше Бектерне җәядән атып үтергәннән бирле, – әйтергә мөмкин, шул вакытлардан ук тормышны коруның иң ышанычлы, хатасыз юлы – көч белән басу икәнлегенә төшенеп, көчкә буйсынмый калган, аның каршында тезләнми торган берни дә юклыгына, ташмы яки утмы, су, агач, ерткыч җанвар яки кошмы булсын, ә мескен адәм баласын искә төшереп торасы да юк, – барчасының да тупас көч астында сүнеп-тоныкланып калуына, көлгә әйләнүенә инанган иде ул. Көч көчне сындырганда, гаҗәп тоелган нәрсәләр дә бик кечкенә, ә гүзәллек исә кызганыч булып кала. Шуннан килеп чыккан нәтиҗә: таптап уза алган бөтен нәрсә дә тузан бөртегедәй вак, ә каршысында йөзтүбән сузылып ятканнарның һәммәсе, мәрхәмәтлек күрсәтергә теләгән кемсәнең талымына карап, беркадәр йомшаклыкка өмет итә ала. Дөньясы шуңа корылган...

Ләкин кайчагында, Һималайдан килүче сәйяр китапчылар аңлатуындагы Мәңгелек һәм Чиксезлек гәүдәләнеше булган Күк-Тәңре турында сүз барганда, анысы – бөтенләй башка нәрсә. Әйе, акыл белән иңләп-аңлап бетереп булмаслык Бөек Күк, бары тик ул гына аңа буйсынмый, аны үрелеп алу да, кулда тоту да мөмкин түгел. Күк-Тәңре хозурында хакан үзе дә бер тузан бөртеге генә – аны куркытып та, аңа каршы баш күтәреп тә, яу белән барып та җиңә алмый. Җирдәге язмышлар һәм, Һималай китапчылары раслаганча, дөньялар хәрәкәте белән идарә итүче Күк-Тәңрегә табынырга һәм белгән догаларыңны укырга гына кала. Шуңа күрә, гомеренең соңгы көненнән котыла алмаган һәркем кебек, ихлас ышанулары һәм корбан чалулары белән, Күктән аны үз канаты астына алуын, аңа яхшы мөнәсәбәтен белдереп, кешеләр дөньясына ныклап хакимлек урнаштыруда ярдәм күрсәтүен һәм, сәйяр акыл ияләре раслаганча, Галәмдә мондый дөньялар исәпсез-хисапсыз икән, җир дөньясын аңа, Чыңгызханга, тулысынча һәм беркем белән дә бүлешмичә идарә итәр өчен бирсә ни була инде, дип, аны үз нәселенә, буыннан – буынга күчә барасы биләмә итеп билгеләвен ялынып-ялварып сорый, чөнки җир йөзендәге адәмнәр арасында аңардан да кодрәтлерәк һәм лаеклырак зат бар микән әле; гөманлавынча, Дөньяның бөтен Дүрт Тарафын тезләндерергә хәленнән килердәй, көче-куәте ягыннан аңардан өстенрәк торучы юк. Тирән, яшерен күңел төпкелен айкап, Чыңгызхан әлегә бүтән берәү дә Күк-Тәңредән сорарга җөрьәт итмәгән нәрсәне – илләр, халыклар өстеннән чиксез хакимияткә рөхсәт бирүен үтенергә үзгә хакы барлыгына торган саен ныграк ышана бара, – чыннан да бит кемдер берәү әлеге тәхетне биләргә лаеклыдыр, бәс, шулай икән, ул башкаларны көч белән буйсындыра алучы булырга тиеш! Чиксез рәхим-шәфкатьле Күк аның яулап алуларына, хакимлеген көчәйтүенә моңарчы комачаулык итмәде, һәм Күкнең аны аерым исәптә тотуына, аның кешеләргә күренмәс-беленмәс югары

көчләре Чыңгызхан ягында булуына ышанычы торган саен ныгый барды. Аңа моңарчы ни кыланса да килеште, – ә бит ул ут һәм кылыч белән узган бөтен төбәкләрдәге иңрәүчеләр авызыннан аның башына нинди генә ярсулы бәддогалар яумады, әмма бичара каргышларның берсе дә аның артканнан-арта баручы куәтенә, бөеклегенә һәм дөньяны тетрәткән шанына ат кылы калынлыгы да күләгә төшерә алмады. Киресенчә, үзен күбрәк каргаганнары саен, ул Күккә юнәлгән сыктау һәм аһ-зарларны тагын да үҗәтләнебрәк санга сукмый башлады. Дөрес, юк-юк та, Күкнең ачуын китерүдән сагаеп, күкләр җәзасын татырга туры килмәгәе, дигән авыр шик күңеленә боз булып төшкән мизгелләр дә булмады түгел. Шундый чакларда бөек хан күпмедер вакытка өнсез калып, үзен йөгәнләп тора, кул астындагыларга җиңелчә сулыш алырга мөмкинлек биреп ала һәм Күкнең гадел шелтәсен кабул итәргә, хәтта тәүбә итәргә әзер була. Мәгәр Күк ачуланмый, үзенең канәгатьсезлеген берни белән дә белгертми һәм чиксез мәрхәмәтеннән мәхрүм итми иде. Һәм ул, Күк гаделлеге саналган нәрсәләрне таптап, комарлы уендагы сыман, тагын да тирәнрәк гөнаһка бата, Күкнең түземлеген сыный. Ә Күк түзә! Һәм, шуннан чыгып, ул үзенә ни кыланса да ярый, дигән нәтиҗә ясый. Еллар узган саен, аңарда Күкнең сайлап алган кешесе нәкъ менә ул икәнлегенә, үзенең Күк Улы булуына ышанычы ныгыганнан-ныгый бара.

Әкиятләрдә генә ышанып була торган нәрсәләргә – зур бәйрәмнәр вакытында атка атланган җырчыларның, халык төркемнәре алдында йөренгәләп, аны Күк Тудырган дип җырлар чыгаруына һәм шулчакта меңләгән кулның шатланып Күккә күтәрелүенә ышанганга түгел, – чөнки болар мескен-ялагай кешеләрнең тәлинкә тотуы гына икәнен аңлый дала хакиме, – бары тик тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, барча эш-гамәлләре Күк-Тәңренең уй-ниятләренә туры килгәненә күрә, Илаһи Күк аны яклый, дип, башкача әйткәндә, ул үзен Җир йөзендә Күк-Тәңренең ихтыярын тормышка ашыручы бердәнбер зат, дип фараз итә, Күк исә, аның кебек үк, бары тик тупас көчне, әлеге көчнең иясен һәм теләсә нинди максатка көч күрсәтеп кенә ирешеп булганын таный, дип уйлый һәм нәкъ менә ул гына, һичшиксез, шул таләпләргә тап килә, дип саный иде...

Югыйсә, вакыт-вакыт аның үзен дә гаҗәпкә калдырган хәлне – борын-борыннан аучылык һәм малчылык белән көн күргән, хәерчелеккә төшкән вак арат-киятлар ыругыннан булган ятим малайның, текә генә күккә күтәрелеп киткән лачындай, дәһшәтле дә, баш әйләндергеч тә дан биеклекләренә, дөнья белән идарә итү дәрәҗәсенә шундый тиз, ашкынулы менүен башкача ни белән аңлатырга мөмкин?! Тарихта күрелмәгән чиксез зур хакимияткә ирешү ничек була алды соң, – ә бит аңа, иртәгесе көнгә өмете өзелгән, шулай да әрсез-чая ятимгә, тормыш, иң яхшы дигәндә, курку белмәс йорт басучы яки ат карагы язмышын гына әзерләп куярга мөмкин иде, һәм башта ул шул юлга баскан да иде. Күрәзәлек итеп торасы юк – нибары сыңар арык аты гына булган Темучинны, Күк-Тәңре катнашыннан башка, авызыннан ут ургып торучы алтын аждаһалы һоруң-әләм көтмәгәндә генә урап алмас, беркайчан да аның Чыңгызхан дигән олы исеме булмас һәм Алтын тирмә гөмбәзе астында шулай вәкарь белән генә утырулар аның төшенә дә кермәс иде!..

Һәм менә барысы да шул сәбәпле икәнлеген, Азия хаканына Күкнең теләктәш мөнәсәбәтен раслаган, һич кире каккысыз шәһадәтлек, ачык дәлил булып күзгә күренеп тора! Карагыз, әнә ул – үзенең диваналыгы аркасында башын югалтудан чак кына котылып калган илгизәр күрәзәче алдан белеп әйткән гаҗәеп болыт. Ә бит аның сүзләре чынга ашты! Ак болыт – Күк-Тәңренең үз Улына хәбәр салуы,

аның эш-гамәлләрен хуплавы һәм аңа фатиха бирүе, ул – алдагы бөек җиңүләр турында киләчәктән хәбәр билгесе.

Яу белән баручы күп меңләгән кешедән берсе дә үзләренә ияргән ак болытка игътибар итмәде, кайдан килеп чыккан ул, нинди максат белән – һичберәүнең боларда гаме юк иде, гомумән, мондый могҗиза булу ихтималы беркемнең дә башына килмәде. Ирекле болытлар агышын кемнең булса да күзәтеп торганы бармыни?.. Бары тик ул – дала чирүенең башында торган һәм аны дөньяны яулап алырга кузгаткан бөек хакан гына әлеге ак болытның илаһи мәгънәсен аңлый, берочтан үзенең гадәттән тыш сизгерлегенә хәйран кала һәм башка сыймастай мондый хәлнең булуына бер ышана, бер ышанмый да иде. Аны шулчак газаплы шик-шөбһәләр биләп ала – бу күзәтүләрен һәм фикерләрен кем белән булса да бүлешергәме, әллә бүлешеп торасы түгелме? Әгәр ул кемгәдер серен ачса, бәлки, болыт, тотар да, күз ачып йомган арада күздән югалыр? Кешеләр аны акылдан язган, дип уйламасмы? Бераздан аның рухы яңадан нygыган кебек була, ул кабат, ак болытның, мәгънәсез бер шаяру гына булмыйча, Күк тарафыннан җитди билге итеп җибәрелгәнен, кинәт юкка чыкмасын аңлый, һәм шулчак аны шатлык, куәтле күңел күтәренкелеге биләп ала: үзенең зирәклегенә, Кояш баешын яулап алырга дип сәфәр чыгуының хата түгеллегенә инану, зарыгып көткән максатына ирешү – кылыч һәм ут белән бөтен дөньяны тез чүктерү, мәңге какшамас зур мәмләкәт төзү нияте тагын да ныгый төшә. Ул шуның белән яши башлый. Аны күптәннән уянган дәрте – комсыз хакимияткә ашкыну теләге әйдәп бара. Күбрәк алган саен, нәфесе котыра гына...

Күзләре канлы орышларга сусаган яу, үткен хәнҗәр кебек, даланы тураклап, Кояш баешына таба котылгысыз сәфәрен дәвам итте.

Ә югарыдагы ак болыт... Ул, атаклы юргасы Хуба иярендә тәхеттәге сыман мәгърур гына оеп баручы Чыңгызханга ияреп, бер якка да тайпылмыйча, талгын гына йөзүен белде. Юрганың ялы ак, ә койрыгы кара, – ул бит тумыштан ук шундый иде, – белгәннәр әйтә, андый ат үзенә аерым йолдыз астында мең елга бер туа, дип. Ул чынлап та дөньяда тиңдәше юк коры җир көймәсе булып, чабышкы түгел, ә озын юлны йөзеп кенә, армый-талмый үтә торган мал иде. Менә Хуба, туктаусыз яуган коен кебек, дымлы-кайнар сулышы белән җирне сугарып, бер алынган киеренке тизлектә туктаусыз юргалап бара. Авызлыгы булмаса, мондый ат артыгын тырышып хәлдән таярга, явып арыган яңгырның соңгы тамчысыдай кибеп бетәргә әзер. Борын заманда бер акын әйткән: андый атка атланган кеше үзенең үлемсезлегенә ышана башлый, дигән...

Шул мәлдә Чыңгызхан үзен бик канәгать, бик бәхетле итеп тойды. Аңа күктән һәм җирдән илаһи көч иңде, әйтерсең лә ул да ару-талуны белмәс юргага әверелгән иде, максатына йөгерә-йөгерә бару сусынын басар өчен, чабып барган атның ярсулы кан әйләнешенә җаны-тәне белән тоташып, кичекмәстән хәрәкәт итәргә ашкынды.

Әйе, җайдак белән ат бер-берсенә тиң иде, – берсен-берсе дәртләндереп, бер көч икенчесенә куәт өстәде. Шунлыктан мал иясенең утыру рәвеше дә лачын торышын хәтерләтә иде. Бөтен булмышы белән ияргә сыланган киң җилкәле, базык гәүдәле, бакыр йөзле бу җайдак аяк табаннарын да, масаебрак һәм үз-үзенә нык ышанган кыяфәттә, ачу китергеч итеп өзәңгеләргә терәгән. Ат өстендә ул тәхеттәгедән дә болайрак булып, сынын катырып, башын югары тоткан хәлдә, кысык күзле калку яңагына, бөтен чыраена таш кебек кырыс, рухсыз төс чыгарып утыра. Аңардан дала йөзен кара болыт каплаган кебек иге-чиге күренмәгән галәмәт зур чирүне данга

һәм җиңүләргә әйдәп баручы бөек хаким куәте һәм ихтыяр көче бөркелеп тора...

Билгеле, Чыңгызханның мондый күтәренке рухи халәтен аңлатырлык үзгә бер сәбәп бар, ул – йөрәгенә мөһер итеп басылган Күк-Тәңре тамгасы булып, аңа үзе юраган бөек вазифасының көмеш таҗы сыман баш өстендә эленеп торган ак болыт. Һәм, шул яктан карасаң, барысының да үзара бәйләнештә икәнен күрергә мөмкин. Болыт... Күк... Алда, хәрәкәт юнәлешен билгеләп, байрак йөртүченең кулларындагы яу әләме – алтын аждаһалы кара һоруң җилферди, ул бер үк вакытта Чыңгызханның кай тирәдә икәнлеген дә күрсәтә. Һоруң янында алар өчәү иде – тәэсир көче белән теләсә кемне аяктан егарлык, үзләренә ышанып тапшырылган гадәттән тыш мактаулы вазифадан башлары әйләнеп, горурлыклары ташып ашкан өч байракчы. Өчесе дә сайлап алган кебек бертөсле чем-кара атка атланган. Уртада – байракның сабын тоткан пәһлеван, аның ике ягында – ялангач сөңгеләрен алга каратып аскан, аны озата баручылар. Хаканның юлын бизәп, ефәк һәм алтын белән чигелгән киң кара тукымадан гыйбарәт әләм җилдә җилферди, аңа төшерелгән, авызыннан ялкын ургытучы аждаһа да шуңа күрә җан кергәндәй булып бөргәләнә иде. Әнә ул аждаһа очып барган шәпкә дошманның өстенә сикерә, ә аның бөтенесен күреп торган, ачудан дөянеке сыман бүлтәеп чыккан коточкыч күзләре, җилдә йолыккаланган әләм белән бергә, чыннан да тере кебек, як-якка тәгәри...

Ару-талуны белмәс хакан, таң тишегеннән ияргә менеп, чирүне алга әйдәкли. Үз хәбәрләрен җиткерү өчен, аңа төрле тарафтан атларын куалап, нойоннар килә дә, барган шәпкә генә күрсәтмәләр алгач, аның яныннан, чаптырып, кире үз урыннарына кайтып китәләр. Яуга төп киртә булачак бөек Идел ярларына кыш капкасындагы салкын яңгырлар, юл өзеклекләре башланганчы барып җитәр өчен ашыгырга кирәк иде, аннары инде боз катканны гына көтеп торасы һәм алга, хыялда йөрткән максатка – Кояш баешы җирләрен буйсындыруга таба юлны дәвам итәсе була.

Ул көнне төн караңгысына чумганчы диярлек иярдән төшмәделәр. Инде офыкка яткан кояш нурларында эңгер-меңгер алдындагы дала шундый иркен булып җәелде ки, бу җирләрнең шултиклем күз иңләмәслек икәнлеген, мөгаен, башка бер вакытта да болай ук күреп-аңлап булмас иде. Үзе яртылаш офык артына чумган хәлдә дә, алсу-кызгылт буяуларын кызганмыйча, киңлекләрне коендырган кояшның соңгы шәфәкъ нурларына, рәт-рәт булып, томан каплаган кара болакларны хәтерләтеп, ничәмә-ничә төмән, алардагы меңнәрчә җайдаклар кереп чума-кушыла бара.

Атларның талчыккан аркалары бары тик төн җиткәч, гаскәр йокы аланына туктагач кына, ияр һәм җайдаклардан бушап, ял итә ала.

Әмма киченнән ялга тукталган урында, таң ату белән, гаскәрне яңадан яуга өндәп, добулбаслар – үгез тиресеннән ясалган искиткеч зур барабаннар дөпелди башлый. Дистә меңләгән кешене йокыдан аеру бик җиңел түгел. Шуңа уятучыларга шактый тир түгәргә туры килә – добулбасларның бертуктаусыз гөрселдәве тирә-юньдәге бөтен тирмә-чатырларга каты шау булып тарала иде.

Ул сәгатькә хакан инде аягына баскан. Беренчеләрдән булып диярлек уяна да, әле аяз, кояш сарысы гына саркылган көзге иртәләрдә сарай тирмәсе тирәсендә йөренгәләп, зиһенен бер ноктага туплап, төн кичкәнче башына килгән уй-фикерләрне кабат уеннан кичереп, ниндидер күрсәтмәләр бирә һәм шул арада чирүне ияр вә тәгәрмәчләр өстенә менәргә мәҗбүр итүче добулбаслар гүләвенә дикъкать белән колак сала. Чираттагы һәр көн шулай башлана, бераздан тавышлар ишәя, хәрәкәтләр ешая, төнгелеккә өзелеп торган сәфәр янә үз эзенә төшә.

Ә добулбаслар һаман гөрселди. Аларның иртәнге шавы, гөрелтесе, йокыдан торырга чакыру авазы гына түгел, нининдидер зуррак, бөегрәк максатны күздә тотучы чаң, таләпчән һәм беркемгә дә буйсынмас нык ихтыярлы әмирнең әлеге максатны исләренә төшерүе булып яңгырый. Шул рәвешле, Чыңгызхан үзенә ияреп бөек сәфәргә чыккан һәркемне куалый: барабаннар шавы белән, тирмәләрнең төн кичәр өчен генә вакытлыча ябылып торган киез ишекләренә һәм уянып килүчеләрнең аңына үтеп керә, нинди генә акыллы фикер булмасын, әгәр аңардан чыкмаган икән, ул аны аяк астына салып таптый да үзенекен тага, чөнки адәм баласы йокы куенында чакта үзенең кемгәдер буйсынганлыгын онытып тора, имештер, ул – хөр, ирекле зат, шуңа күрә дә йокы – алама, заяга узган гомер, хыялый, әмма хәтәр азатлык мәле, андый башбаштаклыкны йокыдан айнуының беренче мизгелләрендә үк кешенең аңыннан, калебеннән бәреп чыгарырга, уянган һәркемне янә өнгә – бары тик хаканга гына берсүзсез буйсынуга, хезмәт итүгә, хәрәкәт эченә кайтарыр өчен, ике дә уйламыйча, «ирек» дигән ул чүп үләнен кырыс-усал кул белән һич кызганмый йолкып атарга кирәк.

Добулбасларның үгез үкерүенә охшаган шыксыз гөрселдәве һәрюлы хәтта Чыңгызханның да тәненә салкын йөгертә, ул аның яшүсмер чагындагы иске күңел истәлегенә бәйле: берзаман якында гына ике үгез, кыргый тавышлар белән акырышып, тоякларыннан вак таш һәм тузан күтәреп котыра-котыра сугыша башлаган иде, аларның үкерүеннән әсәрләнеп микән, ул, үзе дә аңлап бетермәстән, кайдандыр сугыш җәясен тартып чыгарганын һәм шул мәлдә йокымсырап яткан бертуган энекәше Бектернең күкрәгеи ук белән атып тишкәнен, – алар шуның алдыннан гына елгада икәү тоткан вак балык аркасында сүзгә килгәннәр иде, – төшендә күргән кебек кенә хәтерли. Бектер кыргый тавыш белән кычкырып җибәрде, сикереп торды һәм канга батып янә җиргә ауды, ә Темучин, – әйе, иртә үлгән Есугай-баһадирдан ятим калган Темучин гына иде әле ул, – куркуыннан, җилкәсенә тирмә янында яткан добулбасны асып, якындагы тауга йөгереп менде. Анда, тауга менгәч, ул әчпошыргыч бер тавыш белән туктаусыз барабан кагарга кереште, ә анасы Аголен аста үкереп елый, туганын үтергән мөртәтне каргап-каһәрләп, чәчләрен йолкый иде. Аннары тау янына башка кешеләр йөгереп килде, барысы да кулларын болгап аңа нәрсәдер кычкыралар, әмма ул берни дә ишетми, үҗәтләнеп, барабан кагуын белә. Ни өчендер һичкем аңа якын килмәде, добулбасын дөмбәсләп, ул таң атканчы шунда утырды...

Йөзләгән добулбасның колак ярып гөрселдәве, ярсып үкерүе хәзер исә хаканның сугышка өндәү ораны, батыр йөрәкле һәм кансыз булуы билгесе, үзе белән яуга чыкканнарга бөтен игътибарны туплап күтәрелергә, хәрәкәт итәргә, төп максатка – дөньяны яулауга таба юнәлергә чакыру авазы иде. Алар аның артыннан соң чиккәчә барачак, – офыкның да кайдадыр чиге бар ич, – һәм җирдә яшәгән һәммәсе – ишетү сәләте булган барча адәмчекләр һәм башка җан ияләре, эчтән тетрәнеп, аның сугыш барабаннарына буйсыначак. Инде аның яшерен уйларының аерылмас шаһитына әверелеп килүче ак болыт та – хәтта ул да – читкә тайпылмыйча, иртәнге добулбас тавышларына колак салган кебек, баш өстендә салмак кына әйләнә. Кисәк исеп куйгалый торган җил исә җанлы булып тоелган ут ургытучы аждаһа чигелгән һоруңны кыштырдата. Менә-менә ул аждаһа әләмнән сикереп чыгар да, авызыннан якты ялкын бөрки-бөрки, җил уңаена йөгереп китәр төсле...

Бу араларда иртәләр әйбәт тора иде.

Кичләрен, йокы алдыннан, тирә-юньгә тагын бер күз салыр өчен, Чыңгызхан

тирмә алдына чыгып баса. Һәркайда, буш киңлекләрдә учаклар яна, якын булса – аларның дөрләгәне, ерактарак икән утларының җемелдәве күренә. Хәрби аланнардан һәм олау табырларыннан, ат көтүләрен куып баручыларның торак-тирмәләре тирәсеннән аксыл төтен җәелә – бу сәгатьтә кешеләр тирләп-пешеп шулпа эчә һәм туйганчы ит ашый. Галәмәт зур кисәкләре белән казаннардан алгач, пешкән ит исе ач дала җанварларын шул тирәгә чакырып китерә. Йә тегендә, йә монда мескен җан ияләренең шашынулы күзләре ялтыраганы күренә һәм колакка моңсу гына шыңшып-улап куйганнары ишетелә.

Ул арада халык, чалып ташланган кебек, бик тиз үле йокыга тала. Бары тик ялга туктаган гаскәрнең тынычлыгын саклаучы төнге күзәтчеләрнең генә бер-берсенә аваз салуы тәүлек буена тормышның ныклы тәртипкә салынган бер агымда дәвам итүен күрсәтеп тора. Ул шулай булырга да тиеш инде – һәркемнең үз вазифасы бар, соңгы исәптә барысы да бердәм һәм иң югары максатка – Чыңгызханның дөньяны яулап алу идеясенә тайпылышсыз хезмәт итүгә дүндерелгән. Мондый минутларда, күңеле шатлыктан исереп, ул үзенең гайре табигый асылын – туймас нәфесен, бетмәс-төкәнмәс сусавын, җирләре никадәр киңәйгән саен, шашынып, тагын да чиксезрәк хакимлеккә омтылган зат икәнлеген аңлый, һәм аңа әлеге хакимиятне арттыру максатына туры килгән нәрсәләр генә кирәк, ә шуңа җавап бирмәгәннәренең яшәүгә хакы юк, дигән котылгысыз бер нәтиҗә ясый иде».

Сарүзәктә җәзалап үтерү дә – күп заманнар үткәннән соң Әбүталип Куттыбаев үз башына язып алган риваятьтә тасвирланган фаҗига – менә шунлыктан килеп чыккан каза иде...

«Төннәрнең чираттагысында баравылның (уң кулдагы төмәннең) атлы күзәтчеләре, һәрвакыттагыча уяулык күрсәтеп, хәрби аланнардан тыш, олаулар, көтү куып баручылар һәм төрле хезмәт күрсәтүчеләрнең тирмәләренә дә күз салгалап баралар иде. Бар җирдә дә тәртип. Кичүләр үтеп арыган-талган кешеләр бөтен төштә – тирмәләрдә, чатырларда, ә күпләре ачык күк астында, янып бетүче учаклар янында тезелешеп йоклап ята. Тирә-юньдә тирән тынлык хөкем сөрә, барча тирмәләрдән дә караңгылык саркылып чыга. Күзәтчеләр инде бөтен җәйләүне әйләнеп бетерде дияргә була. Алар өчәү иде. Атларын тыя төшеп, үзара нәрсәдер сөйләшеп алдылар. Боларга өлкән итеп куелганы – йөзбашы бүреген кигән озын буйлы җайдак – ике иптәшенә әкрен генә боерды:

– Йә, булды. Барыгыз, егетләр, черем итеп алыгыз. Ә мин монда тагын бер караштырып килим әле.

Тегеләрнең икесе дә китеп барды. Монда калган йөзбашы исә иң элек күзләре белән бөтен тирә-юньне айкап алды, тынып калган дөньяга янә бер колак салган булды, аннары атыннан төште дә, аны тезгененнән тотып, олаулар, дирбия-каеш ясаучылар, тегүчеләр, корал осталары рәтеннән табырның иң аргы читендәге ялгыз тирмә ягына юл тотты. Ул, уйланып башын игән көе, төрле авазларга колагын торгызып барганда, күктән явып торган ай нурлары аның эре йөз сызыкларын һәм артыннан күндәм генә атлаган Акйолдызының ялтыраган зур күзләрен элемчалым гына яктырта иде».

Йөзбашы Эрдене әлеге тирмәгә якынлашты, күрәсең, анда аны көтеп торырга тиешләр иде. Тирмәдән башына яулык бөркәнгән хатын чыкты һәм ишек төбендә

Дәвамы бар ■

КИЯҮ САЙЛАГАНДА

Сәет Кальметов (1918-1992)

Борын-борын заманда бер игенченең берсеннән-берсе чибәр өч кызы булган. Кызлар үсеп буйга җитүгә, игенче аларны каршысына тезеп утырта да:

– Сөекле кызларым, хәзер сезгә канат чыкты. Очар вакытыгыз да җитеп килә. Миңа ошаган егет сезгә ошамас. Булачак кияүләрегезне үзегез сайлагыз, – ди. Әтиләре авызыннан мондый җылы сүз чыккач, кызлар урыннарыннан сикерешеп торалар да хор белән:

– Рәхмәт, әти җаным, болай булгач, син безне бәхетле итәсең, – диләр. Бер елдан игенченең өлкән кызы үзе сайлаган егеткә кияүгә чыга. Ул Баланлыга килен булып төшә. Икенче елны уртанчы кызы үзе сайлаган егет белән туй ясый да Миләшле килене була.

Ләкин игенченең ике кызы да кияүләреннән уңмыйлар. Бала җанлы ата, моны сизеп алгач та, саргаеп, кибеп беткән кызларын өенә алып кайта. Билгеле, бу хәл игенченең төпчек кызын тетрәтмичә калмый. Апаларының ялгышулары аңа сабак була. «Әти, син миңа кияүне үзең сайла инде», – дип әйтергә мәҗбүр була. Әтисе, минем аңа акылым җитмәс, дип кырт кисә. Ләкин үзе эченнән сызлана. Төпчек кызын да бәхетсез итәсе килми. Икенче көнне атын җигә дә, агач арбасына төпчеген утыртып, Йомрыбаш авылына кузгала. Ул авылда тапкырлыгы, зирәклеге белән дан тоткан акыл өләшүче Мәзәкша карт яши икән.

Игенче, Йомрыбаш урамына керү белән, Мәзәкшаның капкасы янында пар ат җигелгән сиртмәле тарантас торганын шәйли. Эченнән генә, Мәзәкшага акыл сорарга байлар да килә икән, дип уйлый.

Мәзәкшаның өенә җиткәч, атын туктатып, байның чыкканын көтәргә була. Бай озак көттерми. Җилкапканы каерып ача да, бу карт иблисне ничә килсәң дә бизгәк тота, дип, мыгырдана-мыгырдана, тарантаска менеп утыра. Көмеш саплы таягы белән кучерның аркасына төртүгә, китеп тә бара. Игенче дә атын кайту ягына бора башлый. Шулчак капка ябарга чыккан Мәзәкшаның карчыгы аңа сүз куша:

– Туган, борма атыңны, борма. Картым сырхауламый. Байлар килсә генә башын җүләрлеккә сала ул, – ди.

Игенчене җитәкләп өйләренә таба алып китә. Ишектән керү белән: «Карт, чык, буразна яручы килде», – диюгә, мич башыннан атылып Мәзәкша төшә. Тиз генә өстендәге тунын салып, чөйгә элә. Куян бүреген салуга, шүрлектән каен тузыннан ясалган кәләпүш алып, такыр башына каплый. Ягымлы елмаеп, игенче белән күрешә. Аны түр башына утыртып, ни өчен килгәнен сорашкач:

– Үзең чыгып тор, кызың керсен, – ди.

Игенче чыгуга, чулпыларын чыңлатып, кызы керә.

– Исәнме, бабакаем, нихәлләрдә яшисең?

– Безнең хәл чыршы кебек, җәй дә яшел, кыш та яшел. Әнә шул түмәргә утыр, кызым. Башта шуны әйт, ни өчен апаларың кияүләреннән уңмадылар?

– Өлкән апаның ире атын да, сукасын да сатып эчкән. Уртанчы апамның ире атын суеп ашаган, сукасын утынга тураган.

– Кызым, сиңа ничә яшь соң?

– Унҗидене тутырдым инде, бабакаем.

– Акылга утырмагансың әле, кызым, хәзергә сабыр ит. Менә үзеңә егерме яшь тулган көнне сиңа яучы җибәргән егетләр минем ишегалдына җыелсыннар. Үзең дә килерсең. Мәзәкша карт нәкъ шул көнне төпчек кызга кияү сайларга вәгъдә иткән.

ӨЧ ЕЛДАН СОҢ

Мәзәкша, ишегалдындагы түмәргә баскан килеш, асыл егетләргә сораулар яудыра:

– Бирегә ни өчен килгәнегезне беләсезме?

– Беләбез, беләбез...

– Игенченең кызы акыллымы?

– Акыллы, акыллы...

– Игенченең кызы эшчәнме?

– Эшчән, эшчән...

– Ул кыз чибәрме соң?

– Чибәр, чибәр...

Мәзәкша кулын тау ягына суза.

–Тау итәгендәге урманны күрәсезме?

– Күрәбез, күрәбез...

– Күрсәгез, ярый. Егетләр, сезгә наказ шул: мин бер пар чабата ясаганчы шул урманны күзәтеп кайтыгыз. Җиргә, күккә карамагыз. Күзегез агачларда булсын.

Егетләр, бердәм кузгалып, урманга юл тоталар. Мәзәкша, өенә кереп, ачык тәрәзә янында торган төпчек кыз янына килә.

– Кызым, егетләргә нәрсә йөкләтелгәнен ишеттеңме?

– Ишеттем, бабакаем.

– Минем карчык белән сиңа да урманга барырга туры килер, шунсыз ярамый.

Кыз белән әби, тиз генә җыенып, өйдән чыгып китәләр.

ӨЧ СӘГАТЬТӘН СОҢ

Мәзәкша, бу юлы түмәрдә утырган килеш кенә, егетләргә сорау арты сорау яудыра:

– Урманны әйләндегезме?

– Әйләндек, әйләндек...

– Безнең урманда нинди агач күбрәк үсә?

Егетләр бу сорауны ишеткәч, аптырап, каушап калалар.

– Йә, кем белә? Шул кулын күтәрсен.

Бермәлдән кыз кулын күтәрә.

– Кызым, син хәзер өйгә кер дә җавабыңны минем карчыкка әйт. Өйдә генә утыр, биредә торсаң, сиңа карап егетләрнең зиһене таралыр.

Кыз тиз генә өйгә кереп китә.

– Егетләр, телегезне йоттыгызмы, әллә сез томаналармы?

Егетләр Мәзәкшаның бу сүзенә гарьләнәләр дә, ни булса, шул булыр дип, агач исемнәрен санап китәләр. Усак, каен, юкә, миләш, балан, чыршы...

Бер читтәрәк, тирән уйга калып, яшел камзуллы егет утыра. Иң ахырда ул кул күтәрә дә:

– Бабай, сезнең урманда кәкре агач күбрәк үсә, – димәсенме...

Егетләр гөр килеп көлешә башлыйлар. Мәзәкша, урыныннан торып, өенә керә.

– Карчык, кызның җавабын әйт әле...

– Ул, безнең урманда кәкре агач күбрәк үсә, диде.

Мәзәкша, йөрәге җилкенеп торган кызны тәрәзә янына алып килә дә:

– Кызым, сиңа әнә теге яшел камзуллы егетне сайладым. Ир белән хатын бер уйда булсалар гына тормышлары түгәрәк була. Кәләпүшемә шулай язылган, – ди. ■

Галиябанунын сәхнәгә менгән көннәре

Мидхәт Фәйзуллин

(Драматург Мирхәйдәр Фәйзи тууына – 125,
атаклы «Галиябану» әсәренең язылуына 100 ел)

Мирхәйдәр Фәйзи 1916 елның җәен Казан губернасы Арча өязенең Шыда авылында бертуган абыйсы өендә уздыра. Шунда яшәгән чакта аңарда «Галиябану» пьесасы язу уе туа. Ул иҗат уты белән яна башлый, айлар буе аның сюжетын ничек кору турында уйлый, көнен-төнен аның күз алдыннан геройлар тезмәсе үтә, колагында әсәрнең лейтмотив музыкасы яңгырый. Орск шәһәренә әтисе өенә кайтканнан соң, Мирхәйдәр Фәйзи ныклап торып өстәл янына утыра, пьеса язу уен тормышка ашыру өчен кулына каләм ала. Нибары өч атна вакыт. Әмма татар авыл тормышын гаҗәеп дөрес һәм көчле итеп чагылдырган, татар драматургиясе өчен яңалык булган бу гүзәл әсәрне тудыру өчен никадәр тырышлык, хезмәт ялкыны кирәк була. Өч атналык эш ул – яшь драматургның күңелендә айлар буе тупланып, өлгереп килгән иҗади хезмәтнең бер йомгагы гына.

Пьеса идеясенең бөтенлеге, драматик композицияләрнең тыгызлыгы, телнең төгәллеге, персонажларның берсендә дә бер генә артык сүзнең булмавы соклану тойгысы уята. Әсәрдәге форма яңалыгы, аның музыкасы, эчтәлек белән табигый үрелеп, тулаем эмоциональ тәэсирне күрсәтә алуына хәйран каласың. Пьесаның гомуми сурәте һәм геройларның характеры реаль, алар тормыштан алынган, әмма турыдан-туры күчереп куелмаган.

Драманың герое Хәлил образының прототибы – Юлык авылының крестьян егете Вафа Әдһәмов. Ул бик матур, күркәм холыклы, ягымлы сылу егет булган, гармунда бик оста уйнаган, тавышы да моңлы булган. Мирхәйдәр аның белән яшьләр уенында, аулак өйләрдә очрашкан. Вафа, Хәлил исеме астында, пьесага бик табигый кереп китә. Галиябану образының өлгесе итеп, Мирхәйдәр күңелендә тирән эз калдырган Шәде кызы алынган.

1916 елның декабрендә пьеса язылып бетә. 1917 елның башында кулъязма Оренбург каласына режиссер Мортазинга җиибәрелә. Тиздән автор соклану белдергән җавап ала, анда пьесаның сәхнәгә кую өчен кабул ителүе турында әйтелә. Премьера 1917 елның 19 мартында Оренбург шәһәр театрында була. Спектакль гаҗәеп зур уңыш белән бара, барлык тамашачылар зур дулкынлану кичерә. Мортазин постановканың уңышлы чыгуы турында драматургка телеграмма җибәреп, аны премьера белән тәбрик итә. Баш рольләрдән Бәдрине – Ман-

Драматург
Мирхәйдәр Фәйзи

гушев, аның хатынын – Иманская, кызлары Галиябануны – Иманская, Галиябануның сөйгән егете Хәлилне – Иманский, Галиябануга күз тотып йөргән бай егет Исмәгыйльне – Садыков, яучы карчык Бәдиганы Сыртланова башкара. Иманскийларның чын фамилияләрен ачыйк – алар Мортазиннар.

Пәрдә ачылды һәм тамашачы күз алдына авыл өендәге бер бүлмә килеп басты. Тәрәзә янында яулык чигеп утырган Галиябану, пәрдәне күтәреп, рамга карый, анда аның үзенә атап чыгарылган җырны җырлап яшьләр уза.

Бакчада гөлләр бар икән,
Гөлдә былбыл бар икән,
Кашы кара, буе зифа,
Галиябану, сылуым-иркәм,
Кемгә насыйп яр икән.

Үзегез өйдә утырасыз,
Тышка чыккан нурыгыз;
Нурыгызга күз чагыла,
Галиябану, сылуым-иркәм,
Яшел пәрдә корыгыз.

Шушы мизгелдән башлап, тамашачының дикъкате сәхнәдән спектакль беткәнче аерылмады.

Спектакль куелгач, Мирхәйдәр

Фәйзигә бик күп котлау хатлары килә. Тамашачылар соклану һәм яңа иҗади уңышлар теләп язалар. Шулардан берсе – Оренбургтан булачак журналист Сәхи Рәхмәтинең спектакльдән соң өченче көнне язылган хаты бик характерлы. Хатның авторы үзенең «Галиябану»ның сәхнәгә беренче премьерасын каравы турында яза. Башта ул сәхнәдәге вакыйганы битараф күзәтүе турында, аннан, вакыйгалар куера барган саен, аны да, башка барлык тамашачыларны да көчле дулкынлану чолгап алуы турында әйтә. Шуннан соң, пәрдә төшкәч, бик озак вакыт алкышлар яңгырап торды, тамашачылар өйләренә таралышканда бик мавыгып спектакль һәм пьеса турында фикер алышалар иде, дип яза. Сәхи Рәхмәти үзенең хатында Мирхәйдәрне зур иҗат уңышы белән котлый, ул халыкны әле яңадан-яңа гүзәл әсәрләр белән шатландырыр, дигән өмет белдерә.

Беренче спектакльдән соң, пьесаны Оренбургның халык йортында, башка шәһәрләрдә дә төрле профессиональ труппалар һәм үзешчән драма түгәрәкләре куйдылар.

Мирхәйдәр Фәйзигә пьесаның текстын җибәрүне, пьесаны куярга рөхсәт итүен, киңәшләр бирүен сорап язган хатлар килә башлый.

Мирхәйдәрнең туган җире Орск каласында да «Галиябану»ны халыкка авторның үз катнашында һәм аның җитәкчелегендә куярга ашыгалар. Спектакль 1917 елның 29 декабрендә «Орск Мөселман яшьләр Союзы» секциясенең җәмгать җыелышы бинасында куела. Шунысы кызыклы, спектакльдә бары бер генә рольдә хатын-кыз уйный, калган рольләр барысы да ир артистлар тарафыннан башкарыла.

Игъланда, Галиябануның әнисе ролен Марфанская башкара, диелгән була. Чынлыкта Мирхәйдәр Фәйзи ул рольдә үзе уйный. Галиябану ролен башкаручы батыр бердәнбер кыз Люси псевдонимы белән чыгыш ясый. Аның чын исеме – Бәдәр Юсыпова. Ул вакытта сәхнәгә чыгарга җөрьәт иткән кыз үзенең абруен гына югалтып калмый, кадимчеләр аның тормышына да куркыныч тудыралар, үч алу белән яныйлар иде. Беренче тапкыр сәхнәгә чыгып, Галиябану образын искиткеч матур башкарып чыкканда Бәдәр Юсыповага нибары 16 яшь була. Мирхәйдәр Фәйзинең башка пьесаларында – «Асылъяр»да һәм «Ак калфак»та да ул төп рольләрне башкарды.

Соңыннан ул, махсус театр хәзерлеге алгач, профессиональ артистка булып китә, аңа Башкортстанның халык, РСФСРның атказанган артисткасы дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Орскидагы спектакль гаять зур уңыш белән үтә. Спектакльнең тамашачылары арасында, татарлар һәм башкортлардан тыш, руслар да була.

Спектакльдән соң Мирхәйдәр Фәйзигә хөрмәт билгеләре күрсәтелә, спектакльдә катнашучылар һәм тамашачылар исеменнән бүләкләр бирелә. Гарәп хәрефләре белән штемпельле кәгазьгә кулдан язылган, «Мөселман яшьләр союзы» мөһере басылган котлау адресында егерме җиде имза, шулар арасында рус кешеләренең имзалары да сакланган. Бу урында «Галиябану» пьесасының рус теленә тәрҗемә ителүен әйтеп китү дә урынлы булыр.

«Галиябану» зур триумф белән Россия шәһәрләре буйлап сәяхәтен башлый. Ул бөтен җирдә тулы залда уйнала, ләкин автор моңардан матди табыш алмый, мораль канәгатьләнү белән генә чикләнә һәм халык мәхәббәтен казана. «Галиябану» пьесасы лаеклы уңышка ирешә, әмма бу уңыш, халыкның бу драмага булган мәхәббәте пьесаның сыйфатына гына кайтып калмый.

Ул бит ил революцион үзгәрешләр кичергән көннәрдә дөнья күрә.

Оренбургта «Галиябану» беренче тапкыр Февраль революциясе көннәрендә куела. Димәк, без аны заман тудырган әсәр, дип тә әйтә алабыз. Пьесада ачык чагылдырылган социаль гаделсезлеккә каршы протест, үз бәхетең өчен көрәш идеясе халыкка якын, социаль каршылыкларның кискенләшүе көннәрендә бу бигрәк тә шулай. Ләкин әле ул «Галиябану» революцион вакыйгалар куерган көннәрдә генә популяр булган дигән сүз түгел. Аннан соңгы елларда да, бүген дә аның сәхнәдән төшкәне юк. Безнең көннәрдә дә «Галиябану» халыкның яраткан әсәре булып кала. Ул театр, шулай ук мәдәният сарайлары һәм клуб сәхнәләреннән төшми. Драманы әле дә куялар, аның героинясы Галиябану һәм аның сөйгән яры Хәлилгә теләктәшлек хисе кичерәләр. Аны татарлар, башкортлар, казакълар һәм безнең чиксез зур илебезнең башка халыклары карый.

«Галиябану» беренче тапкыр 1922 елда Казанда әдәбиятыбыз классигы Галимҗан Ибраһимовның сүз башы белән басылып чыга. Галимҗан Ибраһимов болай дип яза: «Галиябану»ның бөтенләй яңа хасиятләреннән берсе – аның бездә беренче мәртәбә сәхнәгә музыканы, җырны бер иттифакый зиннәт (очраклы бизәк) ясап кына түгел, бәлки төп маддә итеп, асыл мөндәриҗә итеп кертүедер.

Менә шундый хасиятләре белән «Галиябану» бездә ялгыз урында тора, яңа бер баб яки зуррак тәкъбир булса да, әйтик, драмалар галәмендә яңа мәктәп ача һәм шулар аркасында , бик хаклы буларак, гаммә алдында иң кадерле урыннарның берсен ала.

Әдәбиятта һәм театрда башланып килгән яңа дәвер өчен мондый хезмәтләр нигез ташы булырлар».

Г.Кайбицкая Галиябану ролендә, 1940 ел

Бу сүзләрне укыгач, Мирхәйдәр, дулкынланып, түбәндәге юлларны яза: «Әлегә кадәр мине якын кешеләрем – туганнарым һәм иптәшләрем генә мактый иде. Хәзер мин татар әдәбияты классигының мактавына лаек булдым.

Мин бәхетле, әмма минем хезмәтемә булган югары бәя миңа бик күп нәрсә йөкли».

Соңыннан Мирхәйдәр берсеннән-берсе гүзәл яңа әсәрләр язды. Әмма давыллы елларда туган. «Галиябану» әсәре аеруча бер әһәмияткә ия. Мирхәйдәр Фәйзи «Галиябану»ны иҗат итте, ә «Галиябану» аны мәшһүр драматург итте.

«Галиябану», дип әйткән чакта иң элек Мирхәйдәр Фәйзине искә төшерәләр. Әгәр Мирхәйдәр Фәйзи исеме телгә алынса, татар драматургиясенең гүзәл әсәре «Галиябану» күз алдына килә.

Радиода барган материаллардан басмага ***Р.Акъегет*** *әзерләде.* ■

Галимҗан Ибраһимов (1887-1938)



1927 елдан башлап, көчәеп киткән үпкә авыруы аркасында, Галимҗан Ибраһимов даими рәвештә Кырымда яшәргә мәҗбүр була; авыруының вакыт үткән саен җитди төс ала баруына карамастан, әдәби һәм гыйльми эшен өзмәскә тырыша. Ләкин иҗат планнарын үтәп чыгарга насыйп булмый, чөнки үз халкына каршы «зур террор» башлап җибәргән тоталитар режим Г.Ибраһимовны да читтә калдырмый: 1937 елның 29 августында ул Ялтадагы торак йортында кулга алынып, авыру хәлендә этап белән Казанга озатыла һәм шәһәрнең Пләтән төрмәсенә ябыла.

Галимҗан Ибраһимов. Ялта. 1932 ел

Аны, троцкийчы контрреволюцион оешма төзеп, Сталинга, совет-партия җитәкчелегенә каршы һөҗүм әзерләүдә гаеплиләр. Әмма «эш» хөкем-тикшерүләргә кадәр барып җитми, төрмә шартларында тәмам азып соңгы ноктасына җиткән үпкә авыруы (туберкулез һәм плеврит) әдипне 1938 елның 21 гыйнварында төрмә хастаханәсендә дөньядан алып китә. Җирләнүе Казанның Архангел зиратында, дип уйланыла. Әдип-галимнең чекистлар тарафыннан төяп алып кителгән бай кульъязма архивы һәм шәхси китапханәсе исә НКВД подвалларында юкка чыга.

Язучының соңгы көннәрен күз алдына китерү өчен, тоткын Зариф Идрисовның истәлекләренә мөрәҗәгать итик: «1937 ел. Көз. Пләтән төрмәсенең хастаханәсе. Без ята торган тар, озынча камераның бер башыннан икенче башына хәтле, мөмкин кадәр тыгызлап, ике яктан тимер караватлар тезелгән, үтеп йөрер өчен ике арада тар гына юл калдырылган. <...> Арабызда хәрби кешеләр дә бар. Шуларның берсе – мин. Барыбыз да каты авырулар. Шуңа карамастан, камерабызга табиблар сирәк керә. <...>Алар кергәндә калын тимер ишек ачыла, алар чыккач, яңадан бикләнә. Һава тынчу, авыр. Төрмә хастаханәсендә генә була торган авыр ис аңкый.

Менә шундый көннәрнең берендә, кичкә каршы, эңгер-меңгер вакытта, калын тимер ишек шалтырап ачылды һәм аннан өстенә куе күк плащ, башына шундый ук төсле фетр эшләпә кигән, кулына таяк тоткан ябык, саргайган йөзле бер кеше хәлсез генә атлап килеп керде дә, башын бераз ия төшеп, бөтен авырулар белән исәнләште:

– Исәнмесез, иптәшләр! – диде.

Сәламен алдык. <...>

Керүче кеше беркадәр вакыт баскан хәлдә калды, урыныннан кузгалмыйча, зур карасу күзләре белән камераны, андагы кешеләрне сөзеп карап чыкты, аннары билгеләнгән караватка таба китте, өстен салмыйча, кулындагы таягын да куймыйча, аңа авыр гына утырды һәм карашын бер ноктага төбәп, тирән уйга батты. Аның тәмам талчыкканлыгы, хәлсезлеге йөзенә чыккан иде.

Бу халәт,төрмәгә эләгүнең беренче минутларындагы күңел кичерешләре таныш иде безгә. Шуңа күрә булса кирәк, иптәшләр аңа бераз тын утырырга, уйланырга, гадәттән тыш бу вакыйганы тиешенчә күңелдән кичерергә мөмкинлек бирде. Ләкин бу кеше монда кергәнче үк инде үз-үзен кулга алган, фаҗигането котылгысызлыгын аңлаган-төшенгән шикелле иде. Анда ниндидер салкын канлылык, рухи ныклык сизелә иде. <...>

Миннән берничә карават аша озын буйлы, ябык гәүдәле, бик аз сүзле, ярымсукыр бер кеше ята иде. Ул күзләрен күп вакыт ут яктысыннан сөлге белән каплап утыра. Бик аз сүзле, үткен телле, үзенең хәленнән беркайчан да ыңгырашмый. Әллә үзем хәл эчендә яткангамы, әллә ул кешеләр белән аралашырга яратмагангамы, мин бу кешенең кем икәнен белми идем. Хәер, аның да сәламәтлеге начар иде.

Менә шул кеше, яңа керүченең тавышын ишетеп, урыныннан кинәт торды да:

– Кара әле, иптәш Галимҗан түгелме син? – дип сорады һәм, аның җавабын ишетеп, кулындагы сөлгесен ташлады да аңа таба китте. Алар кочаклашып күрештеләр һәм шактый вакыт шул хәлдә калдылар.

Бу кешеләрнең икесен дә мин күңелләрне тетрәткеч шушы минутта гына таныдым. Әле генә безнең камерага кергәне, торышы, күз карашы белән миңа ничектер таныш шикелле тоелганы – Галимҗан Ибраһимов, ә икенчесе – язучы Садри Җәлал иде. <...>

Бу кич Г.Ибраһимов белән С.Җәлал, янәшә утырып, ярымкочаклашкан хәлдә пышылдашып кына озак сөйләштеләр. Бераздан Галимҗан ага, өстен салып, караватка сузылып ятты. Ул яткач та С.Җәлал аның яныннан китмәде».

Тоткын Габделхак Батталовка сүз бирик: «Ул, каты авыру булуына карамастан, өметсезлеккә бирелми, үзенең әрнүләрен, борчылуларын кешеләргә сиздерми, сөйләми, киресенчә, хәтта аларның төшенке күңелләрен күтәрергә теләп, үзенең башыннан үткән кызыклы вакыйгаларны сөйләштергәләп ала иде. <...>

Мин барында Галимҗан агадан бер тапкыр сорау алдылар. Сәламәтлеге бик начар булганлыктан, үз аягы белән чыгып машина-

га утыра алмый иде. Шуңа күрә, тикшерүче Галимҗан ага янына үзе килде һәм аны күршедәге буш палатага алып чыгып китте. Сорау алудан көч-хәл белән генә сөйрәлеп, гаять дәрәҗәдә күңелсезләнеп кайтып керде, караватына егылды һәм бик озак беркем белән дә сөйләшмичә ятты. Тик соңыннан гына белдек: тикшерүче бер төркем алдынгы татар язучыларын гаепләргә, аларны совет хакимиятенә каршы көрәшүче дошманнар итеп расларга теләп протокол төзегән һәм шуңа Галимҗан агадан кул куйдырырга маташкан. Ләкин ул андый ялган кәгазьгә кул куймаган, ә киресенчә, төрле ялганнардан, уйдырмалардан гыйбарәт протокол кораштырырга азапланучы тикшерүченең үзен совет законнарына, партиянең ленинчыл нормаларына бик әшәке рәвештә хыянәт итүдә гаепләгән. <...>



СПРАВКА.

Больной ИБРАГИМОВ Г.Г. находился на излечении в Ялтинской Хирургич. Б-це в 1934 году, где подвергся операции гнойного плеврита. Вторично был оперирован в 1935 году в Хирург. Б-це совместно с д-ром КИШ/резекция двух ребер-первый этап торакопластики/.

Все время находился под моим наблюдением с постоянной консультации врачей ЗВЕНИГОРОДСКОГО, ЦАНОВА Н.И., КУЗНЕЦОВА, д-ра БОГДАНОВА, Проф. ВИШНЕВСКОГО/Москва/ и Проф. КОГАН-ЯСНОГО /Харьков/. Кроме наличия Туберкулезной Эмпиемы и хронической свища правой плевральной полости, страдает еще туберкулезом почек и большим камнем мочевого пузыря, который периодически дает кровотечения. Процесс в легких открытый с кровохарканием и туберкулезными палочками.

Зав. Хирург. Б-цы:/ д-р А.ЦАНОВ/
Консультант: / П. КУЗНЕЦОВ/
/ В.БОГДАНОВ/
З/УП/Л.А.ЗВЕНИГОРОДСКИЙ/

30/УШ-37г.

Әдипнең сәламәтлеге турында белешмә. 30 август, 1937 ел

Әсәрләренең китап кибетләреннән җыелып алынуын, яндырылуын белә һәм моңа гаять дәрәҗәдә ачына иде. Шулай да иҗатының кайчан да булса бер яңадан халык кулына кайтачагына бик нык ышанды.

– Дөреслек ачылыр. Ачылмый калмас, – ди торган иде ул.

– Кайчан ачылыр икән соң ул? – дип сорый идек без аңардан.

– Кем белә бит аны. Бәлки, тиз ачылыр, ә бәлки, ун ел, хәтта егерме ел узар, шулай да ачылыр, – дип җавап бирә иде. – Сез моны күрерсез. Менә шулвакыт китапларым яңадан халык кулына кайтыр һәм мине яхшы сүз белән искә алырлар...»

Тоткын Хәйбик Сибгатуллин истәлеге күрсәткәнчә, Галимҗан Ибраһимовны озакламый төрмәнең 1 нче номерлы палатасына күчерәләр. Язучының ишеген бикләп тормыйлар. Бу вакытта ул каты авыру инде, караватында гына ята. Истәлек авторы күренекле әдип янына берничә мәртәбә кереп кыска-кыска гына сөйләшеп алу бәхетенә ирешә. Күрешә алмаган көннәрдә язучының хәлен коридорда кизү торучы санитаркадан сорый. Авыруларга хәл кадәри ярдәм итүче, йомшак сүзле, ягымлы мөнәсәбәтле, 25-26 яшьләрдәге татар кызы була ул. Кызганыч, Хәйбик ага аның исемен дә, фамилиясен дә хәтерләми. Инде хатирәләрнең үзенә күз салыйк:«Беркөнне, гыйнварның икенче яртысында, иптәшләрем белән коридор буйлап узганда, мин аның камерасына тагын яшеренеп кереп калдым. Ләкин бу юлы Г.Ибраһимов урынында юк иде. Идәнне яңа гына юып чыгарганнар, караватын урыныннан кузгатканнар. Тумбочка


Акт № 3
от 21/I-1938 г. Мы нижеподписавшиеся
ОМЗ Маврин, лекпом Байкеев и старший надзиратель Петров, составили настоящий акт
в том, что з/к Ибрагимов Галимзян
50 лет, прибывший из Казанской тюрьмы № 1 21/X 37
– умер 21/I 38 г. от туберкулеза легких и туберкулезного плеврита

Язучының үлемен раслаган акт. 1956 елгы күчермә


Справка
След. з/к Ибрагимов Галимзян, умерший в б-це 21.I.38, схоронен в общем порядке
б-цы 27.I.38. Сообщено о смерти
Н-ку тюрьмы № 1 т. Нугуманову 24.I.38 г.
Начальник Центральной Б-цы ОМЗ НКВД
29.I.38.

Әдипнең күмелүе турында белешмә. 29 гыйнвар, 1938 ел

әрҗәсен чыгарып, ни өчендер аны тумбочка өстенә каплап куйганнар. Аңа кемдер зур-зур гарәп хәрефләре белән нәрсәдер язган. Язучы кешенең куллары калтыранган булса кирәк, диагональ юллар шактый тигезсез. Мин, кызыксынып, язуга күз төшердем. «Утыз еллар әдәбият юлында эшләгән эшләремнең соңгы көннәре болай тәмамланыр дип уйламаган идем. Нишлисең! Тарих үзе тикшерер, дөрес бәһасен бирер», – дип язылган иде анда. <...>

Камерадан бик борчылып, шомлы уйлар белән чыктым: «Галимҗан ага нигә урынында юк?»

Шул ук көнне, җаен туры китереп, әлеге санитаркадан сакланып кына сорадым:

– 1 нче палатадагы авыру кайда?

– Ул бүген иртә белән үлгән, – диде кыз. – Без кергәндә идәндә ята иде. <...>

Иртәгесен санитарканы тагын күрдем:

– Ул кешенең кем икәнен беләидеңме? – дидем.

– Белә идем, – диде кыз. – Әсәрләрен дә укыганым бар иде.

Аның күзләре дә миңа кайгылы тоелды.

– Алайса, сеңлем, син ул фанер тактаны сакларга тырыш. Төрмәдән алып чык. Аның кайчан да булса кирәге булыр.

Кыз җавап бирмәде. Ул аны төрмәдән алып чыктымы, юкмы? Тарих өчен саклангнмы, ул авыр көннәрдә моның әһәмиятен белгәнме? Бу турыда бернәрсә дә әйтә алмыйм».

Галимҗан Ибраһимов, алда әйтелгәнчә, 1938 елның 21 гыйнварында бакыйлыкка күчә. Аның җәсәден җиде көн (27 гыйнваргача) җирләмичә тоталар. Мондый мәсхәрәнең сәбәбе нидә соң? Хастаханә җитәкчесе бик җиңел аңлата (документы сакланган): чөнки... 22 һәм 23 гыйнварлар ял көненә туры килгән икән.

Рузәл Мөхәммәтша әзерләде. ■

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.699.

2. Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр/ төзүчесе Р.Акъегет. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 544 б.

3. Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых/ автор-составитель М.Х.Ибрагимов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – 336 с.



Ялтаның җылы хатирәсе

Рауль Мирхәйдәров

Яза башлаганчы, ягъни утыз яшемәчә, Иҗат йортлары турында ишеткәнем дә булмады минем. Әмма Ялта, Сочи кебек курортларны илдә һәркем белә иде. Бу җирләрнең тарихы миңа, бер яктан, мәгърур Алтын Урданың кыйпылчыгы, бабаларымның Кырымдагы дәүләте буларак якын булса, икенчедән, мин яшәгән Үзбәкстанда Сталин сөргән кырымтатарлар күп иде һәм алар еш кына, мавыктыргыч та, кызыктыргыч та итеп туган яклары – Кырым, Ялта, Күктүбә, Массандра йөземнәре, Карлыгач оясы, Воронцов һәм Ливадия сарайлары, диңгез буе, Бакчасарайдагы хансарай һәм Пушкин мәңгеләштергән фонтан турында сөйләде. Хәзер үк юлга җыенып чыгып китәсе, бу хозурлыкны үз күзләрең белән күрәсе килә иде!

Мәгълүм ки, әлеге шәһәр-портның тарихы бик ерак гасырларга барып тоташа. Риваятьләргә ышансаң, аны I гасырда греклар ача, аннары, дәүләтләре чәчәк аткан чорда, бирегә Венеция, Генуя халыклары килеп урнаша, бервакыт хәтта әрмәннәр дә төпләнергә ниятләп карый. Кырым ярымутравы иң күп вакыт госманлылар кулында була. Аңарчы Кырым ханлыгы мөстәкыйль татар дәүләте сыйфатында яши.

Без яшь чакта ук: «Сугышка кадәр Ялтада, Кырымда татарлар бик күп яшәгән», – дип сөйлиләр иде. Карт язучылар бәян кылганча, элек биредә духаннар, чәйханәләр, базарлар гөрләп торган, шашлык кыздырганнар, шәраб агызганнар, чибәрәк пешергәннәр (чибәрәк – кырым татарларының иң

Каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 75 ел тулу кичәсе. Сулдан уңга: шагыйрь Зәки Нури, шагыйрь Мөхәммәт Садри, прозаик Гариф Ахунов, КПСС өлкә комитеты сәркатибе Мирзаһит Вәлиев, калмык шагыйре Давыт Көгелтдинов. 14 февраль, 1981 ел

танылган ризыгы). Ялта, аның шәһәр читендәге беркатлы йортлары шау чәчәк арасында утырган, базар киштәләре сый-нигъмәтләрдән (яшелчә, җиләк-җимеш, шәраб, сыр, сөт ризыклары һ.б.) сыгылып торган. Ялта – узган гасырның беренче чирегендә байлык, муллык сүзенә тиң саналган, бәяләр бик арзан булган, шуңа күрә язучылар бу Иҗат йортын бик нык яраткан.

Сталин каләм әһелләре өчен Ялтаның үзәктәге, тау өстендәге иң матур урынын – вакытында сәнәгатьче һәм меценат Антон Максимович Эрлингер утарына кергән җирләрне бүлеп биргән.

Моннан яр буена ун минут эчендә төшеп җитәргә мөмкин, дөрес, кире менгәндә күбрәк вакыт сарыф ителә. Шәхси бакчалар арасыннан бормаланып аккан сукмак буйлап атлаганда кипарислар, чинар агачы, хуш исле талгөл, зелпе, артыш куаклары хәерле сәфәр теләп кала.

Утарның элекке хуҗасын телгә алмасаң ярамас. Ни дисәң дә, без, язучы халкы, әзергә-бәзер килеп утырдык: гаҗәп матур ике йортка, бакчага, паркка 1934 елда (Язучылар берлеге төзелгән вакыт) нибары утыз алты яшь кенә була әле! Бакчаларның, паркның иң җитешкән, иң гүзәл чагын хәтта хуҗа үзе дә күреп калырга өлгерми, 1910 елда бакыйлыкка күчә. Кем белә, инкыйлабка кадәр үлүе белән, бәлки, бик бәхетледер дә әле ул – күпме көч түгеп тудырылган байлыгының бер мизгелдә чит кулларга күчеп, таланып-таратылып бетәсен белми китә.

Бирегә тәүге кат 1975 елның көзендә аяк бастым мин һәм әүвәлге күрүемдә үк Язучылар йортына да, Ялтаның үзенә дә мәңгегә гашыйк булдым. Төзүче буларак, биналарның шулкадәрле матур һәм табигый рәвештә тирә-юнь мохит куенына кереп утыруы да әсир итте мине. Эрлингерлар милке язучылар кулына тапшырылганчы биредә капиталь ремонт ясалган, бүлмәләр үзгә төрле итеп бүленгән – каләм әһелләренә элеккеге йорттан холлга һәм коридорга нур сипкән люстралар, авыр бронза тоткалы нык имән ишекләр һәм керү

юлында каршы алган таш арысланнар гына кала. Мөгаен, эчке байлыкны – мебель, көзгеләр, картиналар, келәмнәр, рояльләрне – дәүләт дачаларына, совет чынбарлыгы оеша башлаганда ук котырып үрчегән «яңа хуҗалар» «кесәсенә» күчергән булганнардыр.

Тау сыртына салынган йортның алгы ягын, мәһабәт холлын һәм киң баскычларын Италия архитекторлары уйлап тапканча кагылгысыз калдырганнар. Холлда да, кайбер бүлмәләрдә дә иске Венеция пыяласыннан ясалган тәрәзәләр дә сакланган иде әле. Аның каруы, эчке мәйданны хәл кадәри гади һәм уңайлы итәргә тырышканнар – коридор буйлап кызыл келәм җәелгән, аның ике як-ягына бүлмәләр тезелгән. Бүлмәләре зур, иркен, әмма юынгычтан кала һичнинди шартлар тудырылмаган: бәдрәф белән душ – коридорның икенче башында. Өстәге каттагы бүлмәләрнең иркен верандалары да бар иде, анда чыгып бассаң, диңгез, яр буе, кипарис бакчасы, чатырлар – уч төбеңдә кебек күренә, бу чатырларны шагыйрьләр аеруча якын итте – анда рәхәтләнеп иҗат итә иде алар. Парк үзенең кипарис аллеялары, мәңге яшел савыр-чинарлары, исемен беркем дә белмәгән башка бик күптөрле кыргый агач-куаклары белән дан тотты. Төп корпусның торак канатын сусыл яфраклы куаклар урап алган иде – лавр агачы белән иң беренче кабат шулай таныштым, һәрнәрсәнең кадерен белгән каләм әһелләре аны кыш өчен җәй кызуында ук җыеп кайталар иде.

Язучыларны шулкадәр ихтирам иткән, аларга кеше ышанмас күләмдә гонорарлар түләгән И.В.Сталин, шулай да, ни өчен Ялтадагы иң яхшы урыннарны актёр һәм киночыларга биргән соң? Әһле каләм бу сорауга җавап эзли-эзли гаҗизләнеп бетте. Дөрес булса, илбашы: «Монда тыныч, күп санлы бакчалар һәм парклар аларны яр буеннан килгән тавышлардан саклар, иҗат итәргә берни дә комачауламас», – дигән ди. Һай шушы сүзләре өчен язучы халкы үпкәле иде аңа! Актерлар йорты чын-чынлап оҗмах бакчасында урнашкан бит, бинагары да элеккеге Романовлар утары, өстәвенә, пляжлары да бар. Ә без, «бичаралар», кызу көндә су коеныр, кызынып алыр өчен төчкергән саен ватыла торган автобуска дыңгычланып, «синематографчылар» комлыгына кадәр йөреп «иза чигәргә» мәҗбүр идек. Язучылар тынычлык урынына бик теләп шау-шулы диңгез ярын сайламасмы икән, дигән уй И.В.Сталинның башына да килеп карамаган, ахры.

Янкормалар аркасында шактый таралйган, ә СССР таркалганнан соң гел кадерсезгә әверелгән паркта бер бик үзенчәлекле, зур, кеше буендагы йомры таш бар. Ялтаны Владимир Луговской дигән күренекле шагыйрь дә үз күргән, яраткан. Сугышка кадәр дә, сугыштан соң да бирегә килеп иҗат итә торган булган ул, алай гына да түгел, үзе исән чагында ук шундый (бер карашка сәер) васыять әйтеп калдырган: үлгәннән соң йөрәгем парк уртасындагы зур йомры таш эченә урнаштырылырга тиеш, дигән. Туганнары, дуслары, Язучылар берлеге әлеге васыятьне үтәгән: 1957 елда вафат булган шагыйрьнең йөрәге махсус савытка салынып Иҗат йорты паркындагы ташка урнаштырылган, өсте түгәрәк бронза барельеф (диаметры – 12 сантиметр) белән капланган, анда әдипнең исеме, фамилиясе, туган һәм җан тәслим кылган еллары язылган. Нинди шәп һәйкәл бит, ә! Әле совет заманында ук аны куптарып алырга маташучылар да табыла үзе... Бәхеткә, ниятләрен тормышка ашыра алмыйлар, куәтләре җитми – бераз кырыен гына китәләр.

...Мине, күп язучылардан аермалы буларак, үз комлыгыбыз булмау һич борчымады. Киресенчә, танылган кино һәм театр актерлары белән бергә кояш астында кызынып ятуны бәхет санадым. Бирегә мин Сергей Шәкүров белән таныштым, яшь булына карамас-

тан, шактый дәрәҗәле чагы иде инде аның. Леонид Филатов белән урыннарыбыз ике көн рәттән янәшә туры килде. Никадәр генә гаҗәп тоелмасын, татар халкының танылган җырчысы Илһам Шакиров белән дә тәүге кабат шушы комлыкта очраштым. Ул мине Иҗат йортында яшәп тә диңгез ярына йөрергә яратмаган Әмирхан Еники янына алып керде, Ялтада «Ницца» кабаре-варьетесы барлыгын әйтте, анда кордебалетта таныш кызлары бии иде аның (минем «Ранняя печаль» исемле романымда әлеге «Ницца» турында әйтелеп кителә). Әлбәттә, бик аралашучан, сөйләшергә яратучан кеше буларак, тагын да күбрәк шәхесләр белән танышырга, әңгәмәләшергә мөмкинлегем бар иде. Әмма... Ялтада да, башка Иҗат йортларында да мин фәкать... бертуктаусыз эшләдем, эшләдем! Пляжга сирәк йөрдем. Әдәбиятка шактый соң килгәнлектән, миңа, ким дигәндә, яшьтәшләремне куып җитәргә кирәк иде, ә алар бишәр-алтышар китап чыгарырга өлгергән иде инде. Дус-ишләр белән диңгез ярына төшсәк, бер-ике сәгатьтән китү ягын карый идем инде, иң әүвәл, нигездә, җәяүләп, базарга барам, аның янындагы тирән таш подвалда Ялтадагы иң борынгы духаннарның берсе урнашкан иде. Хуҗа кеше – күн жилетлы, башына кызыл төрек фәсе кигән, авызына төребкә капкан (нәкъ кинодагы пират яисә юлбасар инде менә!) карт грек һәрвакыт ачык йөз белән каршы ала. Ул салып биргән берике савыт шәрабны каплап куям да... Иҗат йортына кайтып эшлим.

...Берсендә Ялтада миңа бер үк кешеләр өчен ике атна эчендә ике тапкыр табын җәяргә туры килде. Бу турыда язмый калу ярамый. Киләчәктә иң танылган бәяным булачак «Игълан буенча танышу» дигән әсәремне яза башлаган чагым. Сюжет нигезенә туганым белән чын-чынлап булган вакыйга кереп ятты, шуңа күрә миңа әллә ниләр уйлап чыгарырга туры килмәде, каһарманнар күз алдымда басып торганлыктан, әсәр үзеннән-үзе язылды. Валлаһи, дип әйтәм: нотариусның прототибы булган туганыма караганда, әдәби каһарманым якынрак миңа, әмма тормышта җиңел юллар гына эзләгән туганым һәм ул күргән чып-чын хәл булмаса, кызыклы, үткен, мавыктыргыч әсәр дә иҗат ителмәс иде. Күп кенә укучылар шушы бәяннан чыгып, минем сурәтемне дә төзеп карады, алар фикеренчә, мин дә, һичшиксез, җор телле, шаян, көлеп-уйнап кына йөрүче бер кемсә булырга тиеш идем. Әмма әсәрдә китерелгән игъланда шундый юллар бар: «Гаилә бәхете эзләгән әфәнде, хатын-кызлар артык югары таләпләр куеп, соңрак үкенмәсен өчен, алдан ук кисәтеп куя: бии дә белмим, сөйләшергә дә маһир түгелмен». Мөгаен, бу юллар үземә дә туры киләдер.

Совет заманында язучыларны еш кына һәртөрле очрашуларга йөртәләр иде. Шагыйрьләргә, юмор-сатирачыларга халык алдында чыгыш ясау җиңел, халык әдәбиятчыларны, тәнкыйтьчеләрне, прозаикларны тыңларга бик яратмый, шәхесе кызык булса гына сорауларын яудырырга мөмкин; юк икән, һәммәсенең берьюлы йокыга китәсен көт тә тор. Ташкент язучыларын бик еш Сәмәрканд, Бохара, Фирганәгә очрашуга чакыралар иде, хезмәтенә күрә хөрмәте (матди дә, рухи да) булганга күрә, әдипләр андый очрашулардан читтә калмаска тырышты. Мин дә шул исәптән.

Укучы алдына ни сөйләргә? Бу сорау шактый озак гомер йөдәтте. «Игълан буенча танышу» язылу белән, очрашуымның шәкеле дә туды, аны төзегәндә театр, режиссура белән таныш булуым ярап куйды: бәянның иң уңышлы биш-алты урынын сайлап алып, аларын укыйм, калган өлешенең эчтәлеген генә сөйләп чыгам – һәммәсе дә утыз-кырык минутка җыела, әмма, кирәк булганда, бер сәгатькә дә сузар-

га мөмкин иде. Укый башлыйм гына – Жванецкий яисә Задорнов концертымыни! – халык егылып көләргә тотына. Чыгыш ясарга тиешле чираттагы кешеләргә шактый кыенга туры килә иде, шуңа күрә, озакламый, минем белән бергә очрашуга йөрергә теләүчеләр саны бермә-бер кимеде.

Инде әлеге бәяным язылган чакка, Ялтага кайтыйк – анда безне кызыклы вакыйгалар һәм алардан да кызыклырак шәхесләр көтә. Ул җәйдә Ялтага бик күп татар-башкорт язучысы килде, араларында күренекле Зәки Нури да бар иде. Кыяфәте гаярь: үзе бик еш искә алырга яраткан Муса Җәлил әйтмешли, киң күкрәкле, тимер бәдәнле... Шул ук вакытта алманнарга тартым чалымнары да бар иде аның: сипкелле, җирәнрәк чәчле, өстәвенә, алман телен дә ярыйсы гына сукалый.

Ул астма чиреннән газап чикте. Әмма шушы күңелсезлеген дә шаяруга бора белә иде, берсендә миңа: «Интектерепләр бетерә шушы Әсмабикә, суларга ирек бирми», – ди бу. Аңламый торам. Астмасын да Әсмабикә дип яратып әйтүе икән лә! Зәки Нури – танылган җәмәгать эшлеклесе иде, озак вакыт Татарстан Язучылар берлеген, «Казан утлары» журналын җитәкләде, Татарстан Югары Советы депутаты булды.

Кичке ашка кадәр дә, кичке аштан соң да татар-башкорт язучылары уратып ала иде аны, шундый вакытларның берсендә мин кыенсынып кына якынлаштым да: «Мөхтәрәм Зәки әфәнде, мин сезне һәм сезнең дусларыгызны иртәгә кунакка чакырырга телим. Ачуланмасагыз, яңа бәянымны да укып китәрмен», – дидем. (Иҗат йортында яңа гына табадан төшкән әсәреңне бер-береңә уку гадәте бар иде.) Дөнья колакларын тырпайтты. Бер мизгелгә сузылган тынлыкны шагыйрь тиз арада, кинәт уянып киткәндәй, өзеп ташлады, утыз ике тешен күрсәтеп елмайды да: «Син, саранланып кына авыз чылата торган үзбәкләр янында йөргән кеше, татар-башкорт әдипләренең тамакка нык икәнен белмисеңдер әле... Азык-төлек мул булса, һичшиксез, килербез», – диде. Ул соңгы сүзләрен әйткәндә якын-тирәдәге әдипләр елмаеша-көлешә башлаган иде инде.

Бүлмәмнең киң верандасына унбишләп кеше сыя, көне җиткәч, шәрабханәдә эшләүче егетләр-кызлар ярдәменнән ташламады – өстәле дә, урындыклары да, эскәтере дә, савыт-сабасы да табылды, калган кирәк-яракны базардан сатып алдым. Кунаклар җыелышып беткәч, Зәки Нури, күзләре балкыган килеш, үзен барыбер җитди тотарга тырышып: «Чын татарча булган бу. Яхшы! Эчемлек җитәргә тиеш», – диде дә, түргә, коньяк янына узды (астмасы аркасында мин аның коньяк кына эчкәнен белә идем). Кунаклар утырышты, яшьрәкләре чәркәләрне тутырышты. Бер эчеп куйдык, ашадык, тагын бер эчеп куйдык. Табын ямьләнеп, җанланып китте. Шулвакыт Зәки Нури янә сүз алды: «Дуслар, онытмыйк әле – без бирегә сыйланыр өчен килмәдек, яшь каләмдәшебезнең яңа иҗат җимешен тыңлар өчен килдек. Тагын бер чәркә капласак, йомшарырбыз да, әсәр кайгысы калмас бит».

Укырга керештем. Бәян озын иде. Кешеләрне нигъмәт тулы табын алдында озак азаплап тотарга ярамый иде. Радиода күптапкыр чыгышлар ясаганга күрә ык-мык килеп тормадым тагы. Әсәремнең язылган кадәрен укып бетергәннән соң бүлмә алкышларга, котлауларга күмелде, табын кабат җанланды, халык аракы-шәрабка үрелде, савытларны тутыра башлады... Әмма түр яктан килгән тавыш шау-шуны тиз бүлде: «Туктагыз әле, туктагыз! Мактауларыгызны баса төшегез. Бу ахырынача язылмаган бит. Без әдәбиятка килеп кенә кергән чакта Кави Нәҗми: «Әсәрне башлау җиңел ул, тәмамлау авыр», – ди торган иде. Яшь кеше... – Аның тавышы тагын усалланды. – Сез ни оятыгыз

«Ватан сугышы партизанына» медале таныклыгы. 1947 ел

белән безгә, аксакалларга, соңгы ноктасы куелмаган әсәр укырга җөрьәт иттегез? Мондый хәлнең татар әдәбиятында булганы юк иде әле! Шуңа күрә, ачуыбыз басылсын, гафу итик, дисәгез, калган ике атна эчендә бәянныгызны язып бетерергә һәм тагын бер табын җәеп, янә безне чакырырга киңәш итәм. Ялта белән дә шулай саубуллашырбыз! Хак әйтәмме, әфәнделәр?»

Ул көнне без татарча гына сөйләштек. Зәки Нуриның бу тәкъдимен, әлбәттә, һәрберебез хуплады – бигрәк рәхәт, матур утыра идек шул, мөгаен, бу кичәне озаграк сузарга, мөмкин булса, кабатларга теләүчеләр байтак булгандыр. Янәшәмдә утырган Нәби Дәүли шул вакыт колагыма иелде: «Зәкине мондый күңелле халәттә күптән күргән юк иде инде, бу кичәне оештырып, бик яхшы эшләгәнсең, шәп утырабыз».

Зәки Нуриның сүзләре шаяру булуга карамастан, мин аларны җитди кабул иттем – әйткәне хак иде чөнки, аннары, милләттәшләрең тагын бер җыелып кунакка киләм, дип торганда, кем баш тартсын инде?

Комлыкка йөрүдән гомумән туктадым мин, диңгез ярын ураулар да кими төште, хәтта Эдуард Топольнең «Би-би-си» радиосы тапшырган «Журналист для Брежнева» исемле яңа романын да тыңламый башладым, яздым, яздым һәм... мәҗлес башланырга ике сәгать кала, ниһаять, бәянымны тәмамладым. Аңарчы яңа танышларымның һәр көн саен: «Эшләр ничек бара?» – дип кызыксынуларын онытырлыкмыни! Бу вакыт аралыгында бик күпләрнең илһам һәм уңышлар теләвен сизеп-тоеп тордым. Бәянны яхшы кабул иттеләр, кичә җырмоң белән үрелеп барды. Без төн уртасы җитмичә аерылыша алмадык.

Әсәрнең язмышы бик бәхетле булды. Ул Совет илендә басыла килгән бихисап газета-журналларда, китапларда, томлыкларымда урын алды. Мине иң куандырганы: 1998 елда, ниһаять, татарчага тәрҗемә ителеп, «Казан утлары»нда дөнья күрде. Соңрак әлеге әсәр буенча Ркаил Зәйдулла пьеса язды. Спектакле бүген дә әти-әниемнең туган яклары булган Оренбургта, Минзәләдә күрсәтелә, дип беләм.

РЕДАКЦИЯДӘН: Күренекле әдип, журналыбызның авторы, җәмәгать эшлеклесе **Рауль Мирсәет улы МИРХӘЙДӘРОВ**ка 17 ноябрьдә – **75 яшь**! Аны шушы күркәм гомер бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез! ■

Татар моңын дөньяга таратучы

Фәйрүзә Мөслимова

«ҖЫРЧЫГЫЗ КАЙДА БҮГЕН?»

Резидәнең әти-әниләре бакчаларына үзләре генә, балаларын алмый килгән көн була ул. Шунда күршеләре: «Җырчыгыз кайда соң?» – дип сорыйлар. Әни кеше Әлфия гаҗәпләнә кала – нинди җырчы турында сорыйлар икән, дип, хәтта як-ягына да карангалап ала. Баксаң, кече кызлары Резидәне шулай җырчы дип атаулары, имеш. Чыннан да, кайчан карама, гел нинди дә булса җыр көйләп йөрергә ярата шул төпчекләре. Телевизордан еш ишетелгән Пахмутова – Добронравов җырлары булсынмы, радиодан яңгыраган матур татар көйләреме – бәләкәч һәркайсын тиз генә отып ала да, җырлый да җырлый. Әле күптән түгел, карлыган җыярга кушкач та, куак төбендә әкрен генә җырлап утырган иде. Үзләре игътибар итмәсә дә, күршеләре ишеткән, димәк. Әти-әнине шушы сорау уятып җибәргәндәй итә: ә бәлки кызларын музыка мәктәбенә укырга бирергәдер?

Шул рәвешчә, Резидәнең киләчәк язмышы хәл ителә дә куя. Гадәти мәктәпкә беренче класска укырга кергәндә, ул бер үк вакытта Түбән Кама шәһәренең 2нче музыка мәктәбенә дә йөри башлый.

– «Бардым да кердем» түгел әле, анда сынамыйча алмыйлар, – дип искә ала ул чакларны Резидә. – Җырлатып карадылар, интонацияләрне ничек отуымны тикшерделәр. Дмитрий Кабалевскийның «Наш край» дигән җырын җырлаган идем. Гомумән, балачактан ук туган ил, туган җир турындагы җырларны бик яратам мин. Ничек аңлатыйм... күңел түремдә гомер-гомергә сызылып кына нечкә бер патриотлык хисе яши.

Музыка мәктәбендә укыгач, уен коралы – бу очракта фортепьяно алу зарурлыгы туа. Мәктәп өйләреннән ерак булмаса да, дәрес әзерләү өчен гел анда йөгерү кыен. Музыка инструментлары кибетенә килгәч, әнисе Резидәдән: «Укыячаксыңмы? Уйнаячаксыңмы?» – дип сорый. Теләгенең ихлас икәнлегенә ышангач кына, фортепьяно сатып алыр-

га булалар. Кредитка. Бер ел түләп бару шарты белән.

***

Резидә гаиләдә өченче бала булып Чистай шәһәрендә туган. Нәкъ шул чакта ерак та түгел Түбән Кама дигән яшь шәһәрне, бөтен илгә мәгълүм нефть-химия комбинатын төзү башлана. Сөләймановлар гаиләсе дә, яшәгән урыннарыннан кубып, шунда күченеп китә. Әниләре химия комбинатына эшкә урнаша. Гаилә башлыгы Локман автомеханик булып эшли, аның кебек тәҗрибәле белгечләрнең сирәк һәм бик тә кирәк чагы. Хәзер генә бит ул машиналар да, аны йөртүчеләр саны да исәпсез. Резидәнең апасы Ландыш, мәсәлән, 10 нче класста ук, укып, автомобиль йөртү таныклыгына ия була. Абыйсы Илһам мәктәптә фотосөючеләр түгәрәгендә шөгыльләнә. Берсендә, әйләнә-тирәне фотога төшерергә дип урамга чыккач, түгәрәк җитәкчесе: «Әнә тегеннән машина килгәнне күрәсезме? Кем шуны, каршыбыздан үткәндә, кадр уртасына туры килерлек итеп төшереп алыр икән?» – дип кызыктыра. Кирәк бит, иң остасы Илһам булып чыга шунда. Фотосын газетада да бастырып чыгаралар әле. Резидә бу хәлне, беренчедән, абыйсының осталыгы белән горурланып искә төшерсә, икенчедән, машиналарның ул чакта нинди сирәк күренеш булуын уйлап көлемсери.

ОСТАЗЛАРЫҢНАН УҢСАҢ...

Резидә, ике мәктәпне дә тәмамлагач, шәһәрдәге С.Сәйдәшев исемендәге музыка училищесына юл тота. Ул инде үзен музыкадан башка күз алдына да китерә алмый. Махсус фортепьяно классын тәмамлаган кыз күптән түгел ачылган 3 нче музыка мәктәбендә үзе дә балалар укыта башлый. Тик аның җырга да сәләтле икәнен күреп калган укытучысы Вадим Петрович Шургалин Резидәнең шул эше белән генә

Татарстанның Беренче Президенты М.Шәймиев Р.Галимовага Рәхмәт хаты тапшырган мизгел. 2013 ел

канәгатьләнеп калуын теләми: «Әйдә, вокал курсында укуыңны дәвам ит», – ди. Юлыңда шундый хәерхаһлы остазлар очрап тору үзе үк зур уңыш түгелмени? Монысын тәмамлагач та ул аңа: «Тукталып калма! Югары белем алырга Казанга яки Мәскәүгә барырга кирәк сиңа», – дип киңәш бирә. «Казанга? Минем бит анда бер танышым да юк!» – ди Резидә, башына беренче килгән фикерен әйтеп. «Ә Мәскәүдә бармы?» «Анда да... юк». Бергәләп уйлашкач, ахыр чиктә Мәскәүне сайларга булалар. Өстәвенә, остазының бер укучысы – Владимир Конин да шунда укыган: Гнесиннар исемендәге югары музыка мәктәбендә – Россия музыка академиясендә. (Сүз уңаеннан, Түбән Каманың танылган җырчысы ул, шунда музыка училищесында укыта.)

Академиягә документларын тапшыргач, ил буенча җырларга теләүчеләрнең никадәр күп булуын күреп шакката Резидә. Арадан иң өметлеләрен күреп алу да җиңел түгелдер шул: юкка гына сайлап алу конкурсын 3 турдан оештырмаганнардыр. Имтиханнар да бик җитди. Дулкынланасың, борчыласың. Һәр баскыч саен, иләктән иләнгән сыман, кемнәрдер коела, коела... Ниһаять, соңгы турны да үтеп, сайланганнар исемлегендә кала ул.

Ул укырга кергән ялгыз (соло) академик җыр факультетына күренекле җырчы-педагог Валентина Левко җитәкчелек итә. Маргарита Миглау, Зара Долуханова, Наталья Шпилер да биредә укыталар. (Совет опера җырчысы Наталья Шпилерны Сталин тыңларга яраткан, дип сөйлиләр.) Танышлары булмаудан да юкка курыккан икән Резидә, укый башлагач, танышлары да, дуслары да табыла...

БАРЫ ТИК ФИЛАРМОНИЯ!

Лирик сопрано тавышлы, дәрәҗәле вузны яхшы билгеләренә генә тәмамлаган Резидә эш урынын сайлаганда шикләнеп тә тормый: әлбәттә, Ка-

занга кайтырга, әлбәттә, Габдулла Тукай исемен йөрткән данлыклы Татар дәүләт филармониясенә барырга! Гомеренең бу баскычы да үзенчәлекле имтиханнан башлана – оешма җитәкчелегенең таләпләренә туры киләсеңме син, сайлаган җырларың, башкару осталыгың дәрәҗәле худсовет аша уза аламы? Ничек инде узмасын? Төрле опералардан арияләрне, романсларны, рус, чит ил һәм татар композиторларының әсәрләрен (барысы 7-8ләп) Резидә һич кимчелексез башкарып чыга. Филармониянең Халык уен кораллары оркестры җитәкчесе Анатолий Шутиков аны үз коллективына эшкә чакыра. Шул көннән бирле Резидә «төшкән җирендә таш булып», җырлары белән үз халкына хезмәт итә. Әйе, аларның концерт оешмасының максаты, гомумән, халыкны музыкаль яктан агарту, төрле стиль, төрле чорларның музыкасын камил төстә тамашачыларга җиткерү, авторлар һәм тамашачылар арасын ефәк җепләр белән бәйләп торудан гыйбарәт бит. Оркестр барлык сәхнәләрдә чыгыш ясый, Татарстан Республикасының мәдәният көннәре оештырылганда төрле илләргә гастрольләргә чыга. Аларның сәяхәт картасында Болгария, Германия, Португалия, Көньяк Корея кебек илләр теркәлгән. Резидә үзен җиде дистәгә якын кешелек тату, дус коллективыннан аерып карый алмый. Шулай да үзе Гали Ильясовның «Идел вальсы», «Синең өчен», Резеда Ахиярованың «Сөембикә», Александр Алябьевның «Соловей» җырларын

А.Шутиков җитәкчелегендәге оркестрга кушылып җырлаган вакыт

башкарганда, тамашачы белән ике арада аеруча тирән бәйләнеш, аңлашу урнашуын тоеп тора. Көньяк Кореяда, әйтик, концерт тәмамланганда, тамашачылар аягүрә басып шулкадәр алкышлыйлар аларны! Җырчыга, музыкантларга моннан да зуррак бәя була алырмы?!

Хәер, Резидә иҗат гомерендә рәсми рәвештә дә югары бәяләргә лаек булды. Ул күп санлы музыкаль конкурслар, фестивальләр луреаты. 2001 елда аңа – Татарстан Республикасының атказанган, 2011 елда Татарстанның халык артисткасы исемен бирделәр. Гомерең, эшең заяга үтми дигән сүз бит бу.

ХӘЗЕР ҮЗЕ БӘЯ БИРӘ

Кайчандыр төрледән-төрле конкурслар, сыналулар аша узган Резидә хәзер үзе дә төрле жюрилар составында утыра. Әйтик, Түбән Камада Салих Сәйдәшев исемендәге халыкара вокалистлар конкурсы, Казанда телевидениенең «Татар моңы» халыкара яшь башкаручылар конкурсы жюриларының әгъзасы булды. (Җырчылар Марат Фәйрушин, Гөлсирин Абдуллина, баянчы Булат Хисмәтов кебекләр иҗатка юлын шундый конкурслардан башлады.) Хәзер дә әле ТРның эшләүче яшьләр иҗаты буенча республика телевизион фестивале жюрие рәисе вазифасын башкара. Бу бит – карап, бәя бирел утыру гына түгел. Үзешчән артистларның кеше көлдерү өчен кылган мәгънәсез гамәл-хәрәкәтләрен вакытында тотып алырга, аларга әдәп-әхлак тәртипләрен өйрәтергә кирәк чаклар да булгалый.

Нәкъ үзе әйткәнчә, Резидәнең күңелендә нечкә патриотлык хисе, үз халкын тирән ярату хисе бар. Ул аны югары культуралы, белемле, тәрбияле итеп күрергә тели. Кызы Сөембикәне дә ире Нияз белән кечкенәдән шул ук рухта тәрбияләгәннәр. Өч яшенә кадәр бары тик татарча гына сөйләшеп үскән бала, әнисе кебек үк, гомуми белем бирү мәктәбе белән беррәттән, фортепьяно классы буенча музыка мәктәбен дә тәмамлый. Соңыннан университетның халыкара мөнәсәбәтләр факультетына укырга керә. Җәйләрен чит илләрдә стажировкада булганда, үзәк шәһәр мәйданнарында урнаштырылган (чит илләрдә андый тәртип бар) фортепьяноларда уйнаганын сөйли.

Кайберәүләр аннан кызларын ник Сөембикә дип исемләүләре турында сораша. «Яңа туган балама карауга ук, аның бары тик Сөембикә булырга тиешлеген күреп алдым», – ди Резидә.

Резидәгә дә чит илләргә чыгарга туры килгәнен яздык инде. «Тик кая анда ил күрү? Еш кына залның тышында, фойеда ниләр барын да сиземләмисең. Гастрольләр – киеренке хезмәт бит ул», – дип сөйли Резидә. Шулай да Америкада – Сан-Франциско һәм Нью-Йорк Сабантуйларында чыгыш ясавын, Рокия Мансур, Даян һәм Рокия Сафалар гаиләсендә кунак булганын бер дә онытмастыр, мөгаен. Җирнең теге ягында да татарлар яши. Аларның бүгенге буыннары кебек үк, яңалары да милли аңыбызны, телебезне, гореф-гадәтләребезне киләчәккә алып барсыннар иде, ди Резидә. ■

Миллият сүзлеге

Адлер Тимергалин

РУСЛАШТЫРУ СӘЯСӘТЕ – Көнбатыш терминологиясендә – *русификация, русификаторлык*. Россиядә (Мәскәү кенәзлегендә) XV гасырдан ук гайре русларны (әҗнәбиләрне, «вак милләтләрне») көчләп ассимиляцияләү, йоту сәясәте. Баштарак бу реакцион сәясәт рус булмаган халыкларны мәҗбүри чукындыру рәвешендә үткәрелә, аннары һәртөрле икътисади чикләүләргә мәдәни чикләүләр килеп өстәлә. Ана телендә белем алуны кысрыклау, мөселман руханиларының хокукларын киметү, рәсми оешмаларда эш кәгазьләрен фәкать рус телендә генә алып бару кебек ирексезләү чаралары гамәлгә кертелә.

Патша хөкүмәтенең мәҗбүри руслаштыру сәясәте христианлаштыру сәясәте белән бергә үрелеп барган һәм бу эш Н.И.Ильминский системасына нигезләнгән.

Ильминский беренче эш итеп керәшен татарлар, чувашлар, мари һәм удмуртлар өчен рус графикасына нигезләнгән әлифба төзи. Аның керәшеннәр өчен беренче әлифбасы 1862 елда Казанда басылып та чыга. Ильминский фикеренчә, вак халыкларны руслаштыру аларның телләрен шундук русчага үзгәртү аша үткәрелергә тиеш түгел. Иң әүвәле әҗнәби (рустан гайре халыклар) аңлы һәм ихтыяри рәвештә христианлык нигезләрен үзләштерергә тиеш, шуннан соң инде ул рус телен үзе теләп өйрәнәчәк һәм аның руслашуында икенче этап башланачак. Тюрколог В.В.Григорьев болай дип тә язган: «...*әҗнәбиләрне руслаштыруга ярдәм итүче диннән кала икенче чара — аларга рус халкының әхлакый өстенлеген танытудан гыйбарәт...*». Монда әхлакый өстенлекне күпкырлы мәдәни өстенлек дип тә аңларга кирәк. Шулай булганда, рустан гайре милләтләр үзләренең артта булуларына төшенеп, русларны остаз һәм җитәкче сыйфатында ихтирам итәчәк булып чыга. Алар русча уйлап, русча фикер йөртә башлаячак... Күренекле татар әдибе һәм бездә сирәк очрый торган төпле фикер иясе, замандашыбыз Равил Бохараев булып ул да: *«Мин – элекке математик һәм асылым белән әдип, табигый татар кешесе, хәтеремне җиңелчә генә эшкә җигеп, югарыда сөйләнгәннәрнең барчасын да берничә Европа телендә, ул гына да түгел – татар телендә бәян итә алыр идем, ләкин шул ук вакытта мин барыбер, балачагымнан ук гадәтләнгәнчә, русча уй йөрткән булыр идем һәм мондый кеше бер мин генә түгел»*, – дип яза. Боларга әллә ни өстәп әйтәсе килмикилүен, ләкин бүген үзенең ифрат катлаулы фәлсәфи фикер сөрешен татарчага әйләндерергә тырышып карaса,

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.



«Русская Швейцария». 1913 ел

Равил Бохараев бу эшнең һич кенә дә җиңел түгеллеген аңлап, кәефе кырылыр иде, дип ышанып әйтә алабыз.

XIX гасыр ахырында татар халкы арасында таратылган бер кулъязма прокламациядә руслаштыру сәясәтенең ачык мисалы итеп ул заманда Россиягә көчләп кушылган Польшадагы хәлләргә игътибар ителә. Анда: *«Поляклар ялгыз русча укымак хәлгә килделәр. Бүгенге көндә гомум Ләһестанда гыйбадәттән катгы назар илә, гадәте исламиядән дәхи бер шәйләре калмамыш... Инде бакалым-күрәлем, әгәр дә мәдрәсәләремез ысуле җәдидә илә укытылып, битәдриҗ русча укытыла башласа, безләр дә шул мәзкүр поляклар кеби булуымызда һич шик вә шөбһә улмаячакдыр»*, — диелә. Мәгълүм ки, поляклар мондый афәттән мөстәкыйльлек алу юлы белән котылдылар.

Русификаторлык сәясәте нәтиҗәсендә XIX гасырда 200 мең чамасы татар православие диненә дүндерелә. Чуаш, мари һәм мордва халкын христианлаштыруда патша хөкүмәте тагы да зуррак уңышларга ирешә. Мәс., Казан губернасында яшәүче чуашларның 98,8%ы көчләп һәм юмалап чукындырыла, 1,2 %ы гына мәҗүсилектә кала яки мөселманлыкка иман китерә. 133300 мари христиан динен кабул итә, фәкать 3851е генә мәҗүсилеген ташламый. Мордваның исә 100%ы диярлек христиан диненә күчәргә мәҗбүр ителә.

«РУССКАЯ ШВЕЙЦАРИЯ» – Иске Казандагы матур табигатьле бер урын, *Рус Швейцариясе*. Хәзерге «Казан» санаторие һәм Ял паркы урнашкан мәйданга туры килә. Бу атаманы язучы С.Т.Аксаковка нисбәт итәләр. Казан шәһәре территориясендә «Немецкая Швейцария» дә булган. Анысы Арча зираты артында, хәзерге психневрологик диспансерга табарак урнашкан була. Рус-нимес Швейцариясе «Табигать ядкяре» дип игълан ителде.

РЫБНОРЯДСКАЯ УРАМЫ – Иске Казандагы урам исеме. Татарча *Балык базары* (яки *рәте*) *урамы* дип атарга мөмкин булыр иде. Хәзер Пушкин урамы исемен йөртә, 1917 елдан соң бер ара *Кооператив урамы* дип тә аталган. XVIII гасыр урталарына кадәр бу урам Казан шәһәренең көньяк чиге булып исәпләнә, хәзер исә ул шәһәрнең үзәгендә калган.

Электә монда *Олы ермак* булган. ■

ПИБИК

Хисаметдин Исмәгыйлев

Озакламый «БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын алдырып укый башлавыма бер ел тула. Шушы кыска гына вакыт эчендә без аны гаиләбез белән яратып өлгердек һәм көтеп алабыз. Һәрбер санын укыган саен, күзләребез ныграк ачыла бара. Галәм киңлекләренә тиңләрлек икән бит безнең тарих, безнең мирас.

Журналның сигезенче санында якташыбыз Айдар ага Хәлимнең «Сагышта туган сабырлык» дигән мәкаләсе басылган. Аны бик игътибар белән укып чыктым. Бик шәп язылган. Менә шул мәкаләдәге «Турай ат» җырындагы ПИБЕК сүзе турында язып үтәсем килә.

Пибек сүзе бездә дә бар. Бездәге картлар авызыннан бу сүзнең азаккы иҗегендәге е авазы и булып, ягъни ПИБИК дип ишетелә иде. Өршәк елгасы буенда яшәгән башкортларда да әлеге сүз бар. Һәм бу сүз белән уйсу җирдә тереклек иткән чәүкә зурлыгындагы күчмә кошны атыйлар. Башка җирдә яшәгән башкортлар ул кошны БИБЕК диләр. Бу безнең як татарлары әйтелешенә бик тә аваздаш бит. Шул кошны бездә ТӘКӘРЛЕК дип тә йөртәләр. Һәрхәлдә, Өршәк елгасы буеннан әлеге урыннарына күчеп утырган Авыргазы районындагы Бәгәнәш авылында яшәүче башкортларда ике исеме дә йөри иде. (Без бәләкәй чакларда, ягъни 55-65 нче елларда.) Хәзер бу сүзне белгән олы кешеләр дә, ТӘКӘРЛЕК-ПИБИК кошы кебек үк, бармак белән генә санарлык калды. Урысча ул кош ПИГАЛИЦА яки ЧИБИС дип йөртелә.

Аның кычкыруы ПИБИК-ПИБИК-ПИБИК, дип, ничектер бик моңсу ишетелә. Сазлыклы урыннарда, күл-елга буйларында тереклек итә ул. Башында озын гына бер-ике йоны тырпаеп тора, чама белән 5-7 см булыр.

Иң кызыклысы шунда – безнең Гөлем авылында ПИБИК кушаматлы кешеләр яши. Аларга ул кушамат әтиләреннән калган, чөнки Хайбыр бабай мәҗлесләрдә гел шушы ТУРАЙ АТ җырын җырлаган. Шуңардан калган ләкаб-кушамат. Ә АЙДАР аганың туган авылы Кәркәлегә мин туган-үскән Гөлем авылыннан урман аша турыга бер 12-15 чакрым булыр. Менә шуны гына әйтәсе килгән иде.

Башкортстан, Эстәрлебаш

Тел – тормыш көзгесе

Гомәр Бәширов

Нәкъ бүгенгечә, илдәге халыкларны бер халык итеп карау, урыс телен барлык халыклар өчен дә бердәнбер тел итү сәясәте алып барылган 1970 нче еллар башы... Шәһәрләрдә татар мәктәпләре инде тәмам бетеп барган, авылларда урысча укытыла башлаган караңгы бер чор.

Һәм, ни гаҗәп, шушындый вакытта Татарстан радиосында, кара болытларны аралап үткән кояш нуры кебек, башка программалардан бик нык аерылып торган «Тел күрке – сүз» дигән тапшырулар циклы пәйда булды.

Ана телебезнең бүгенге хәле, хәзерге торышы ничек, киләчәк язмышы нинди булыр, элек-электән килгән уку-укыту традицияләрен дәвам иттерәбезме, әдәби тел кагыйдәләрен дөрес кулланабызмы, сүзләребезнең килеп чыгышын, тарихын беләбезме, башка халыклар үз телләре язмышы турында ниләр уйлыйлар? – бу сораулар тапшыруларыбызның төп эчтәлеген, төп мәүзугын тәшкил итте.

Халык арасында тиз арада популярлык казанган әлеге тапшыруны күренекле язучылар һәм тел галимнәре күтәреп алдылар һәм аның актив авторлары булып киттеләр. Шушы җәһәттән атаклы язучыбыз Гомәр ага Бәшировны аеруча хөрмәт белән искә алабыз. Өлкән әдибебез бу эшкә беренчеләрдән булып кушылып китте һәм радиотыңлаучыларда зур кызыксыну уяткан байтак гыйбрәтле чыгышлар ясады. Аларның кайберләре бүгенге көндә Татарстан радиосының фондында саклана. Шул чыгышларның беренчесен сезнең игътибарга да тәкъдим итәргә булдык.

Рөстәм Акъегет

Кеше кайда гына яшәмәсен, нинди генә телдә сөйләшмәсен, аның олы хөрмәт белән әйтә торган ике газиз сүзе бар: туган ил, туган тел. Алар һәрвакыт бер-берсенә авваздаш булып ишетелә. Туган тел, дидеңме, үзеннән-үзе туган ил күз алдына килә. Икесе ике төшенчә булуга карамастан, бу ике сүзнең икесендә дә җанга якын уртак мәгънә бар. Алар телгә алыну белән күңелләрдә якынлык, кардәшлек хисе, туган илеңә һәм халкыңа тирән мәхәббәт тойгысы уяна. Чөнки болар икесе дә иң беренче булып сабый чакта ук колакка кергәннәр. Чөнки алар ана сөте, әниләрнең бишек җырлары белән үк каныбызга сеңеп калганнар. Шунлыктан, кеше туган илен саклар өчен кулына корал алып сугышка китә, чит илдә булса, туган илен сагынып җырлар чыгара, иленә кайтканда туган туфрак җылысын да, туган тел авазларын да бер дәрәҗәдә үк сагынган була.

Билгеле, һәркайсыбыз туган илнең алдынгы, бай, аның һәртөрле афәтләрдән, хәвеф-хәтәрдән, сугышлардан имин булуын телибез. Аңа шул юнәлештә ярдәм итәргә тырышабыз. Туган тел дә бездән шундый ук хәерхаһлык, шундый ук кайгыртучанлык таләп итә. Чөнки тел – җәмгыятьнең, һәр шәхеснең берни белән дә алыштырып булмый торган рухи байлыгы. Ул халыкның акыл хәзинәсен, гореф-гадәтләрен, хәзер дә безгә хезмәт итә торган иң яхшы традицияләрен, дөньяга карашын, фәлсәфәсен, шигъри җәүһәрләрен, бик борынгыдан бирле безнең заманнарга түкми-чәчми алып килгән. Иксез-чиксез бу бай мираска һәр буын үз өлешен керткән. Әлеге гаҗәеп күңел хәзинәсе беркайчан да саекмасын өчен, һәр буын аңа яшәү куәтен өстәгән. Шушы телдә шагыйрь Кол Гали гасырлар буена укылып килгән мәшһүр поэмасын – «Кыйссаи Йосыф»ны бүләк

«Чит телләрне 6 елда өйрәнеп була, әмма үз телеңне гомер буе өйрәнергә кирәк»

итеп калдырган. Шул ук тел безгә бик борынгы заманнарда ук иҗат ителгән дастаннар, җырлар, әкиятләр, табышмаклар, бәетләр шикелле беркайчан да кыйммәтен җуймый торган халык күңеле җәүһәрләрен китереп җиткергән. Бу телдә Мөхәммәдьяр, Утыз-Имәни, Мәүлә Колый кебек шагыйрьләр һәм башка бик күп әдипләр әсәрләр язып калдырганнар. Һәм, ниһаять, инде XX гасырда Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Галимҗан Ибраһимовлар телнең тагын да тирәнрәк яткан поэтик нечкәлекләрен ачтылар, аны тагын да баетып, халыкка якынлашуына, тагын да югарырак баскычка күтәрелүенә ярдәм иттеләр.

Телнең ифрат бай эчке мөмкинлекләре мәйданга чыкты, бихисап яңа сүзләр барлыкка килде. Моңа хәтта тугандаш халыкларның каләм әһелләре дә игътибар иттеләр. Казакъ халкының зур әдибе һәм галиме Мохтар Әуэзов, соңгы елларда татар әдәби теленең һәр җәһәттән үсеп, камилләшеп китүенә соклануын белдерде.

Иң соңгы мәгълүматлар да, төрле уңай белән гыйльми даирәләрдә әйтелгән фикерләр дә татар теленең халыклар арасында абруе өзлексез үсә баруы турында сөйлиләр. Танылган тел галимнәренең раславынча, безнең телебез җир шарында иң таралган, иң популяр 14 телнең берсе булып санала. Бу хәл, ягъни татар теленең халыкара әһәмияте булган зур телләрдән берсе булып танылуы галимнәрдән, әдип һәм шагыйрьләрдән, тел-әдәбият укытучыларыннан телнең сафлыгын саклауга, аны тагын да үстерү, камилләштерү мәсьәләсенә җитдиерәк карауны таләп итә булса кирәк.

«Тел – тормышның көзгесе», – диләр. Телнең байлыгына, тормышның нинди катлаулы ихтыяҗларын үтәүгә сәләтле булуына карап, халыкның культурасы нинди югарылыкта торуын билгеләргә мөмкин. Шулай да монда французның мәшһүр философы Вольтер фикерен искә алу кирәк булыр шикелле. Ул бик хаклы рәвештә: «Чит телләрне 6 елда өйрәнеп була, әмма үз телеңне гомер буе өйрәнергә кирәк», – дигән. Бу сүзләргә бик тирән мәгънә салынган. Ул безнең заманга да туры килеп тора.

Мәгълүм ки, белем алуга, һөнәр өйрәнүгә, яисә тормыш кагыйдәләрен үзләштерүгә халыкның уңай традицияләрен, аның тормыш фәлсәфәсен, гомумән, туган телендә өйрәнелгәнне нигез итеп салсаң, һәрнәрсә онытылмастай булып күңелгә сеңеп кала. Максим Горький әдәби телне, осталар тарафыннан эшләнгән тел, дип атый. Каюм Насыйри: «Шагыйрьләр – сүз патшаларыдыр», – ди. Күренекле шагыйрь һәм әдипләр әдәби телгә генә түгел, халыкның сөйләм теленә дә зур өлеш керттеләр. Һади Такташ та озак еллар телдән төшмәслек шигъри шедеврлар калдырды:

«Салкын карга басып Алсу килә,
Үзе көлә,
Үзе сөйкемле.
Үзе усал.
Үзе болай
Бер дә
Усал кебек түгел шикелле...»

– дип язды.

Хәзерге әдип һәм шагыйрьләрнең дә әсәрләренең телен өзлексез баета баруларын, заманыбызга хас үткен, тапкыр, образлы, бай тел белән язуларын көтәбез.

Халыкчан, җиңел тел белән язылганда, газета-журналлар да ансат укыла. Телнең сафлыгына, аңлаешлы булуына, гадилегенә игътибар ителсә, артистлар, лекторлар, агитаторлар сүзе дә үтемлерәк, тәэсирлерәк була.

Татарстан радиосының «Тел күрке – сүз» тапшыруына нигезләп, басмага ***Рөстәм Акъегет*** *әзерләде.* ■

Алар ГУЛАГта дуслашкан

Лилия Гаделшина

Күренекле татар язучысы Аяз Гыйләҗевнең әле исән вакытта эзләп тә таба алмаган ГУЛАГ лагерьларында танышкан венгр дусты быел октябрьдә Казанга кайтты. Венгриядә танылган тәрҗемәче Арпад Галгоци татар язучысының «Йәгез, бер дога!» романы герое булуын белде. Романны хәзер рус телле укучылар да укый алачак.

Аяз Гыйләҗевнең сәяси тоткынлыкта үткәргән алты елга якын гомеренә багышланган әсәрен рус телендә чыгарырга Татарстанның Беренче Президенты, бүгенге көндә Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев тәкъдим иткән. Туксанынчы еллар башында язып тәмамлаган һәм тәүге тапкыр 1993 елда «Казан утлары» журналында дөнья күргән «Йәгез, бер дога!» романы, Наил Ишмөхәммәтов тәрҗемәсендә, күптән түгел «Аргамак» журналында басылды (беренче һәм икенче бүлекләре). 2017 елда ул Татарстан китап нәшриятында аерым китап

булып дөнья күрәчәк. Аяз Гыйләҗевнең КФУ галимәсе Миләүшә Хәбетдинова җитәкчелегендә әзерләнүче алты томлыгы да Татарстан китап нәшриятында чыгып килә, аның инде дүрт томы нәшер ителде, киләсе елларда калган ике томы да басылачак.

Арпад Галгоци турында беренче тапкыр татар җәмәгатьчелеге быел Миләүшә Хәбетдинова аша ишетеп белде. Рус телен ГУЛАГ лагерьларында камил өйрәнгән, төрмә китапханәсендә рус әдәбияты белән танынышып, аңа гашыйк булган Арпад Галгоци, иреккә чыккач, тәрҗемә эшенә алына – бөтен гомерен бөек рус әдипләре иҗатын венгр укучысына җиткерүгә багышлый.

«Давайте, помолимся!» романын тәкъдим итү кичәсе Казанда КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында бик күп галимнәр, язучылар, җәмәгать эшлеклеләре һәм Арпад Галгоци катнашында оештырылды. Арпад Галгоци Татарстан башкаласына рус шагыйре Державин укуларына чакырылган иде. Аяз Гыйләҗев белән 1950 нче еллар башында ГУЛАГта дуслашкан, соңрак «Йәгез, бер дога!» романында телгә алынган Арпад Галгоцины Миләүшә Хәбетдинова эзләп тапкан. Язучының хатыны Нәкыя апа да Аяз Гыйләҗевнең үзе исән вакытта 1950-1955 елларда Караганда төбәгендә ГУЛАГ төрмәләрендә танышкан дусларын эзләвен хәтерли. 60 яше тулган көннәрдә ул аларны бер өстәл артына җыярга хыялланган. Хәтта Караганда якларына да барып кайткан, ләкин сәяси репрессия корбаннары Сталин вафатыннан соң акланса да, әле архивлар ачылмау сәбәпле, беркемнең дә эзенә төшә алмаган. Фамилиясен Голгоци дип эзләп, бер хәреф аркасында ике дусның очрашуы булмый калган, ди Миләүшә Хәбетдинова. Чынлыкта исә Арпад Галгоци Венгриядә танылган шәхес, рус шагыйрьләренең аның тырышлыгы белән венгр телендә яңгыраган әсәрләре әдәбият белгечләре тарафыннан иң камил тәрҗемә, дип бәяләнә.

***

Арпад Галгоци, милли-патриотик хәрәкәттә катнашкан өчен, 19 яшендә 1947 елда кулга алына, 20 елга хөкем ителеп, 1954 елга кадәр Караганда төрмәсендә утыра. Ләкин иреккә чыккач та әле туган иленә тиз генә кайта алмый, документлар әзер булуын көтеп, 1960 елга кадәр Карагандада яшәргә мәҗбүр була.

– Мин төрмәдә рус телен өйрәндем, шунда үзем өчен рус әдәбиятын ачтым. Венгриягә кайткач, тәрҗемә әсәрләрне укып карадым, берсе дә ошамады, шулай итеп, үзем тәрҗемәгә тотындым. Бүгенге көндә XVIII, XIX, XX гасырларда яшәп иҗат иткән 68 рус әдибенең барлыгы 500ләп шигырен тәрҗемә иттем, – дип сөйли тәрҗемәче.

88 яшьлек Арпад әфәндене Аяз Гыйләҗевнең гаиләсе – Нәкыя апа, уллары Искәндәр, Мансур, Рашат язучының каберенә алып барган, Казанны күрсәткән. «Бигрәк ямьле шәһәр!» – дип, Казанны бик ошатты. Татарстанны күптән күрергә теләгән икән», – ди галим Искәндәр Гыйләҗев.

Арпад Галгоци Аяз Гыйләҗевнең аны эзләвен белмәвенә күңеле әрнүен әйтте. Югыйсә, Россиягә ике тапкыр – 1993 һәм 2000 елларда килгән булган. Ул вакытта Россия Президенты Борис Ельцин аңа, әдәби эшчәнлеге өчен, «Дуслык» орденын тапшырган.

– Төрмәдә Аяз Гыйләҗевне яхшы хәтерлим. Таңга кадәр сөйләшә, ул миңа – үзенең милләте, ә мин аңа үзебез турында сөйли идем. Төрмәдә төрле кешеләрне очраттык, әмма тоткыннар арасында үз милләтенең



асыл уллары күп иде. Арабызда төрле милләт вәкилләре бар иде: алман, поляк, япон, кытай, латыш... Үзем ике татар егете белән якыннан аралаштым, аларның берсе – Аяз. Безне өмет яшәтте, кайчан да булса моннан чыгачагыбызга ышандык. Сөйләшү, аралашу, фикерләшү безгә сынмаска ярдәм итте, көч бирде, – дип, үткән елларны искә алып сөйли Арпад Галгоци.

ГУЛАГ еллары турында ул өч томлы автобиографик повесть язган. Әмма аларда нигездә венгр халкының ГУЛАГларны кичүе турында бәян ителә. «Безнең милләт бик бердәм булуы белән аерылып торды. ГУЛАГта бер венгр кешесе икенчесе белән соңгы телем ипиен дә бүлешергә әзер иде. Без шушы бердәмлек исәбенә исән калдык», – ди ул. Дүртенче том итеп, Арпад әфәнде ГУЛАГтагы иптәшләре турында язарга планлаштыра. Анда, әлбәттә, Аяз Гыйләҗевне дә искә алачак.

Миләүшә Хәбетдинова сөйләгәнчә, Аяз Гыйләҗев әсәрләренең беренче томында урын алган ике портретның авторы Арпад Галгоци икәнлеге ачыкланган. Арпад Галгоциның төрмәдә утырганда рәсем ясау сәләте ачыла, ул каләм белән дусларының портретларын ясаган. Аяз Гыйләҗевнең дә портретын иҗат иткән. «Ул аны ике төрле итеп ясаган: берсендә – төрмә киемендә: башында – бүрек, өстендә – бушлат, ә икенчесендә – затлы костюмнан-галстуктан. Бу күренеш белән Аяз Гыйләҗевнең ул чактагы тормышын һәм чынлыкта ничек булырга тиешлеген күрсәтергә теләгән. Без беренче томга керткәндә бу рәсемнәрнең авторына игътибар итмәгән идек», – ди Миләүшә Хәбетдинова. Нәкыя ханым ул портретларның төрмәдән хат белән килүен әйтә, алар әле дә гаилә архивында кадерләп саклана. Беренче томны Нәкыя Гыйләҗева Арпад Галгоцига да истәлеккә бүләк итте.

Арпад Галгоци хәзер «Йөгез, бер дога!» романын венгр теленә тәрҗемә итү турында хыяллана. ■

Зур Чынлының олуг улы

Бертуган Усмановлар. 1919 ел

Күренекле язучы, хәрби һәм сәяси эшлекле Шамил Усмановның кыска һәм аянычлы гомере шанлы да, канлы да вакыйгаларга гаять бай. Шамил Хәйрулла улы Татарстанның хәзерге Чүпрәле районы Зур Чынлы авылында дөньяга килә. Мәдрәсәдә укый, һөнәр училищесын тәмамлый. Шамил Усманов, ватандашлар сугышының башыннан ахырынача катнашып, 21 яшендә үз инициативасы белән төзелгән аерым татар укчы бригадасының комиссары була. 27 яшендә аңа дивизия комиссары дигән хәрби дәрәҗә бирелә. Ә ул чакта дивизия комиссары генерал дәрәҗәсенә тиң санала.

Шамил Усманов әдәбият үрләренә дә шулай зур тизлек белән күтәрелә. Аның «Канлы көннәрдә» дигән беренче пьесасы 1919 елдан башлап фронт театрларында, үзе әйтүенчә, мең тапкырдан артык куела. «Памирдан радио» дигән фантастик повесте, «Легион юлы» дилогиясе, «Кичеккән фәрман» драмасы әдипкә зур популярлык китерә.

Гел ашкынып, халык мәнфәгатьләрен алга куеп яшәгән бу шәхес Татарстан радиосын оештыруга зур көч куя, татар язуын латин имлясына күчерүнең иң актив тарафдарларыннан берсе була.

Канлы 30 нчы елларда да Шамил Усманов көчле, сынмас ихтыярлы милләт улы булып кала, үз гомерен саклау өчен берәүгә дә яла якмый, кулга алынгач, коточкыч җәза-кыйнауларга дучар ителеп тә, үзен «гаепле» дип танымыйча, дөньядан чын каһарманнарча китә.

Әлеге фаҗигале еллар турында Шамил Усмановның кызы Айсылу Усманова-Сагайдак менә болай искә ала: *«1936 елда без Мәскәүдән Казанга кайттык. 1937 елның 8 апрель таңында уянып китеп, күзләремне ачсам, пальто кигән әтиемне һәм ишек катында хәрби киемле ике кешене күрдем. Әтием миңа: «Вакытлыча аңлашылмаучылык килеп*

чыкты, мин НКВДга барырга тиеш. Ә син әбиең янына бар», — диде дә чыгып китте».

Бу вакытта Айсылуга 15 яшь була.

1937 елның 3 декабренә, тикшерү эше тәмамлангач, этиегез параличтан үлде, дип, Айсылу Усманованы 1939 елда НКВДга чакыртып, этисенең үлеме турында хәбәр итәләр.

1959 елда Айсылу апа НКВДга этисенең документларын, кулъязмаларын сорарга баргач, милиция майоры аңа: «Сез этиегез белән горурлана аласыз, ул бернинди протоколга да кул куймаган», — дип белдерә. Әмма, ни аяныч, әдипнең фатирында тентү вакытында алынган китаплар, документлар, кулъязмалар барысы да юк ителгән булып чыга.

Ә менә озак еллар Татарстан дәүләт музеенда фәнни хезмәткәр булып эшләгән тарих фәннәре докторы, профессор Алтер Литвинның «Запрет на жизнь» дигән, 1993 елда нәшер ителгән китабында Ш.Усманов турында мондый документ китерелә: *«1898 елда туган, язучы, Казанда яши, ВКП(б) әгъзасы, татар, югары белемле, Зур Чынлы авылыннан, мулла улы, әлек хөкем ителмәгән Шамил Усмановны, җәза чарасы буларак, ТАССР НКВДсының 1 нче төрмәсенә ябарга».* Күрәсез, әлеге рәсми язуда да Шамил Усманов Зур Чынлы авылында туган, дип күрсәтелә. Ә элегрәк чыккан дәреслекләрдә, библиографик белешмәләрдә әдипне хәзерге Пенза өлкәсенең Кузнецки районы Пәндәлгә авылында дөньяга килгән, дип язалар иде.

Бу уңайдан «Кызыл Татарстан» гәзитендә (1925 ел, 12 сентябрь) З.Сибгатуллин дигән авторның мәкаләсендә болай дип язылган: *«Буа кантоны Иске Шәйморза волостенда Зур Чынлы дигән авыл бар. Шушы авылның Хәйрулла хаҗи дигән кешесе Николай заманынан ук авылда тормыйдыр иде. Аның балалары Шамил һәм Гали Усмановлар Зур Чынлы авылында кунак булып кына күренәләр. Үзләре авылында тормасалар да, Шамил һәм Гали Усмановларның авылдагы җирләре үз исемнәрендә калган исәпләнә».*

Әйе, Хәйрулла хаҗи революциягә чаклы ук туган авылыннан китеп, мөгаллим булып эшләсә дә, уллары Шамил белән Галинең имана җирләрен Хәйрулла хаҗинең туганы Гыйниятулла Усманов эшкәрткән. Хәйрулла Хаҗинең Зур Чынлы авылына улы Шамил белән кайтып йөргәнен әле минем әтием дә искә алып сөйли торган иде. Шамил Усмановның тууына 70 ел тулуга багышланган тантанада катнашып, мин әтинең шул вакыйгаларга бәйле хатирәләре белән уртаклашканын да хәтерлим әле.

Флүрә Дәминова,
Татарстан Милли музееның өлкән фәнни хезмәткәре. ■

Төрек кызы Әминә килен булып төшкән нигез. 2016 ел

Еллар кайтавазы яки бер сәфәр

Фатих Кутлу

Галиәсгар Камал исемендәге театрның олы хөрмәткә лаек артисты Илдус абый Әхмәтҗан биш-алты ел элек: «Әтиемнең беренче хатыны төрек булган. Төркиянең кайсы шәһәреннәндер, мәгълүмат юк дәрәҗәсендә», – дип сөйләгән иде. Ул вакытта бу мәсьәләгә карата күңелдә беркадәр кызыксыну хисе уянса да, әлеге хис, нишләптер, мине җилкетерлек дәрәҗәдә кабынып-дөрләп китә алмады.

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның 130 еллыгына әзерләнгән мәлләрдә башыма: «Хәзерге көн әдипләре, сәнгать әһелләре арасында Тукайны төштә күрүчеләр бармы икән? Мондый төшләр матбугатта басылып чыкса, бик кызыклы булыр иде», – дигән фикер килде. Шул уңайдан Илдус абыйга да шалтыраттым. Тукайны төштә күрмәгән күрүен. Ләкин сөенечсе бар икән: күптән түгел абыйсы – күренекле шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанның ике томлык шигырьләр китабы чыккан. Шул җыентыкны, җай табып, миңа да тапшырырга теләвен белдерде. Өстәвенә, китапта этиләренең беренче хатыны – төрек кызы турында тулы бер поэма да урын алган.

Инде ничә ел күрешмәгән Илдус абыйга шалтыратырга Тукай сәбәпче булган иде. Менә хикмәт! Очрашуыбызны да... Тукай оештырды.

Без унбишенче апрель, җомга көнне, иртәнге сәгать уннар тирәсендә, театр янында Татар зиратына алып баручы автобус көткәндә күрештек. Илдус абый сеңлесе Сания апа белән бергә төзегән ике томлыкны бүләк итте. Мәгълүм поэма «Карачкы» дип атала икән[1]. Зиратка барганда без янәшә утырдык.

Илдус абыйның этисе Хәниф әфәнде

[1] Рәшит Әхмәтҗанов. Әсәрләр. Икенче том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014. – Б. 161-189.

(1891-1958) Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында Төркиянең бер авылыннан Әминә исемле төрек кызын хатынлыкка алып кайткан. Кызның әти-әнисе әүвәл кияүдән Коръән укытканнар. Диндар икәнен белгәч, багалмаларын тыныч күңел белән аңа бирергә булганнар. Хәниф әфәнденең шушы төрек хатыныннан Бәхтияр, Әмрия һәм Мәгъния исемле өч баласы туган. Аннан соң ана озак яшәмәгән, яшь килеш дөнья куйган. Балаларның төпчеге – 1927 елда туган Мәгъния исемлесе әле дә исән-имин икән, Баулы районының Татар Кандызы авылында гомер кичмеше.

Автобустагы әңгәмә күңелемдәге дәрт учагын кабызды. Төрек анадан туган Мәгъния әби белән телефоннан булса да сөйләшәсем, аның тавышын ишетәсем килде. Түзмәдем, бу эштә ярдәм сорап Илдус абыйга шалтыраттым. Сөйләшү Мәгъния әби өчен дә мәгънәле булыр, дип уйладым. Чөнки шушы яшенә җитеп әнисе милләтеннән, аның туган иленнән, үз каныннан булган кеше белән тәүге мәртәбә сөйләшү булачак иде бит бу!

Ниһаять, көтеп алган мизгел җитте. Бик нык дулкынланам. Вакыт 16 сәгать 26 минутны күрсәтә. Телефон номерын җыйдым. Төрек апасының тавышын ишеттем. Башта үзем белән таныштырдым. Аннан әнисе турында белгәннәрен сөйләвен үтендем.

– Әнкәм миңа яшь ярым чакта вафат булган, – дип башлады ул сүзен. – Шуңа күрә, әниемне бер дә хәтерләмим. Әткәй белән әнкәйнең хөкүмәт никахлары да булган. Аларның язылышу кәгазе Казанда сакланырга тиеш.

Әнкәй мәрхүмә беренче көннәрендә чишмәдән су алып кайтканда чиләккисмәкне җилкәсенә куеп ташый торган булган. (Төркия авылларында, чыннан да, шулай гадәткә кергән. Ул бу сүзләрне әйткәндә үзебезнең кызлар күз алдыма килеп басты. – *Ф.К.*) Авыл хатыннары: «Алай йөреп җилкәңне авырттырырсың», – дип, суны көянтә-

Бәхтияр Әхмәтҗанов (1923-2006)

чиләк белән ташырга күндергәннәр үзен...

Хәниф әфәнде балаларына әниләре турында бик сөйләмәскә тырышкан. Болар да кызыксынып артыгын сорамаганнар.

– Өч баланың кайсы әниегезгә күбрәк охшаган соң? – дим.

– Әти Әмрия түтәмне әйтә иде.

– Әниегез яшьли бакыйлыкка күчкән, ничек вафат булуын белмисезме?

– Әни Төркияне, әти-әнисен, туганнарын бик нык сагынган. Түзәр әмәле калмагач, әтидән: «Мине бер мәртәбә булса да туган илемә алып кайт, зинһар!» – дип ялвара башлаган. Алар монда кайткач, дөньялар үзгәреп куйган шул, СССР дигән яңа дәүләт төзелгән. Ишек-капкалар ябылган. Шуңа да карамастан, әти аның гозерен үтәргә ризалашкан. Озакламый, тәвәккәлләп, сәфәргә кузгалганнар. Ләкин чик буенда боларны кире борганнар, чыгармаганнар. Әнием бик каты елаган. Соңгы сулышына кадәр әти-әнисен, туганнарын, ватанын күрә

алмый тилмереп, интегеп яшәгән. Ахыр чиктә бу хәсрәт-сагышка йөрәге түзмәгән, саргаеп үлгән...

Ул сөйләгәндә миңа әллә ничек булып китте. Башымнан яшен тизлегендә уй үтте: Әминә апа монда янып көлгә әверелгән булса, тегендә әти-әнисе, туганнары сагынып-саргайгандыр. Нинди хәсрәт!

Мәгъния әби сөйләвен дәвам итә:

– Әтине: «Әниемне әллә кайлардан ник алып кайттың», – дип гел әрләдем.

Әтисе илләр арасына шыгырдап тимер пәрдә төшәсен каян белсен соң...

Әңгәмә тәмамланды. Телефонны куйдым. Аннан соң да озак вакыт аңыма килә алмый интектем әле. Күңелемне-барлыгымны милләттәшем, якташым Әминә апаның хәсрәте биләп алды: «Их, ятим хатын! Җеназаңда ни атаң, ни анаң, ни туганың катнаша алмаган. Алар синең яшьли үлеп киткәнеңне дә белмәгәндер. Озак еллар буе, гомерләре өзелгәнче, күзләрен ерак офыкларга төбәп: «Кызыбыз бер кайтмасмы?» – дип өметләнгәннәрдер. Соңгы сулышларына кадәр хат ташучыны сагалаганнардыр...

Их, Кандыз авылы! Синең йөрәгеңдә милләттәшем – ятим ана, Әминә анам ята!

Их, Әминә ана! Бәхтиярең тугач: «Әнием, әтием! Әби-бабай булдыгыз!» – дип, алар белән шатлыгыңны бүлешә алмагансың. Алар Әмриянңне дә, Мәгъниянңне дә белмәгәннәр. Ни шатлыгыңны бүлешергә, ни кайгыңны уртаклашырга якын кешең булмаган.

Их, Мәгъния әби! Син анасыз да, әбибабайсыз да үскәнсең. Туганнарыңны, ана телеңне белмичә, сыңар канатлы килеш картайгансың. Синең яныңа бару – минем изге бурычым. Гомереңдә бер булса да әниеңнең милләттәшен күрергә хакың бардыр бит?!

Их, Әминә ана! Әти-әниең, туганнарың исеменнән кабереңә бару – мөкатдәс бурычым...

Күңелемдә, уемда гел бернәрсә: ул килен булып төшкән, гомер сөргән, ниһаять, җан тәслим кылган йорт һаман торамы икән? Аның сагынулы күз яшьләре тамган туфракны күрәсем, шул җирләрдән узасым килде...

Мин, һичшиксез, Кандызга барырга тиешмен! Бу эшне озакка сузарга ярамый. Мәгъния әби – әнисеннән калган бердәнбер истәлек. Аның да яше туксанга җитеп килә. Дөнья хәлен белеп булмый. Юкса, гомер буе үкенермен, Аллаһ сакласын!

***

Ул арада мин Рәшит Әхмәтҗанның «Карачкы» поэмасын укып чыктым. «Әменнең (авыл халкы аны шулай йөрткән. – *Ф.К.*) туган илен сагынуы» дигән бүлек мине һушсыз итте. Күз алмаларым дымланып чыкты. Автор төрек ананың хәсрәтен, сагышын, үз башыннан кичергәндәй, гаҗәеп оста итеп тасвирлап биргән. Мең рәхмәт аңа!

Әсәрне кат-кат укып чыктым. Очраган бер кешегә укып күрсәттем. Мәгъния әбигә дә укыйсым килде ул юлларны.

«Карачкының бала елавын тыңлавы» дигән бүлектә Әминәнең ничек үлүе ап-ачык тасвирлана:

Кучеп беткән шулай.
Үлемнәрнең
Мондыйлары була бик сирәк.
Сагышлардан саргаюны беләм,
Саргаеп та үлү бар, димәк.

Кандызга бару теләгемне Илдус абый Әхмәтҗанга да җиткердем. Ул моңа сөенде, ләкин шул ук вакытта борчылуын да яшермәде: «Биш сәгатьлек юл бит, кар да эреп бетмәгәндер, юллар пычрак, мәшәкать кенә булмасмы?» Шөкер, фикер-ниятем оешып беткән иде инде.

Юлга әзерләнергә тотындым. Төркиядән алып кайткан чит-чите чигелгән өр-яңа яулыкны, ап-ак төрек сөлгесен һәм төрек тәм-томнарын, төрекчә бишек җырлары яздырылган дискны (әнисе сабый Мәгънияне тибрәткәндә шул җырларны җырлагандыр, дип гөманладым) алып барырга ниятләдем...



Рәшит Әхмәтҗан. Фотографиянең оригиналы: «Түтәй белән җизнәйгә истәлек», – дигән язуны саклый... 1990 нчы еллар

Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗан. 2016 ел

Ләкин, Кандызга барганчы, Казан ЗАГСына юл тоттым. Мәгъния әби: «Әти-әнинең язылышу турындагы таныклыгы Казанда булырга тиеш», – дигән иде бит. (Мәгъния әбинең туу турындагы таныклыгында теркәлгән мәгълүматларны язып алган идем инде.) Казанда кирәкле кәгазьне таба алмадылар. Булса, Баулыда булырга тиеш, диделәр. Ул бик мөһим документ: анда Әминә апаның әти-әнисе, аларның туган еллары, туган җирләре күрсәтелгән булырга тиеш. Бу кәгазь табылган очракта, Әминә апаның туганнарын эзләп табарга җай туачак.

Ул арада җәй – изге Рамазан ае җитте. Илдус абый белән яңадан сөйләшкәннән соң, шунысы ачыкланды: Мәгъния әбинең улы Ярулла әфәнде район үзәгендә – Баулыда тора икән. Күренекле артист: «Мин аның белән сөйләшермен, ул хәзер лаеклы ялда инде, сине бик теләп авылга кадәр алып кайтыр, кайгырма», – диде.

Илдус абыйдан Мәгъния әби һәм аның мәрхүм абыйсы Бәхтиярнең ничә баласы булуы хакында белештем. Аларга да Төркия күчтәнәчләре хәстәрләдем. Әминә апа турында бихисап сораулар туды. Фотоаппаратымны, видеокамерамны әзерләп куйдым.

***

Бүген – егерме беренче июнь. Ниһаять, көтеп алган көн килеп җитте.

Букча әзер. Рәшит Әхмәтҗанның «Карачкы» поэмасы кергән китабы да шунда. Иртүк автобуска утырып, ерак сәфәргә кузгалдым. Күңелдә куаныч катыш дулкынлану хисе тантана итте.

Баулыга килеп җиттем. Анда Ярулла әфәнде белән очраштык. Мин аны тәүге күрүемдә үк төреккә охшаттым. Ул мине якын туганыдай бик җылы каршы алды. Өйгә уздык. Гомер юлдашы Сиринә ханым белән дә таныштык. Ярулла әфәнде бик укымышлы, итагатьле, әдәбиятны, тарихны ярата торган, хискә бай, шигъри күңелле кеше булып чыкты. Сөхбәтләшеп утырганда әтиемнең исемен сорадылар. Мин:

– Нәвзат, – дигәч, Сиринә ханым беравык тынып калды. Аннары:

– Карагыз әле, минем җияннең

(племянник) берсе – Нәвзат, икенчесе – Мулланур исемле бит, – диеп куймасынмы!

– Гөлнараның балаларымы әллә? – дип сораганымны сизм дә калдым.

Сиринә ханым тагын аптырый төште:

– Әйе, сез аны каян беләсез?

– Нәвзат белән Мулланур – минем дә җияннәрем. Гөлнара – игезәк сыңарымның хатыны. Безнең киленебез ул...

Өчебез дә шушы хәлгә шаклар каттык. Баксаң, Сиринә ханымның әтисе белән безнең Мулланур коданың әтиләре бертуган икән бит! Сиринә ханым – Мәгъния әбинең килене. Димәк, Мәгъния әби безгә кодача булып чыга. Аның әнисе Әминә – карт кодача, ире Хәниф әфәнде – карт кода! Сөбханалла! Туганнар ук икәнбез.

Бу хәл минем сәфәр-сәяхәткә аерым бер ямь, үзгә бер төсмер өстәде...

***

Беркадәр игә килгәч, эшкә тотындым. Видеокамераны әзерләп куйдым. Ярулла әфәндедән төрек әбисе турында ишетеп белгәннәрен сорый башладым. Мине иң кызыксындырган сорауларның берсе шул иде: ата-анасы төрек кызы Әминәне бер дә белмәгән чит ил солдатына бирергә ничек ризалашкан икән?

Ярулла әфәнденең җавабы мондый булды:

– Хәниф бабай хезмәт иткән армия солдатлары төрек авылына басып керә. Командир кушуы буенча, алар халыкны интектерә-азаплый башлый. Бабам булачак хатынының гаиләсен яклап чыга, үлемнән коткара һәм алар: «Кызыбызны урыс алганчы, татар алсын», – дип, йөрәк майларын шушы гаскәригә тапшыралар.

Ул авыл турында колактан-колакка йөргән бер сүз генә бар: «Кара борын котычлы, Драгон кариясеннән...»

Әбиемнең бик бай бирнәсе булган. Дөньяда бер чибәр үзе! Чәчләре тез астына җиткән. Аны «солтан кызы» дип йөрткәннәр. Затлы нәселдән. Хискә бай, нечкә күңелле хатын. Беренче баласы Бәхтияр абый 1923 елда туган, икенчесе – Әмрия 1925 елда туган һәм 1939 елда үлгән. Ә минем әни 1927 елгы. Әнигә яшь ярым булганда төрек әбием дөнья куйган. Хәниф бабам өч кечкенә бала белән тол калган, шуннан соң күрше Кирәчле авылыннан Саҗидә исемле унсигез яшьлек ятимәгә өйләнгән. (Ул шулай дигәндә ихтыярсыздан күз алдыма Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән...» әсәрендәге Бибинур образы килеп басты. – *Ф.К.*) Илдус һәм Рәшит абый Әхмәтҗаннарның әнисе була инде ул. Саҗидә апа унике бала тапкан һәм гаиләдәге һәр сабыйны (үгиләрен дә) тигез күреп, рәнҗетмичә тәрбияләп үстергән. (Саҗидә ана – үзе аерым бер тарих инде! Урыннары җәннәттә булсын! – *Ф.К.*)

Әбиемнең төрек булуы белән һәрвакыт горурланып яшәдем. Мин – Төркия ватандашының оныгы! Ул безнең авыл зиратында җирләнгән. Өебез зиратка бик якын. Әбиемнең каберен эзләсәм дә тапмадым. Картлар, бер калкулыкны күрсәтеп: «Монда булырга тиеш», – дип кенә әйттеләр. Әмрия апамның да кабере билгесез.

Кулыбызда төрек әбидән калган бер генә чүпрәк тә юк. Октябрь түнтәрелешеннән соң хәвефле-шомлы, куркыныч еллар килә, алар белән бергә, бабайга «төрек шымчысы» дип шикләнеп карау башлана. Гаиләсенә үлем куркынычы яный. Шуңа күрә, бабай Төркиягә бәйле һәрнәрсәне юкка чыгарырга тәвәккәлләгән, дип фаразлыйм.

Авыл халкы, коткыга бирелеп, бабайның барлык балаларын (хәтта Саҗидә әбидән туганнарын да) «төрекләр» дип мыскыллауга күчә. Әмрия апа ундүрт яшьтә вафат була. Мин, аның үлемендә дә шушы коткының өлеше юкмы икән, дим, чөнки Әмрия

Мәкалә авторы (сулдан беренче) Ярулла абый һәм Сиринә апа белән. 2016 ел

апа, салкын кышкы көндә өстенә юка киенеп, чабатадан гына мәктәпкә бара. Дәрескә соңга калганга күрә, укытучы аны кертми, салкын урамда көтәргә куша. (Бу урында ихтыярсыздан күз алдына кечкенә Апуш килеп баса. – *Ф.К.*) Озакламый үпкә чире Әмрия апаны аяктан ега һәм ул шул сырхавыннан савыга алмыйча үлеп китә.

Рәшит абый Әхмәтҗан әниемне бик нык ярата иде. Авылга кайткач, иң беренче безгә кереп чыга иде. Шигырь китабының икенче томында урын алган фотографиянең оригиналы: «Түтәй белән җизнәйгә истәлек», – дигән язуны саклый.

Мин, кечкенәдән бирле, әбиемнең берәр туганы яисә ватандашымы килеп, аның тарихын өйрәнәчәк, хәлебезгә керәчәк, дигән өмет белән яшәдем. Шуңа чын күңелдән ышандым. Бүген егерме беренче июнь – елның иң озын көне. Безнең өчен бәхетле көн бу, Фатих энекәш!

***

Баулыдагы эшебезне төгәлләгәннән соң, ниһаять, Татар Кандызына (элеккеге атамасы буенча – Сөләйман авылы), Мәгъния әби янына юлга чыгабыз. Район үзәгеннән кырык чакрым ераклыкта икән ул.

Ярты сәгать узды дигәндә авылга килеп кердек. Машинабыз Мәгъния әбинең капкасы төбендә туктады. Мин, видеокамераны кабызып, Ярулла абыйга тоттырдым. Әнисе белән тәүге очрашуымны истәлеккә саклап калдырырга кирәк иде. Тарихи мизгел бит бу!

Ярулла абый бусагадан узганда ук: «Әнкәй, төрек туганыңны алып кайттым!» – диде. Без күзгә-күз очраштык. Ябык кына, матур, ап-ак әби икән. Күрешкәч, төрек гадәте буенча, кулын үптем һәм маңгаема терәдем. Очрашу мизгелен гомер буе көткән, диярсең: кочаклашканнан соң шактый озак аерыла алмадык. «Мин шул төрек кызы инде», – диде ул. Әминә анадан калган бердәнбер тере хатирә...

Утырышкач-урнашкач, иң элек букчадан яулыкны чыгардым. Ул көтелмәгән бүләккә бик нык сөенде һәм: «Моны башыма төрекчә итеп бәйлә әле», – дип сорады. Шулай иттем дә. Аннан соң алдына ап-ак сөлге җәйдем. Кулына төрек ризыклары, бишек җырлары яздырылган дискны салдым. Мәгъния әбинең күңеле тулды. «Боларны әнкәм җибәргән төсле кабул итәм», – диде...

Ахыры киләсе санда ■

Кырлы бәләк

Агач эшләнмәләр

(ТР Милли музее фондларыннан)

Крестьян тормыш-көнкүрешендә агачтан эшләнгән әйберләр аерым урын алып торган. Агач – иң уңайлы, арзан, эшкәртү һәм файдалану өчен дә кулай материал. Агачтан нәрсә генә ясамаганнар: балалар өчен бишек һәм уенчыклар, хатын-кызларга йон эрләү кабасы, орчыклар дисеңме, агач савыт-саба, чүмечләр... Агачтан эшләнгән һәр әйберне, нәкышләп, кисеп-уеп бизәкләгәннәр. Һәр бизәкнең үз мәгънәсе булган: мәсәлән, түгәрәк – кояшны, дулкынлы сызыклар суны белдергән. Йөзем тәлгәшләре, чәчәк, яфрак һәм сабакларны үсемлек орнаменты ярдәмендә агачка төшергәннәр алтын куллы осталар. Контурлы ябыштырылма бизәкләр белән тәрәзә йөзлекләрен, кәрниз асты яссылыкларын, йорт почмакларын матурлаганнар.

ТР Милли музее фондында агачтан ясалган йорт кирәк-яраклары коллекциясе бар. Аның нигезен Идел буе осталарының эшләнмәләре тәшкил итә.

Руфия Мөхетдинова әзерләде. ■

Кырлы бәләк

Кырлы бәләк

Кабалар

Кырлы бәләк

Кырлы бәләк

Каба

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның ноябрь ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Сугыш сафыннан

Сугыш сафындагы мөселманнар укырга китап вә гәзитә юкка бик борчыламыз. Йортта калган кардәшләремез безгә китап вә иске булса да, үзләре укыгач, гәзитәләрен йибәрсәләр, кардәшлек иткән булырлар иде. Адресымыз: «Кояш» идарәсе[1].

***

«Гасыр» көтебханәсе [китапханәсе] тарафыннан йибәрелгән китапларны кулымызга алдык. Бер китап күрер өчен әлләни бирергә әзер торган мөселманнарны шатландырган өчен, полкның 4 нче ротасындагы бөтен мөселманнар исеменнән, «Гасыр» көтебханәсе ширкәтенә рәхмәт укыйм. Габделәхәд Сөләйманов.

Кояш. – 1916. – №1039. – 6 ноябрь.

Угрылыклар

Соңгы көннәрдә борадәран Кәримовларның яңа кибетеннән бик күптөрле мал угрыланганы беленгән. Яшерен полиция шул кибеттә хезмәт итә торган кибетчеләрдән Шиһабетдин Мифтахетдинов, Салих Алмазов, Сәфәргали Әхмәдиев, Хәсән Йосыпов дигән кибетчеләрне кулга алган. Угрыланган нәрсәләрнең бер кыйсеме бу кибетчеләрдән табылып алынган. Моннан башка, Габдулла Морасов дигән крестьяннан, Йосыпов аркылы угрыланган бер партия оек табылып алынган.

Сошествия мәйданында[2] сәүдә итә торган Фәйзрахман Гыйззәтуллинны тентегәч, аннан да Кәримовның бик күп малы тыбылган. Болардан башка Мәскәүский урамда Юнысов йортында урам кибете тотучы Җарулла Корбангалиевтан да Кәримовлар кибетеннән угрыланган байтак мал табылган.

Театр

Г.Кариев идарәсендәге «Сәйяр» труппа үткән җомга көнне «Большой театр»да «Тигезсезләр» белән Г.Камалның «Өйләнәм... Ник өйләндем?» дигән яңа комедиясен уйнады.

«Тигезсезләр»дә татарлыгын сизә торган бөтен татар дөньясында танылган вә танылуын үзе дә бик яхшы белә торган татар мөхәррире Сөләйман ролен Үзбәк Тинчурин бик яхшы үтәде. Тик 35 яшендә генә булып, яшь кенә бер кызга өйләнүне дә артык кире какмаган Сөләйман өчен, Үзбәк Тинчуринның сөйләшүендә булган вәкарь артыграк иде. Бу вәкарьгә бераз дәрд вә нәшат [шатлык] та кушылса, тагы да яхшырак чыгар иде төсле. Моның өчен Үзбәк

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Шул санда ук «Кояш» идарәсенең сугыш сафының күп урыннарына газета җибәреп торганлыгы язылa.

[2] Постау бистәсендәге, хәзерге Туфан Миңнуллин урамындагы «Сошествия Святого Духа» чиркәве тирәсе.

Тинчуринга тынын гына ул хәтле үк түбән алмаска кирәк булыр иде!

Гимназистка Рөкыя ролен уйнаган Ильская артыкны теләргә калдырмады. Аның Рөкыясе нәкъ шул пьесада бирелгән татарлыкны баш белән түгел, бәлки йөрәк белән сөя торган Рөкыя иде.

Сәлимә ролен уйнаган Болгарская бу юлы үзенең ролен бик һәйбәт үтәде. Гомәр ролен үтәгән икенче Камалда үз эшен сөя торган Гомәрнең эше хакындагы сүзләрендә күрсәтергә тиешле булган җылылык йитми иде.

Сафыйулла Насыйбуллин ролен уйнаган Кариев, гакыллы вә тәҗрибәле урта кулдагы карт татар сәүдәгәрләрен бик һәйбәт тасвир иткән хәлдә, Закир Әхмәдич ролендә ул Сакаевны сагындырды. Аның ашыгып сөйләве аркасында, бу көлкеле роль үзенең тәэсирен бирә алмады.

Абдулкә ролен уйнаган Уралов үзенең ролен бик һәйбәт үтәде. Аның икенче пәрдәдә Рөкыя кыланышына гаҗәпләнүе, соңгы пәрдәдә аннан гафу үтенүе бик самими чыкты.

Галиев ролендәге Әбүбәкеров белән Маһруй ролендәге Гомәрованың рольләрен үтәүләрендә тигезлек, кыланышларында табигыйлек юк иде.

Г.Камалның «Өйләнәм... Ник өйләндем?» дигән комедиясе җәйге театрларда уйнала торган көлкеле генә, җиңел генә фарслар җөмләсеннәндер. Анда канторда хезмәт итүче Әхмәд ролен Кариев бик шәп үтәде. Бүтәннәр дә рольләрен яхшы гына үтәделәр. Бу фарс халыкны бик көлдерде. Театрда халык күп иде. З.Нуркин.

Иделдә

Боз бик каты ага башлаган. Усия турында өченче көн боз җыелып калган. Идел аркылы күчә торган пароход көненә ике тапкыр гына, бик читенлек белән генә күчә ала башлаган инде.

Кояш. – 1916. – №1042. – 13 нояб.

Җиһан остазбикәнең вафаты

Бик күп еллар фәкать үз иҗтиһады илә генә кызлар мәктәбе тәрбия итеп килгән Җиһан (мәрхүм Кәмал карыйның хатыны), 73 яшендә улдыгы хәлдә, 13 нче ноябрьдә дарелбәкагә иртихал итеп[3], кичә өйләдән соң җеназасы укылып, гүр иясе булды.

Мәрхүмәнең үзеннән соң якын варисы калмаса да, укучы кызларны урамда калдырырга теләмәгәнлектән, язга кадәр мәктәптә укуны дәвам иттерүне мөгаллимәләренә васыять итеп калдырган. Үзенең бер йортын мәктәп вә мәдрәсәләр файдасына вәкыф иткән.

Кояш. – 1916. – №1043. – 15 нояб.

Мөселман прапорщик

Минзәлә өязендә мәшһүр Лотфулла хәзрәт Мансуровның мәхдүме Лотфырахман Мансуров, учительлек ләвазименнән [хезмәтеннән] гаскәри хезмәткә алынганнан соң, Чугуев гаскәри мәктәбен бетереп, прапорщиклык дәрәҗәсен алгач, Казанга хезмәт итәргә тәгаен ителгән иде. Хәзер Мансуровның истигъдады [сәләте] тәкъдир кыйлынып, Одесса гаскәри округы штабына йибәрелгән.

Кояш. – 1916. – №1044. – 17 нояб. ■

[3] Дарелбәкагә иртихал итеп – бакый дөньяга күчеп, ягъни вафат булып.

Вак-вак лəтыйфəлəр* һəм хикəя кисəклəре



КАСЫЙМ КЫЗЛАРЫНДА ТАТАРЛЫК

Розочкам, җаным! Запискаңны палучил. Үзеңне бик скучать иттек. Кичә капка төбеңдә ямь юк иде, патамучто син юк идең. Анда: Астра, Фиалка һәм Ландыш та булдылар. Сине исләп утырдык.

Җаным, Розочка! Син бүген безгә зайди. Бездә Ризидә дә булачак. Пагода яхшы булса, прогулкага чыгармыз.

Хуш, сәламәт бул. Синең Розочкаң.

ИГЪЛАН

Яшь егет кәләш эзли...

Гыйффәтле, инсафлы чибәр генә бер кызга өйләнмәкче булам...

Үзем сугыш башланганнан бирле аракы эчмим... Тәмәкене дә бик сирәк (тартасым килгәндә генә) тартам. Яшем октябрь башы белән 64кә чыга. Күзләрем яхшы күрә, урт тешләрем нык, ипи йомшагын чәйгә җебетмичә дә ашый алам.

Кыз тарафына шартлар:

1) яше 17дән узмаган булсын (өч кенә көн узган булса да ярамый);

2) байлыгы шарт түгел, акчасы һәм нәрсәләре күп булса, фәкыйрь булса да ярый;

3) яше 17дән узмаган булса, карчык булса да ярый;

4) замана модасына ярамый торган булсын, аягына кыш көннәрендә ак сарык йоныннан киез ката, җәй көне оек белән башмак яхуд милли чабата киеп йөри торган булсын, башыннан бөркәнчеге (сигез чирекле француз яулык) төшмәсен;

5) көндәшләре белән кычкырышмый торган сабырлы, вәкарьле бәндә булсын.

Татар бае.
«Ялт-йолт» журналы. – 1916. – №116. – Б.10-11.

---
* Ләтыйфә – мәзәк.

ЗАМАННАН ЗАРЛАНУ

Тукайның:

«Бер заман бер төшкә килгән: ат белән арба, чана,
Бу өчәү һәрберсе үз тормышыннан зарлана»,

– дигән сүзләрен укыгач, мин дә бөек шагыйребез шикелле шөһрәт казанмам микән дип, ошбу сүзләрне язып ташладым.

Бер ялкау ученик агызыннан

Һич тә тормышның кызыгы юк миңа, иптәшләрем!
Төрлечә итеп карыймын: алга бармый эшләрем.
Дәфтәр тулган: «икеле», «ноль» вә «бер»ләр илән;
Кайтам өйгә калтырап мин, күзләрем гел яшь илән.
Юл буе уйлап кайтамын: «Әти күрсә нишләрем?»
Яшь бала күк мин җылыймын: шак-шак итә тешләрем.
Һәр класста икешәр ел утырам мин, юк бәхет;
Көлсә икән, җылмаеп, бер хәлфә абзый миңа «хоть».
Кайгы-хәсрәткә чумамын – юк праздник, юк гаед;
Нишлим инде, иптәшем, соң булгач үземдә гаеп?
Һич тә рәтләп аш ашамыйм, ачлы-туклы мин йөрим;
Алладан сорыйм һаман да: «Ал мине, тизрәк үлим!»
Йокласам, төшләр күрәм, җеннәр күрәм;
Дәфтәрем тулган «икеле», «ноль» вә «бер»ләр күрәм.

Татар шагыйре агызыннан

«И синең тормыш әле оҗмах кебек,
Син торасың үз өеңдә падишаһ баласы кебек.
Әйт минем тормышны, иптәш, барыгыздан мин фәкыйрь,
Һич кеше булмас бәхетсез миннән актык», – ди шагыйрь.
Мин язам – урлыйм китаплардан шигырь;
Аударам рустан татарга, кайсы яхшырак булыр?
Көн-төн утырам язуда, мин бетәмен – йөткерәм;
Шулпалы ашны аенда, атнасына бер күрәм.
Язмаган булса шигырьләр Некрасов, Пушкин, Тукай;
Кайдан урлап язар идем мин соң аларны болай?
Ну рәхәт тә мин торам соң, – ди кәвешче Нигъмәтҗан,
Тормышым алтын минем: кайгы да юк, кыйналмый җан.
Мин укымадым сезнең күк, укый-яза белмәдем,
Юк китапларны күтәреп, мәдрәсәгә йөрмәдем.
Шунда да мин сездән артык, сездән уңгай тормышым;
Тамагым тук, өст бөтен, рәхәт минем көнкүрешем.
Мин тегәм кәвеш, батинка, туфлиләр,
Укымыйм сезнең кебек юк-бар вә чуп-чар нәрсәләр.
Һәркөнне тапкан табышым җитә һәммә нәрсәгә,
Кирәгенчә эчәсең дә, калганы да кесәгә.
«Балапан» – Петропавел.

«Ялт-йолт» журналы – 1916. – №118. – Б.7-8.

Текстны һәм искәрмәләрне Рәйсә Шәрәфиева әзерләде. ■

Оренбург өлкәсе, Шарлык районы, Мостафа авылында Муса Җәлилгә куелган һәйкәл

«Безнең мирас»
елъязмасы / ноябрь

• 165 ел элек (1851)

Казанда «Урак һәм чүкеч» заводына нигез салына.

• 130 ел элек (1886)

Сәяси эшлекле, педагог, географ Нәҗип (Мөхәммәтнәҗип) Латыйф улы Хәлфин (1886-1937) дөньяга килә.

• 95 ел элек (1921)

Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы «Ачлык» исемле әдәби җыентык чыгарырга карар бирә. Ф.Бурнаш, Ф.Сәйфи һәм И.Кули составында редколлегияраслана.

Бу җыентык, «Ачларга әдәби ярдәм мәҗмугасе» исеме белән, 2 китап булып, 1922 елда чыга. Редакторлары – Г.Ибраһимов һәм Ф.Бурнаш.

• 90 ел элек (1926)

20-25 ноябрьдә Казанда хәреф киңәшмәсе эшли. 1926-1927 елларда татар телендә дәреслекләр чыгаруда кулланыр өчен гарәп шрифтында 30 хәрефтән торган алфавит кабул ителә.

• 75 ел элек (1941)

«Наемщик» музыкаль драмасының (Таҗи Гыйззәт әсәре, Салих Сәйдәшев музыкасы) премьерасы була.

• 55 ел элек (1961)

Габдрахман Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше» романы китап булып дөнья күрә.

Оренбург өлкәсе, Шарлык районы, Мостафа авылында Муса Җәлилгә һәйкәл ачыла.

• 50 ел элек (1966)

3 ноябрьдә Казанда Муса Җәлилгә һәйкәл ачыла.

• 45 ел элек (1971)

21 ноябрьдә язучы Сөббух Рафиков (1913-1971) вафат була.

• 25 ел элек (1991)

2-9 ноябрьдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев Швейцариядә интеллектуаль милекне саклау буенча Бөтендөнья үзәгенең (ВОИС) чираттагы конгрессында булып кайта.

17-29 ноябрьдә язучылар Р.Батулла һәм Р.Вәлиев Төркиядә төрки халыклары алфавитын камилләштерү мәсьәләләренә багышланган симпозиумда катнаша һәм чыгыш ясый.

Татарстан Министрлар Кабинеты җөмһүриятебезнең В.И.Ленин исемендәге китапханәсенә Милли китапханә статусы бирү турында карар кабул итә. ■

Мирасворд



- Гарәп язуының бер төре
- Аксыл кызыл
- Билгеле бер вакытта укылырга тиешле дога, аять
- Язучы Ләбибә ...
- Көйле тавыш, тон
- Ашлык бурасы
- Патша армиясендә кавалерия солдаты
- Балхаш күленә коючы елга
- Ишек, капка бите
- Иң зур агулы елан
- Кече Азиядәге борынгы дәүләт
- Амударьяның борынгы исеме
- «Муса» романы авторы
- Дунайның сул кушылдыгы
- Борынгы грек драматургы
- Күренекле рус шагыйрәсе
- XVII йөз француз фәлсәфәчесе, математик һәм физик
- Абдулла ....
- Пианист ... Урасин
- Максим Горький романы
- Урта гасыр Хәзәр каганлыгындагы шәһәр
- Хатынның апасының яки сеңлесенең ире
- XX йөз француз әдибе
- Төп, нигез (иск.)
- Хан мәҗлесендә касә өләшүче, сакый
- Борынгы Римда һәм Византиядә бакыр акча
- Чиләбе өлкәсендәге шәһәр
- Хорафатлар буенча: табигатьтән өстен явыз зат
- Хаҗилар киеме
- Күлдә, елга култыкларында яшәүче ялтыравык мехлы җәнлек
- «... Фәхри» җыры
- «... Мәргән» дастаны
- ... Ростропович
- Суның бер халәте
- Кәрим Тинчурин дрмасы
- Дивар шәмдәле
- Борынгы кабер өстендәге таш сын
- Пуэрто - ...
- Фин-угор халкы



Рәис Габдулла төзеде.

10 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Хәйри, вә, Сабир, ата, Мусин, шаһ, Алов, «Китап», Перов, Шамун, оран, шлен, «Сиваш», луидор, Кәлилә, һилал, Абы, шәмаил, айра, улҗа, Марк, га, Бату.
Өстән аска: мопс, «Шаһнамә», Ай, Саркел, Ларра, Ило, Лу, абак, Хәсәнов, Шихлы, Шабай, Сок, Итака, ирәбә, Ибраһимов, му, турачи, Алга, Канаш, Таҗи, Мәүла.

СОДЕРЖАНИЕ

Журналу «Безнең мирас» – 25!

Историческое наследие: «Булгар. Музей хлеба»; «Зулейха». А.Мухаммадиев; «Казаки Каргалы». Р.Аминов; «В стране нарушился финансовый порядок...» Р.Валиев; «Дом Якуба Акчурина». Н.Таиров, И.Таиров; «Судьба Хосрова би». Р.Галлям; «Мои деды были из знатного рода...» Рауза Биккулова; «Успешные начинания». Л.Хамидуллин.

Татарский мир: «Мы должны жить и гордиться тем, что мы татары!..» Мансур Ярмиев; «От них осталось хорошее наследство». Р.Юныс.

Татарские мигранты: «Сания Гиффат». Ф.Гаффарова

Литературное наследие: «Кутадгу билик». («Благодатное знание»). Ю.Баласагуни; «Белое облако Чингизхана». Ч.Айтматов; «Выбирая жениха». С.Кальметов; «Дни, когда Галиябану поднялась на сцену». М.Файзуллин.

В глубине памяти: «Тёплые воспоминания Ялты». Р.Мирхайдаров.

Художественное наследие: «Знакомящая мир с татарской душевностью». Ф.Муслимова.

100 лет назад...: «Казанские вести» в газете «Кояш»: ноябрь 1916 года».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT

«Our heritage» celebrates 25

Historic heritage: «Bulgar. The museum of bread»; «Zuleikha» by A.Mukhammadiev; «The Cossacks of Kargaly» by R.Aminov; «There is a financial disorder in the country...» by R.Valiev; «The House of Yakub Akchurin» by I.Tairov; «The fate of Khosrov bi» by R.Gallyam; «My grandfathers were from the prominent race...» by R.Bikkulova;
«The successful beginnings» by L.Khamidullin.

The Tatar world: «We must be proud of being Tatars!..» by M. Yarmiev; «The left an excellent heritage» by R.Yunys.

The Tatar migrants: «Saniya Giffat» by F.Gaffarova

Literary heritage: Kutadgu bilik» («The blessed knowledge») by U. Balasaguni; «The white cloud of Genghis Khan» by Ch. Aytmatov; «Choosing the groom» by S. Kalmetov; «The days when Galiyabanu began to act on the stage» by M.Fayzullin.

From the depth of memory: «The warm memoirs of Yalta» by R. Mirkhaydarov.

Creative heritage: «Introducing Tatar heartfulness to the world» by F.Muslimova.

100 years ago...: «Kazan news» is in the «Koyash» newspaper: November of 1916.

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

«Курай моңы».
Картон, майлы буяу.
1985 ел

ХАРИС ЯКУПОВ
(1919-2010)

Харис Габдрахман улы Якупов 1919 елның 23 декабрендә Казанда туа. 1940 елда Казан сәнгать училищесын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша.

Харис Якупов – күпсанлы тарихи картиналар, портретлар һәм пейзажлар авторы, СССРның халык рәссамы (1980), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1957), Г.Тукай исемендәге премия лауреаты (1958).

Х.Якупов 2010 елның 17 февралендә Казанда вафат була.

«Автопортрет».
Киндер, майлы буяу

«Герой ананы олылау».
Картон,
майлы буяу.
1957ел



www.beznenmiras.ru

ИГЪТИБАР! ИГЪТИБАР!

Хөрмәтле абунәчеләребез!
Журнал индексын каталогтан эзләп вакытыгызны югалтмыйча, турыдан-туры элемтә бүлеге хезмәткәрләренә мөрәҗәгать итә аласыз.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» белән бергә булыгыз!

ИНДЕКС:
Татарстанда – П-2343
Россиядә – 70275

«Безнең мирас» журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), Казан киоскларыннан сатып алырга мөмкин.